**КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ**

**Г.Тукай ис. татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар институты**

**Р.Х.МИРЗАҺИТОВ**

**Р.К.СӘГЪДИЕВА**

# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ТЕЛЕ: СИНТАКСИС

**Лекцияләрнең тулы конспекты**



**Казан-2013**

**Мирзаһитов Р.Х., Сәгъдиева Р.К.**

**Хәзерге татар теле: Синтаксис. Лекцияләрнең тулы конспекты** / Р.Х. Мирзаһитов, Р.К. Сәгъдиева; Каз.федер.ун-ты. – Казан, 2013. – 288 б.

Тәкъдим ителгән кулланмада хәзерге татар теле синтаксисы мәсьәләләре өйрәнелә. Гади һәм кушма җөмлә, текст синтаксисы белән бәйле теоретик материал практик биремнәр белән үрелеп бара. Кулланманың төп максаты – студентларның татар теле синтаксисы буенча белемнәрен тирәнәйтергә ярдәм итү, аларны мөстәкыйль эшләргә өйрәтү.

Тәкъдим ителгән курсның электрон версиясе бар: http://tulpar.kpfu.ru/course/view.php?id=419

Хәзерге татар теле һәм укыту методикасы кафедрасы утырышында кабул ителде

Протокол № 9 (07.06.2013)

**© Казан (Идел буе) федераль университеты**

**© Мирзаһитов Р.Х., Сәгъдиева Р.К.**

## Эчтәлек

**1. “Хәзерге татар теле: Синтаксис” курсын өйрәнүне оештыру буенча укытучыларга методик киңәшләр** 7

**2. “Хәзерге татар теле: Синтаксис” курсын өйрәнү өчен студентларга методик киңәшләр** 8

**3. Лекция № 1.**

3.1. Сөйләм төзелеше закончалыкларын өйрәнә торган фән буларак синтаксис. Синтаксик берәмлекләр: сүзтезмә, җөмлә кисәге, җөмлә һәм текст. Интонация 9

3.2. Гамәли биремнәр 18

3.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар 19

**4. Лекция № 2.**

4.1. Җөмләгә билгеләмә. Җөмләнең төп үзенчәлекләре хәбәрлек һәм модальлек. Аларның белдерелүе. Җөмләләрне төркемләү принциплары 21

4.2. Гамәли биремнәр 22

4.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар 23

4.4. Презентация 24

**5. Лекция № 3.**

5.1. Сүзләрнең синтаксик бәйләнеше. Сөйләмне оештыра торган төп бәйләнеш буларак ияртүле бәйләнеш. Сүзтезмә 24

5.2. Гамәли биремнәр 40

5.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар 43

5.4. Презентация 44

**6. Лекция № 4.**

6.1. Җөмләнең баш кисәкләре. Баш кисәкләрнең хәбәрлек оештырулары. Ия. Аның төп билгеләре. Хәбәр. Исем хәбәрләр. Фигыль хәбәрләр. Гади һәм тезмә фигыль хәбәрләр. Кушма фигыль хәбәрләр ........ 44

6.2. Гамәли биремнәр ........ 52

6.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар ........ 53

6.4. Презентация ........ 54

**7. Лекция № 5.**

7.1. Иярчен кисәкләр. Иярчен кисәкләрне өйрәнү тарихы. Аергыч. Тәмамлык, аның төрләре. Хәл, аның төрләре. Аныклагыч. Модаль кисәкләр ........ 54

7.2. Гамәли биремнәр ........ 72

7.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар ........ 73

7.4. Презентация ........ 74

**8. Лекция № 6.**

8.1. Тиңдәш кисәкләр. Җөмләнең синтагмаларга бүленеше. Аерымланган кисәкләр. Җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше. Сүз тәртибе. Тематик баш килешле әйләнмәләр. Өстәлмәләр ........ 75

8.2. Гамәли биремнәр ........ 102

8.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар ........ 104

8.4. Презентация № 1 ........ 105

8.5. Презентация № 2. ........ 105

8. 6. Презентация № 3. ........ 105

**9. Лекция № 7.**

9.1. Җөмлә төрләре. Раслау һәм инкяр җөмләләр. Хикәя, сорау, боеру, тойгылы җөмләләр. Тулы һәм ким җөмләләр. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. Ике һәм бер составлы җөмләләр ..... 105

9.2. Гамәли биремнәр ..... 118

9.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар ..... 120

9.4. Контроль эш ..... 121

9.5. Тест ..... 123

9.6. Презентация ..... 138

**10. Лекция № 8.**

10.1. Кушма җөмлә. Тезмә кушма җөмлә, аның төрләре. Иярченле кушма җөмлә, аның төрләре. Иярченле кушма җөмлә үзенчәлекләре. ..... 139

10.2. Гамәли биремнәр ..... 163

10.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар ..... 175

10.4. Презентация № 1. ..... 177

10.5. Презентация № 2. ..... 177

**11. Лекция № 9.**

11.1. Иярчен җөмләләрнең төзелеш һәм мәгънә ягыннан төрләре, аларның синонимлыгы ..... 178

11.2. Гамәли биремнәр ..... 187

11.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар ..... 194

11.4. Мөстәкыйль эш өчен биремнәр ..... 195

11.5. Тест № 9.1. (контроль эш) ..... 198

11.6. Тест № 9.2. (контроль эш) 200

11.7. Тест 203

11.8. Презентация № 1. 218

11.9. Презентация № 2. 218

**12. Лекция № 10.**

12.1. Катлаулы кушма җөмлә төрләре: күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә, күп иярченле катлаулы кушма җөмлә, катнаш кушма җөмлә 219

12.2. Гамәли биремнәр 226

12.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар 228

12.4. Презентация 229

**13. Лекция № 11.**

13.1. Текст. Пунктуация 229

13.2. Гамәли биремнәр 234

13.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар 239

13.4. Контроль эш 240

13.5. Тест № 11.1. (контроль эш) 243

13.6. Тест № 11.2. (контроль эш) 247

13.7. Тест 251

**14. Әдәбият исемлеге** 268

**15. Имтихан сораулары** 273

**16. Курс эше темалары** 276

**17. Глоссарий** 276

## 1. “Хәзерге татар теле: Синтаксис” курсын өйрәнүне оештыру буенча

## укытучыларга методик киңәшләр

Туган телне өйрәтү теориясе тел берәмлекләрен тикшерү күнекмәләре тәрбияләү белән бәйләп алып барыла. “Хәзерге татар теле: Синтаксис” курсының лекцион, практик дәресләр формасында баруы студентларның белем һәм күнекмәләрен тирәнәйтергә, алар белән индивидуаль эшләргә мөмкинлек бирә. Хәзерге татар әдәби теле синтаксисы нигезләре белән таныштырганда, укытучы фактик материалның сыйфатына, тел җәүһәрләрен файдалануга, студентларның теоретик белемнәрендә һәм сөйләм практикасында интерференция күренешләрен мөмкин кадәр булдырмаска тырышырга тиеш.

Хәзерге татар әдәби теле синтаксисын өйрәнү, бер яктан, тарихи-лингвистик дисциплиналарга таяна, икенче яктан, ул стилистика, сөйләм культурасы, социолингвистика белән тыгыз бәйләнештә тора.

Хәзерге татар әдәби теле синтаксисын укытканда, тел тармаклары арасындагы бәйләнешләрне (мәсәлән, лексикология, морфология, стилистика һ.б. белән) дә ассызыкларга кирәк.

Хәзерге татар әдәби теле синтаксисын укытканда, төп игътибар татар теленең орфоэпик һәм орфографик нормаларының саклануына юнәлдерелергә тиеш. Шул ук вакытта туган телнең даими үсештәге күренеш икәнлеген дә онытмаска кирәк, бу үсеш синтаксиста да чагылыш таба.

Хәзерге татар әдәби теле синтаксисын укытуның һөнәри юнәлеше аны мәктәптә татар телен укыту белән тыгыз бәйләүне таләп итә.

Синтаксик анализ күнекмәләрен һәм укытуның нәтиҗәләрен күзаллау максатында, практик дәресләрдә язма контроль эшләр, тестлар, мөстәкыйль эш төрләре үткәрү күз алдында тотыла, аларның нәтиҗәләре имтиханда исәпкә алына.

## 2. “Хәзерге татар теле: Синтаксис” курсын өйрәнү өчен студентларга методик киңәшләр

Хәзерге татар теле синтаксисын өйрәнү вакытында, студентлар лингвистик белемнәрен мөстәкыйль рәвештә тулыландыру һәм тирәнәйтү күнекмәләре алырга, татар телендә сөйләү осталыгын үстерергә һәм камилләштерергә, туган телнең әдәби нормаларына ия булырга, телдәге төрле синтаксик күренешләрне аңлый, тел берәмлекләренең системалы бәйләнешләрен һәм кулланылуын билгели, сүзләрне грамматик формалар һәм синтаксик берәмлекләр буларак куллануның үзенчәлекләрен аңлата белергә тиешләр.

Хәзерге татар әдәби теле синтаксисын үзләштергәндә, студент сүзтезмә, җөмлә һәм текст синтаксисы белән таныша. Ул җөмлә эченнән сүзтезмәләрне аера белергә, җөмлә кисәкләренә дөрес анализ ясарга, җөмлә төрләрен билгеләргә тиеш. Синтаксик анализ ясау күнекмәләренә ия булырга тиеш. Эш вакытында, бигрәк тә синтаксик анализ ясаганда, студентның логик фикерләве мөһим. Сорау кую алымыннан читләшеп, һәр җөмлә кисәгенең мәгънәсенә, формасына игътибар итә белү күнекмәләрен үстерү кирәк.

Студент грамоталы язу белән беррәттән тиешле тыныш билгеләрен дөрес куярга да өйрәнә. Пунктуация кагыйдәләрен практикада куллану күнекмәләре булдыру алгы планга чыга.

Студент үз белемен төрле формадагы тестлар, контроль сораулар, мөстәкыйль эш биремнәре ярдәмендә даими тикшереп тора ала.

Фәнне өйрәнү процессында лингвистик белемнәрне тулыландыру, татар әдәби теле синтаксисы нормаларына ия булу, шул ук вакытта татар теле синтаксисы белеме өлкәсендә фәнни тикшеренү эшләре алып бару күнекмәләре тәрбияләнергә тиеш.

**3.**
**Лекция № 1**

- **Сөйләм төзелеше закончалыкларын өйрәнә торган фән буларак синтаксис. Синтаксик берәмлекләр: сүзтезмә, җөмлә кисәге, җөмлә һәм текст. Интонация.**

**Аңлатма.** Әлеге тема синтаксисның төп берәмлекләре турында аңлатма бирә.

**Иң мөһим төшенчәләр.** Сүзтезмә, җөмлә кисәге, җөмлә, текст, интонация.

**Методик киңәшләр.**

•Тема теоретик мәгълүматны үз эченә алган лекциядән гыйбарәт;

•Мөстәкыйль эш өчен гамәли биремнәр тәкъдим ителә;

•Теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү максатыннан, теоретик сораулар бирелә.

### 3.1. Сөйләм төзелеше закончалыкларын өйрәнә торган фән буларак синтаксис. Синтаксик берәмлекләр: сүзтезмә, җөмлә кисәге, җөмлә һәм текст. Интонация.

"Синтаксис" грек теленнән кергән термин, "төзү"дигән сүз. Элеккеге (гасыр башы) грамматикаларда "нәхү" (Г. Алпаров, 1945) термины кулланыла (димәк, синтаксис сөйләм төзелешен өйрәнә). Шуны искәртү мөһим: сөйләм төзелешен, ә тел төзелешен түгел. Тел – аралашу коралы, ә сөйләм – аралашу ысулы, димәк телнең хәрәкәттәге халәте. Синтаксис телнең хәрәкәттәге халәтен өйрәнә.

XX йөз башына кадәр телне һәм сөйләмне аерып карамаганнар. Беренче тапкыр XIX йөз ахырында Швейцария галиме Ф. Соссюр сөйләм төзелешен тикшерә башлый. Шуннан әкренләп ул рус синтаксисына да керә. XX гасырның 50 нче елларында татар синтаксисында да әлеге юнәлеш үсеш ала. Ләкин бу синтаксис тел төзелешеннән читләшә икән дигән сүз түгел. Чөнки, нигездә, тел берәмлекләре белән сөйләм берәмлекләре (сүз, җөмлә, бәйләүче чаралар) туры килә.

Сөйләм – катлаулы күренеш, аны, гомумән алып, берьюлы өйрәнү мөмкин дә түгел. Шуңа күрә дә, иң элек аның төп берәмлеге булган җөмлә

аерым алынып тикшерелә. Ә җөмлә сөйләмнең барлык үзенчәлекләрен дә чагылдыра. Соңыннан җөмләләрнең текстка оешуын (ягъни сөйләмгә оешуын) тикшерәләр.

Кешенең хәтерендә конкрет җөмләләр түгел, бәлки, җөмләләрнең билгеле бер телгә хас булган калыплары саклана. Теге яки бу фикерне хәбәр итәргә кирәк булганда, сөйләүче әзер сүзләрне, кушымчаларны телгә хас булган аерым калыпка урнаштырып, конкрет җөмлә төзи. Синтаксис фәне өчен җөмләләрнең конкрет эчтәлеге әһәмиятле түгел.

Синтаксис билгеле бер телгә хас булган җөмлә модельләрен өйрәнә.

Төрле диалектларда, төрле коллективта, төрле обстановкада сөйләм төрлечә төзелергә мөмкин. Сөйләмгә аерым кешеләргә генә хас булган очраклы сүзләр (аккозионализмнар) дә килеп керү гадәти күренеш. Ләкин һәр телдә сөйләмнең уртак нормалары эшләнгән була (бу әдәби тел). Синтаксис фәне дә әнә шундый әдәби нормага салынган сөйләм төзелешен өйрәнә.

Сөйләмнең барлыкка килүе фикер әйтү зарурлыгы белән бәйле. Фикер үзе чынбарлыкның кеше аңында чагылышы буларак туа. Кеше сизү органнары аркылы чынбарлыктагы әйберләрне, күренешләрне үзенчә танып белә. Димәк, чынбарлыктан информация ала. Кеше миендә бу информация элек istә калганнар белән анализлана, нәтиҗәдә, фикер формалаша. Шушы фикер сөйләм ярдәмендә тыңлаучыга җиткерелә.

*Чынбарлык – кеше аңыннан тыш реаль яши торган күренешләр.*

Күргәнебезчә, сөйләм – телнең хәрәкәттәге халәте, икенче төрле әйткәндә, ул – аралашу процессы. Ә аралашу кешеләрнең бер-берсенә нәрсәдер хәбәр итүе аркылы тормышка ашырыла. Димәк, сөйләмнең беренче төп үзенчәлеге – хәбәр итү (аралашуны тәэмин итү). Сөйләмнең хәбәр итү үзенчәлеген синтаксиста **х ә б ә р л е к** диләр.

Хәбәр итүне сөйләүче чынбарлыктан алып оештыра. Шуңа күрә хәбәр итү сөйләүченең чынбарлыкка ниндидер бер мөнәсәбәттән тыш була алмый.

Сөйләүче чынбарлыкны, ничек бар шулай, үз кичерешләрен кушмыйча, тыңлаучыга җиткерергә мөмкин, яки үз кичерешләрен кушып

хәбәр итәргә мөмкин (хәбәр ителәсе күренешне кайгырып, шатланып, гаҗәпләнеп, сокланып, шикләнеп, нәфрәтләнеп, яратып һ.б. интонацияләр белән).

Сөйләм барышында шулай ук сөйләүче тыңлаучыга да үз мөнәсәбәтен (уңай яки тискәре) ниндидер бер сүз яки сүзләр тезмәсе белән белдерергә мөмкин (мөнәсәбәт белдермәсә робот булыр иде) (прогматик мөнәсәбәт).

Димәк, сөйләмнең икенче төп билгесе (үзенчәлеге) – сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерү. Моны синтаксис фәнендә **м о д а л ь л е к** диләр.

Шулай итеп, сөйләмнең 2 төп үзенчәлеге бар – хәбәрлек һәм модальлек. Хәбәрлек – гомумән хәбәр итү, модальлек – ничек хәбәр итү (хәбәрлек һәм модальлектән башка сөйләм барлыкка килми; сөйләмнән башка хәбәрлек һәм модальлек булмый).

Хәбәрлек – предикативность.

Модальлек – модальность.

Синтаксисның өйрәнү объекты сөйләм, ләкин сөйләм – чиксез әйбер. Аны гомумән алып өйрәнеп булмый. Сөйләмне өйрәнү өчен, аның берәмлекләрен аерып чыгаралар: текст, җөмлә, сүзтезмә, җөмлә кисәкләре, сүз.

**Синтаксис һәм логика, сөйләм һәм фикерләү арасында мөнәсәбәт.**

**Сөйләмнең төп үзенчәлекләре**

Синтаксис – билгеле бер телдә сөйләм төзү закончалыкларын, сөйләмнең төзелешен, логика исә фикерләүнең (мышление) формаларын һәм закончалыкларын өйрәнә.

Антик дөньяда ук кешенең фикерләү формаларын, законнарын өйрәнә торган фән – логика барлыкка килгән, фикерләүнең күзаллаулар (представление), төшенчәләр (понятие), хөкемләү (суждения), уйлау нәтиҗәләре (умозаключения) аркылы объектив чынбарлыкны чагылдыру икәнен аңларга тырышканнар. Фикерләүнең төп берәмлеге – хөкемләү,

хөкемләүнең төп өлешләре – субъект, предикат һәм бәйләү (связь) булуын ачканнар.

Ләкин башта әле фикерләү белән телне (сөйләмне) аерып карый белмәгәннәр. Шул чорда логика эчендә әкренләп синтаксис дигән фән туган. Синтаксисның берәмлекләре дә турыдан-туры логикадан чыгып билгеләнгәннәр, алар башта хәтта фикерләү берәмлекләренең исемнәре белән аталып йөртелгәннәр. Мәсәлән, тел белемендә һәм логикада җөмлә белән хөкемләүне аермыйча, икесен бер исем белән атап йөртүләр, субъектны иядән, предикатны хәбәрдән аермыйча, аларның икесенә дә бер үк атама кушулар әле XIX йөздә дә булган. Хөкемләүдә бәйләү (copula) булгач, җөмләдә дә өченче баш кисәк сыйфатында бәйләү яки бәйләгеч (связь) булырга тиеш дип санаганнар.

Бу мәсьәләдә капма-каршы чиккә ташланучылар да булган, ягъни кайберәүләр сөйләм белән фикерләү арасында бернинди бәйләнеш тә юк дип уйлаганнар.

Фикер әйтергә кирәклектән сөйләм оеша, димәк, сөйләм фикерләүне формалаштыра һәм аралашу процессында шул фикерне тыңлаучыга җиткерә. Сөйләм белән фикерләү, форма белән эчтәлек кебек үк бәйләнештә торалар. Форма эчтәлек түгел, эчтәлек форма түгел, шул ук вакытта форма эчтәлектән башка, эчтәлек формадан башка була алмый. Шуның кебек үк сөйләм фикерләү түгел, фикерләү сөйләм түгел, шул ук вакытта сөйләм фикерләүдән башка, фикерләү сөйләмнән башка була алмый.

Фикерләүне, алда әйтелгәнчә, логика фәне өйрәнә, тирәнрәк тикшерә башласаң, фикерләүнең үзенә генә хас үзенчәлекләре ачыла. Сөйләмне синтаксис фәне өйрәнә, җентекләбрәк өйрәнгәндә, сөйләмнең үзенә генә хас үзенчәлекләре табыла. Мисал өчен сөйләм һәм фикерләү берәмлекләренең төрле яссылыкта туры килү-килмәвенә күз салыйк.

*I яссылык – сөйләм белән фикерләү яссылыгы.*

Болар арасында форма белән эчтәлек арасындагы кебек диалектик бәйләнеш. Фикерләүне җәмгыятьтә эчке яки тышкы сөйләмнән башка гамәлгә ашырып булмый, башкаларга фикерне әйтү, алардан фикер алу, шул юл белән фикерне тагын да үстерү сөйләм (тышкы сөйләм) аркылы

тормышка аша. Икенче яктан караганда, сөйләм дә фикерләүсез була алмый.

*II яссылык – җөмлә белән хөкемләү яссылыгы.*

Хөкемләү нәрсәнеңдер булу-булмавын раслый, ягъни анда нәрсә булса да раслана яки инкяр ителә. Хөкемләү һәрвакыт җөмлә белән бирелә, ләкин барлык җөмләләр дә хөкемләүне тулы килеш белдерә дип әйтеп булмый. Мәсәлән, хикәя җөмләләр һәрвакыт хөкемләүгә туры киләләр, ә сорау һәм боеру җөмләләр хөкемләүне әзерләүдә яки аны дәвам итүдә күбрәк катнашалар. Күренә ки, бу яссылыкта сөйләм һәм фикерләүнең үзләренә генә хас үзенчәлекләре әкренләп арта бара.

*III яссылык – субъект һәм предикат, ия һәм хәбәр яссылыгы.*

Субъект – аның турында ниндидер яңалык әйтү өчен алынган төшенчә. Предикат – алынган төшенчә турында әйтелгән яңалык. Алар, икесе бәйләнешкә кереп, алынган төшенчәдә ниндидер билгенең булу-булмавын хәбәр итәләр. Кайбер очракта субъект – ия яки җәенке җөмләдә ия группасы белән, ә предикат хәбәр яки хәбәр группасы белән бирелә. Мәсәлән, *Көн эссе. Завод эшчеләре көнлек норманы тутырдылар.* Бу хөкемләүләрдә һәм җөмләләрдә: субъект (S) – *көн* һәм *завод эшчеләре*; ия – *көн* һәм *эшчеләр*; предикат (P) – *эссе* һәм *көнлек норманы тутырдылар,* хәбәр – *эссе* һәм *тутырдылар*. Куренә ки, беренче мисалда логик һәм синтаксик берәмлекләр ныграк туры киләләр, икенчесендә синтаксик берәмлекләр логик берәмлекләрнең үзәгендә генә торалар.

Кайчагында субъектның – ия, предикатның хәбәр белән бирелмәве дә мөмкин. Мәсәлән, *Сез синтаксисны кайчан үтә башлыйсыз?* дигән сорауга *Без синтаксисны өченче курста үтә башлыйбыз* дип җавап бирелсә һәм җавапны бу конкрет обстановкадагы хөкемләү буларак тикшерсәң, анда хәбәр итү өчен алдан алынган төшенчәне, ягъни субъектны, *Без синтаксисны үтә башлыйбыз* җөмләсе белдерә, шул алдан билгеле булган төшенчәнең яңалыгын *өченче курста* сүзләре белдерә, димәк, *өченче курста* – предикат була. Ул җавапны җөмлә буларак тикшерсәң, анда ия – *без*, хәбәр – *үтә башлыйбыз* булыр.

Болардан нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: сөйләм белән фикерләү арасында диалектик бәйләнеш бар, алар бер-берсеннән башка була

алмыйлар, ләкин алар бер үк нәрсәләр дә түгел. Фикерләүнең үзенә хас, сөйләмнең үзенә хас структурасы һәм закончалыклары бар. Шуңа күрә аларның икесен ике фән – логика һәм синтаксис өйрәнә. Синтаксис фәнен җентекләп өйрәнгәндә, логика нигезләре белән дә таныш булырга кирәк, шунсыз аны аңлавы кыен булачак.

**Сөйләмнең төп үзенчәлеге: хәбәрлек һәм модальлек**




Минем бүген авылга кайтасым бар.

Минем – субъект, ләкин ия түгел.

Идән юылган.

Идән – ия, ләкин субъект түгел, ә объект.

**Сөйләмнең төп үзенчәлекләре**

Күргәнебезчә, сөйләм ул телнең хәрәкәттәге халәте, ул – аралашу процессы. Ә аралашу кешеләрнең бер-берсенә нәрсәдер хәбәр итүе аркылы тормышка ашырыла. Димәк, сөйләмнең беренче төп үзенчәлеге – хәбәр итү, башкача әйткәндә, аралашуны тәэмин итү. Сөйләмнең хәбәр итү үзенчәлеген синтаксис фәнендә ***хәбәрлек*** диләр.

Хәбәр итүне сөйләүче чынбарлыктан алып оештыра, тыңлаучыга җиткерә, шуңа күрә хәбәр итү сөйләүченең чынбарлыкка (тыңлаучыга, хәбәр ителә торган фикергә, фикерне тудыруга сәбәп булган чынбарлык күренешләренә, фикернең формасына – сөйләмгә, сөйләм максатына, сөйләм обстановкасына)ниндидер бер мөнәсәбәтеннән тыш була алмый: сөйләүче чынбарлыкны, булганынча, үз кичерешләрен кушмаска тырышып, я күбрәк үз кичерешләрен кушып (хәбәр ителә торган күренеш булганга шатланып, кайгырып, гаҗәпләнеп, шикләнеп һ.б. тойгылар белән) хәбәр итә, вакыйганың булуын мөмкин яки мөмкин түгел дип карый, булуын яки булмавын тели, сөйләмнең төгәл яки җитешсез формалашуына игътибар итә, тыңлаучыга уңай яки кире мөнәсәбәтен дә сөйләмнең бер деталендә чагылдыра. Димәк, сөйләмнең икенче аерылгысыз билгесе, үзенчәлеге – сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерү. Моны сөйләмнең ***модальлеге*** диләр.

Хәбәрлек һәм модальлек нигездә сөйләмнең прагматикасын тәшкил итәләр, ягъни сөйләм оештыруның максатын тулыландыралар.

Шулай итеп сөйләмнең ике төп үзенчәлеге була, алар – хәбәрлек һәм модальлек. Хәбәрлек – гомумән хәбәр итү, модальлек – ничек хәбәр итү. Сөйләмнән башка хәбәрлек һәм модальлек булмый, хәбәрлек һәм модальлектән башка сөйләм булмый. Хәбәрлектән башка модальлек юк, модальлектән башка хәбәрлек юк.

## Синтаксик берәмлекләр

Синтаксисның өйрәнү объекты – сөйләм. Сөйләм ул колач җитмәслек чиксез бер күренеш, шуңа күрә аны гомумән алып өйрәнеп булмый. Бу эшне башкару өчен, синтаксис фәне иң элек сөйләмнең берәмлекләрен аерып чыгара. Сөйләмнең үзен алмаштыра алырлык берәмлек – текст. Текст итеп, аерым кыска әсәрләр (кечкенә хикәя, анекдот, мәсәл, мәзәк, мәкалә, гариза, беркетмә ...), әсәрләрнең бүлекләре, бүлекчәләре, параграфлары, берничә абзацтан торган өлешләре дә алына. Текстның бер темасы булырга, ул һәрьяклап бер бөтен төзергә тиеш. Хәбәрлек тә, модальлек тә текстта ачыграк чагыла.

Текстны тәртипле итеп өйрәнү өчен, иң элек текст эченнән сөйләмнең төп үзенчәлекләрен үзенә туплый алган, ягъни хәбәрлеге һәм модальлеге булган, иң кыска берәмлеге аерып чыгарыла. Сөйләмнең хәбәрлеккә һәм модальлеккә ия булган иң кыска берәмлеге – җөмлә. Ләкин җөмлә аралашу процессында үзе генә катнаша алмый, ул текст эчендә генә кулланыла. Димәк, җөмләне аерып алып өйрәнсәк тә, аның нинди текст эчендә килүен бер вакытта да истән чыгарырга ярамый.

Җөмләнең үзен эзлекле итеп өйрәнү барышында – сүзләр белән, җөмлә кисәкләре белән, җөмләдә сүзләр бәйләнешен тикшергәндә, сүзтезмәләр белән эш итәргә туры килә. Шуңа күрә синтаксиста, сөйләм берәмлекләре буларак, сүзләр, җөмлә кисәкләре һәм сүзтезмәләр дә сөйләгәндә алган үзенчәлекләре белән бергә аерып чыгарыла.

Шулай итеп синтаксис берәмлекләре: текст, җөмлә, сүзтезмә, сүз, җөмлә кисәге; шушылар ук сөйләм берәмлекләре дип тә аталалар.

## Интонация

Сүзләрдән җөмлә, җөмләләрдән сөйләм оештырганда, җөмләнең һәм сөйләмнең аерылгысыз элементы булып, интонация дә катнаша. Соңгы елларда интонациянең барлык төр чагылышларын, тавыш хәрәкәте турындагы фән буларак, просодия исеме белән өйрәнә башладылар.

Интонациянең җөмлә төзүдә зур роль уйный торган һәм үзара тыгыз бәйләнештә булган өлешләре: фраза басымы, пауза, логик басым, тойгы басымы, җөмләнең билгеле бер көй белән әйтелүе, ягъни тавышның аерым урыннарда күтәрелүе яки төшүе, сузыбрак әйтелүе.

Бер яки мәгънә ягыннан бәйләнгән берничә сүзне бер басым белән әйтүне **фраза басымы** диләр. Синтагмада берничә сүз булганда, басым шундагы бер сүзгә төшә, башкалары шул басымлы сүзгә кушылып китәләр. Бу күренеш, бердән, җөмләнең нормаль төзелешен саклауда роль уйнаса, икенчедән, сүзләрнең бәйләнешен дә тәэмин итә. Мәсәлән, *Табигый законнарны | үз белдегең белән | бозып булмый* дигән мисалда *табигый* һәм *законнарны* сүзләре бер фраза басымы белән әйтелгәндә генә, бер-берсенә бәйләнәләр; алар һәрберсе аерым фраза басымы белән

әйтелсәләр, ягъни алар арасында пауза ясалса, үзара бәйләнмәсләр иде: *Табигый, | законнарны | үз белдегең белән | бозып булмый.*

**Пауза**. Җөмләнең нормаль төзелешен һәм андагы сүзләрнең үзара бәйләнешен тәэмин итүдә, фраза басымы белән бергә, паузаның да роле бар. Чөнки һәр синтагма, ягъни фраза басымына тупланган сүзләр, башка синтагмалардан паузалар белән аерыла. Пауза синтагмаларны гына түгел, бәлки җөмләләрне дә бер-берсеннән аера, аерымланган иярчен кисәкләрне, эндәш һәм кереш сүзләрне аерырга ярдәм итә.

**Логик басым**. Җөмләдә мәгънәсе буенча иң әһәмиятле сүзгә төшә торган басымны логик басым диләр. Логик басым төшә торган сүзне, ягъни тыңлаучы өчен яңа төшенчәне, хөкемләүнең предикатын белдерә торган сүз дип атыйлар. Логик басымны күчерү белән, җөмләнең мәгънәсе дә үзгәрә, башка төрле хөкемләү барлыкка килә: *Без бер йомыш белән сезгә килгән идек. Сезгә бер йомыш белән без килгән идек.*

**Тойгы басымы**. Тойгы басымы көчле тойгы белән әйтелгән җөмләләрдә аерым сүзләргә төшә һәм сөйләүченең чынбарлыкка нинди мөнәсәбәттә торуын белдерә. Тойгы басымы төшкән сүз сузыбрак әйтелә. Ул күп вакыт логик басым белән бер урынга туры килергә дә һәм аннан аерым да булырга мөмкин. Мәсәлән: *Сезгәме со-оң гомуми эшләр артыннан йөрү-ү!* (К. Тинчурин).

**Сөйләм көе.** Сөйләм көе тойгы басымы, логик басым һәм пауза белән аерылгысыз бәйләнгән. Сөйләмнең көенә карап, җөмләләрнең төрләре, сүзләр һәм җөмләләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләре, модаль мәгънәләр билгеләнә.

Интонация, көенә карап, берничә төргә бүленә.

**Тулы интонация,** ягъни күтәрелү өлеше, югары ноктасы һәм төшү өлеше булган интонация: *Студентлар түгәрәккә барысы да теләп язылдылар.*

Әкренләп күтәрелә бара һәм үзенең иң югары ноктасында кинәт туктап кала торган интонация **күтәрелүче интонация** дип атала: *Студентлар түгәрәккә барысы да теләп язылдыла-ар?*

**Төшүче интонация**, ягъни үзенең югары ноктасыннан әкренләп төшеп бара торган интонация: *Рәхәт тә соң шушы олыларга тагылып йөрү!* (И. Гази).

**Катнаш интонация**: *Сезгәме соң гомуми эшләр артыннан йөрү!* (К. Тинчурин).

Интонация, сөйләм көенә һәм паузаның характерына карап, тагын түбәндәге төрләргә бүленә:

**Хәбәр итү интонациясе** теләсә нинди җөмләне тәмамлап куя. Бу төр интонация булмаса, сүзләрдән җөмлә оеша алмый. Хәбәр итү интонациясе хикәяләү, сорау, боеру, үтенү төрләренә бүленә. Тойгыга бай җөмләләрдә хәбәр итү интонациясе бик күп төрле тойгы басымы белән төрләнә ала.

**Санау интонациясе** хәбәр итү интонациясеннән бик ачык аерылып тора. Санау интонациясе тиңдәш кисәкләр һәм тиңдәш җөмләләрне үзара бәйләүдә катнаша.

**Каршылык интонациясе** бер-берсенә семантик каршы куелган сүзләр яки җөмләләр арасында була.

**Көттерү интонациясе** кисәкләр яки җөмләләр арасында көттерү паузасы булуга бәйләнгән. Бер кисәк яки җөмлә әйтелә дә “әле сүз бетмәде, тагын әйтәсе бар” дигән кебек көттерү паузасы ясала, шуннан соң гына калган сүз-кисәк яки җөмлә әйтелә. Көттерү паузасы булган урында һәрчак ике нокта куела.

Интонациянең бу төрләре дә, телдәге башка чаралар кебек үк, мәгънә белдерүдә катнашалар, шуңа күрә алар тел-сөйләм чаралары рәтеннән каралалар.

### 3.2. Гамәли биремнәр.

**1 нче бирем.** Түбәндәге текстта ике бер үк сүзләрдән оешкан җөмләләргә нинди мәгънә салынган һәм аларны нинди интонация белән укырга кирәк?

*Йөгерү ярышында ике мәктәпнең спорт командасы катнаша. 1 нче гимназиянең иң яхшы йөгерүчесе авырып киткән. Алар җиңеләбез дип алдан ук кайгыра башлаганнар. Кинәт төркем арасыннан ябык кына кечкенә бер малай, җилкәләрен киереп, иптәшләре арасыннан кысыла-кысыла, алга чыга башлый.*

- *Сиңа кая? – дип сорый бер иптәше.*

- *Сиңа кая! – дип әйтә икенчесе.*

**2 нче бирем.** Логик басым ярдәмендә җөмләнең мәгънәсен төрлечә үзгәртеп карагыз.

*Алсу бүген әбиләренә кунакка бара.*

**3 нче бирем.** Төзүчеләр бригадасы, гадәттә, планны арттырып үти. Ләкин ни өчендер бүген алар начаррак эшләделәр. Бары тик Мансуров кына, һәрвакыттагыча, биремне арттырып үтәде. Көн азагында төзелештәге радиодан “Бүген Мансуров кына планны арттырып үтәде”, – дип хәбәр итәләр. Берничә сәгатьтән Мансуров директорга керә һәм үпкәләгән кыяфәттә үзенең һәрчак планны арттырып үтәгәнлеген хәбәр итә. Сез ничек уйлыйсыз: диктор нинди хата ясаган? Редактор әлеге хатаны җибәрмәс өчен нишли ала иде?

**4 нче бирем.** Каралтылган сүздән соң пауза ясалган очракта, әлеге җөмләнең мәгънәсе ничек үзгәрә? Җөмләгә нинди мәгънәләр биреп була. Бер төрле генә мәгънәне аңларлык итеп, җөмләне үзгәртеп языгыз.

***Көчкә-көчкә** чукып ясалган такта фигураны ул стенага элеп куйды.*

**5 нче бирем.** Пауза һәм интонация ярдәмендә диалогтагы икенче репликаның мәгънәсен ничек инкяр итеп була?

- *Арыдыңмы?*

- *Тагын шуның кадәр чапкач!*

### 3.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар.

1. Синтаксис сүзе нинди мәгънәләрдә кулланыла?
2. Ни өчен синтаксисның өйрәнү объекты сөйләм?
3. Тел белән сөйләмнең аермасы нәрсәдә?
4. Синтаксис һәм логика фәннәре бер-берсенә нинди мөнәсәбәттә торалар?
5. Сөйләм һәм фикерләү арасындагы мөнәсәбәтне ничек аңлыйсыз?
6. Синтаксик берәмлекләргә нинди берәмлекләр керә?
7. Сөйләм ничек барлыкка килә?
8. Нәрсә ул хәбәрлек?
9. Нәрсә ул модальлек?
10. Сөйләм интонациясе нинди өлешләрдән тора?
11. Нәрсә ул фраза басымы?
12. Нәрсә ул пауза?
13. Нәрсә ул логик басым?
14. Тойгы басымы дип нинди басымга әйтәләр?
15. Нәрсә ул сөйләм көе?
16. Хәбәр итү, санау, каршы кую һәм күтәрү интонацияләрен сез ничек аңлыйсыз?

## 4.
## Лекция № 2

- **Җөмләгә билгеләмә. Җөмләнең төп үзенчәлекләре хәбәрлек һәм модальлек. Аларның белдерелүе. Җөмләләрне төркемләү принциплары.**

**Аңлатма.** Әлеге тема җөмлә һәм аның төп үзенчәлекләре турында аңлатма бирә.

**Иң мөһим төшенчәләр.** Җөмлә, хәбәрлек, модальлек.

**Методик киңәшләр.**

•Тема теоретик мәгълүматны үз эченә алган лекциядән гыйбарәт;

•Мөстәкыйль эш өчен гамәли биремнәр тәкъдим ителә;

•Теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү максатыннан, теоретик сораулар бирелә.

•Лекция презентация белән үрелеп бара.

## 4.1. Җөмләгә билгеләмә. Җөмләнең төп үзенчәлекләре хәбәрлек һәм модальлек. Аларның белдерелүе. Җөмләләрне төркемләү принциплары.

Сөйләмнең фикерне, кичерешне һәм ихтиярны хәбәр итә һәм сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерә торган иң кыска берәмлеге **җөмлә** дип атала. Сөйләм җөмләләрдән тора, һәм җөмлә, сөйләмнең төп берәмлеге буларак, аның ике төп үзенчәлеген – хәбәрлекне һәм модальлекне – үзендә чагылдыра.

Фикерне, кичерешне һәм ихтиярны хәбәр итүе, ягъни аларны чынбарлыктан алып чынбарлыкка төбәп әйтүе җөмләнең **хәбәрлек белдерүе** дип атала. **Хәбәрлек** – җөмләнең иң төп бер билгесе, һәм ул җөмләгә хас. Хәбәрлек я ике сүзнең үзара хәбәрлекле мөнәсәбәткә керүе (*Кар эреде.*), я бары бер генә сүзнең хәбәр итә торган үзәк төзүе формасында (*Кыш. Салкын һава. Язам.*) бирелә. Хәбәрлек белдерүдә заман формалары, вакыт һәм урын белдерә торган сүзләр дә катнаша, чөнки хәбәрлек – сөйләмнең билгеле бер урын һәм вакыт эчендә алынган чынбарлыкны хәбәр итүе ул. Хәбәрлек нинди генә формада бирелмәсен, ул хәбәр итү интонациясеннән аерылгысыз.

Сөйләүченең чынбарлыкка, тыңлаучыга, сөйләмгә мөнәсәбәт белдерүе җөмләнең **модальлек белдерүе** дип атала. **Модальлек** – җөмләнең шулай ук иң төп билгесе.

Модальлек хикәя, сорау, боеру һәм тойгылы җөмләләрне формалаштыра торган чаралар белән бирелә. Биредә хәбәр формалары зур роль уйный. Мәслән: *Болытлар таралдылар. Кояш ничәдә чыга? Нинди иркен минем туган илем! Тизрәк чап!*

Сөйләүче, сөйләгәндә, үзенә, тыңлаучыга һәм сөйләмдә катнашмаган өченче бер затка да үзенең мөнәсәбәтен белдерә. Мондый модальлек зат,

тартым кушымчалары, зат алмашлыклары һәм эндәш сүзләр белән дә бирелә.

Модальлек һәрвакыт интонациягә төренгән була. Тойгыга бай модальлекне белдерүдә интонация башка чараларга караганда да зуррак роль уйный.

Хәбәрлек һәм модальлек – җөмләнең аерылгысыз билгеләре. Хәбәрлексез һәм модальлексез җөмлә була алмаган кебек, җөмләсез дә хәбәрлек һәм модальлек була алмый. Хәбәрлек белән модальлек үзара аерылгысыз бәйләнештә тора.

Телдәге барлык категорияләр хәбәрлек һәм модальлек белдерү процессында барлыкка килгәннәр, үскәннәр, шомарганнар.

Җөмләләрне төрле принциплардан чыгып төркемлиләр. Хәбәрлек санына карап, җөмләләр гади һәм кушма була. Гади җөмләләр раслау – инкяр, хикәя – сорау – боеру (тойгылы); җәенке – җыйнак, тулы – ким, бер составлы – ике составлы; тәмамланган – тәмамланмаган кебек төрләргә бүлеп анализлана. Кушма җөмлә, компонентларның санына карап, ике компонентлы һәм катлаулы кушма җөмләләргә аерыла. Ике компонентлы җөмлә тезмә һәм иярченле кушма җөмләгә аерыла. Катлаулы кушма җөмләнең төрләре: күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә, күп иярченле катлаулы кушма җөмлә һәм катнаш кушма җөмлә. Күп иярченле катлаулы кушма җөмлә исә үз чиратында тагын дүрт төргә: тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләгә, тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләгә, бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләгә һәм берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләгә аерыла.

## 4.2. Гамәли биремнәр.

**1 нче бирем.** Хикәя, сорау, боеру җөмләләргә матур әдәбият әсәрләреннән икешәр мисал табып языгыз. Аларның һәрберсен тойгы белән әйтеп карагыз.

**2 нче бирем.** Мәкальләрне укыгыз. Аларның мәгънәләрен аңлатыгыз. Үзегез белгән мәкальләрне өстәп языгыз.

*Яхшы сүз балдан татлы.*

*Әйткән сүз – аткан ук.*

*Сүз канатсыз, ләкин оча.*

*Сүз бер көнлек, тел гомерлек.*

**3 нче бирем.** Бөек затларның тел турында әйткән фикерләрен табып языгыз.

**4 нче бирем.** Тәкъдим ителгән җөмләләр арасыннан “артык” җөмләне табыгыз.

1. *Абыйсының шигырен ишетсә, Заһит, мөгаен, йомшарыр иде* (С. Сөләйманова).

2. *Бик телиләр икән, ихтирам итәләр икән, әнә егетләр үзләре беренче булып баш исен!* (Г. Бәширов).

3. *Көнем туса,*

*Җиргә сыймый шатлыгым* (Р. Фәйзуллин).

4. *Таштай каты, йомры таза имән чикләвеге бәрәкәтле туфракка эләктеме, тишелеп чыга һәм кояшка тартыла башлый* (Р. Низамиев).

5. *Яшьлегеңдә күп тырышсаң,*

*Эшкә бирсәң чын күңел,*

*Картлыгыңны*

*Бик тыныч һәм бик җиңел* (Г. Тукай).

**4.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар.**

1. Нәрсә ул җөмлә?

2. Нәрсә ул хәбәрлек?

3. Нәрсә ул модальлек?

4. Җөмләнең төп үзенчәлеге булган хәбәрлек нинди юллар белән белдерелә?

5. Модальлекнең бирелү юллары нинди?

6. Җөмләнең нинди төрләргә бүленә?

**4.4. Презентация.**

**5.**
**Лекция № 3**

- **Сүзләрнең синтаксик бәйләнеше. Сөйләмне оештыра торган төп бәйләнеш буларак ияртүле бәйләнеш. Сүзтезмә.**

**Аңлатма.** Әлеге тема сүзләр арасындагы тезүле һәм ияртүле бәйләнешне, аларның чараларын чагылдыра. Сүзтезмә турында аңлатма бирә.

**Иң мөһим төшенчәләр.** Тезүле һәм ияртүле бәйләнеш; хәбәрлекле, төгәлләүле (ачыклаулы), аныклаулы мөнәсәбәт, сүзтезмә.

**Методик киңәшләр.**

•Тема теоретик мәгълүматны үз эченә алган лекциядән гыйбарәт;

•Мөстәкыйль эш өчен гамәли биремнәр тәкъдим ителә;

•Теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү максатыннан, теоретик сораулар бирелә.

•Лекция презентация белән үрелеп бара.

**5.1. Сүзләрнең синтаксик бәйләнеше. Сөйләмне оештыра торган төп бәйләнеш буларак ияртүле бәйләнеш. Сүзтезмә.**

Сөйләм барлыкка килсен өчен, сүзләр бер-берсенә бәйләнгән булырга тиеш, ә аңлаешлы сөйләм барлыкка килсен өчен, алар билгеле бер чаралар ярдәмендә һәм билгеле бер тәртиптә бәйләнергә мәҗбүр. Бу бәйләнеш гаять күп төрле (бигрәк тә сөйләмә телдә, көндәлек сөйләмдә). Шулай булса да, тел белемендә 2 төрле бәйләнеш бар дип уйланыла.

тезүле

Бу – бәйләнешләр

иярт үле

**Тезүле бәйләнеш** булганда, бәйләнешкә кергән сүзләр тигез хокуклы булалар, бер-берсенә буйсынмыйлар (чагыштырмача, бер-берсеннән семантик бәйсез булалар, бер сүздән икенчесенә сорау да куеп булмый). Күп очракта аларның урыннарын алыштырып була.

Мәсәлән: *Безнең су ул кешеләргә*

*Көч, гайрәт, дәва бирә.* (Р. Миңнуллин)

Тик бәйләнешле сөйләм барлыкка килсен өчен, ягъни җөмлә төзелсен өчен, сүзләр арасында ияртүле бәйләнеш булу шарт. Димәк, тезүле бәйләнеш үзе генә җөмлә төзи алмый, ул җөмләдә ияртүле бәйләнеш белән бергә генә килә.

Тезүле бәйләнеш нәтиҗәсендә җөмләнең **тиңдәш кисәкләре** барлыкка килә.

Тезүле бәйләнеш җөмләнең төрле логик-грамматик кисәкләре арасында булырга мөмкин.

Мәсәлән: *Урамнар да, урманнар да –*

*барысы да иске танышлар* (иyәләр арасында).

*Күпме хатын, әнә, әле булса*

*Яудан көтә ирен, улларын* (тәмамлыклар арасында).

(Р. Миңнуллин)

*Гомерләр үтмәгән, көз әле җитмәгән*

*Елыйбыз, көләбез, яшибез бит әле* (хәбәрләр арасында).

(Ш. Җиһангирова)

*Туган авылыбызны сагынып,*

*Авыз суыбызны агызып, күз яшьләрен хәтта тамызып,*

*“Кайтам” – диеп, җырлар язабыз* (хәлләр арасында) һ.б.

(Ә. Атнабаев)

Тезүле бәйләнешкә кергән сүзләр үзара түбәндәге чаралар ярдәмендә бәйләнәләр.

1 – интонация

-*Һәм дә бар монда куян, әрлән, тиен, йомран, пошы* (санау интонациясе).

(Г. Тукай)

-*Көзнең шундый вакыты җитте. Кояш чыга – җылытмый* (каршы кую интонациясе).

2 – тезүче теркәгечләр

*а) Ул чорлар да бу чорлар,*

*Каеннар да чыршылар.*

*Бар да матур кебек тә*

*Күңел тулы борчулар* (җыючы теркәгеч).

(Г. Афзал)

б) *Я суга сал, я утка ат*

*Я кайгымнан арала* (бүлүче теркәгеч).

в) *Алар безне бөек эшләргә илһамландыралар, тик эшләргә генә комачаулыйлар* (каршы куючы теркәгеч).

(А. Чехов)

Тезүле бәйләнеш үзе генә сөйләм барлыкка китерә алмый. Сөйләм оешсын өчен, сүзләрнең бер-берсенә буйсынып, ияреп китүе кирәк, ягъни ияртүле бәйләнеш мөһим.

**Ияртүле бәйләнештә** ияртүче һәм иярүче компонентлар була (В. Хангилдин "җитәкче" һәм "җитәкләнүче" сүзләр дип тә атый). Мәсәлән: *урманда <u>йөрү</u>, яшел <u>чирәм</u>, <u>мин</u> укыйм* (*йөрү, чирәм, мин* – ияртүче; *урманда, яшел, укыйм* - иярүче).

Ияртүче сүз белән иярүче сүз арасында төрле мәгънә мөнәсәбәтләре була (аларны синтаксик мөнәсәбәтләр дип тә атыйлар). Бу мөнәсәбәтләр сөйләм оештырудагы әһәмиятләренә карап, үзара өч төргә бүленәләр.

1 – хәбәрлекле

2 – тәгәлләүле (ачыклаулы)

3 – аныклаулы

**I.** Җөмлә оештырудагы 1 нче дәрәҗәдәге рольне – **х ә б ә р л е к л е** мөнәсәбәт үти.

Хәбәрлекле мөнәсәбәт булганда, 1 сүз икенче сүз турында (яки иярүче сүз (хәбәр) ияртүче сүз (ия) турында) нинди дә булса бер яңалык хәбәр итә.

Хәбәрлекле мөнәсәбәт нигезендә - сөйләмнең төп берәмлеге <u>**җөмлә**</u> барлыкка килә. *Мин язам.* (Шуңа күрә дә бу мөнәсәбәт иң әһәмиятлесе – 1 нче дәрәҗәдәге роль уйный дип санала да). Тагы шуны да әйтергә кирәк: хәбәрлекле мөнәсәбәттәге сүзләрнең ияртүчесе һәрвакыт әйберләрне, билгеләрне, процессларны, төшенчәләрне *атаучы* сүз була һәм бары тик баш килештә генә килә. Бу үзенчәлек хәбәрлекле мөнәсәбәттәге тезмәне тәгәлләүле мөнәсәбәттәге тезмәдән аерырга да ярдәм итә.

Мәсәлән: *Клубта җыелыш бара* – бу бәйләнештә *"җыелыш бара"* тезмәсе клуб турында хәбәр итә, ләкин хәбәрлекле мөнәсәбәт барлыкка килми, чөнки *"клубта"* баш килештә килмәгән (бу беренчедән) һәм икенчедән, клуб сүзе *"җыелыш бара"* тезмәсенә түгел, ә бәлки *"бара"* сүзе белән генә бәйләнгән. Шуңа күрә бу мисалда *"җыелыш"* сүзе белән *"бара"* сүзе арасында гына хәбәрлекле мөнәсәбәт була.

Хәбәрлекле мөнәсәбәткә кергән сүзләр арасында төрле мәгънә мөнәсәбәтләре булырга мөмкин.

Мәсәлән: *Алмаз укый.* – субъект тарафыннан эшләнгән эш белдерелә.

*Идән юылды.* – иярүче сүздән аңлашылган процессның

объекты белдерелә.

*Китап – Маратныкы* – бер предметның икенче предметка (бу очракта затка) каравы белдерелә.

*Тырышуым – синең өчен* – процессның максаты белдерелә.

*Кайтучылар – алтау* – затларның билгесе, бу очракта саны белдерелә һ.б.

Хәбәрлекле мөнәсәбәтне белдерә торган чаралар:

**1) Кушымчалар:**

а) хәбәрлек кушымчалары. *Мин – студент<u>мын</u>.*

б) зат-сан кушымчалары. *Мин <u>язам</u>. Син <u>эшлисең</u>.*

в) тартым кушымчалары. *Китап <u>Маратныкы</u>.*

г) килеш кушымчалары. *Китап <u>өстәлдә</u>. Хат <u>сезгә</u>.*

д) сыйфат, рәвеш ясагыч кушымчалар. *Сөйләшүе <u>татарча</u>.*

**2) Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр**: *Сагынганда айга карыйм.*

*Ул да гел <u>синең төсле.</u>*

*Урам <u>пыяла шикелле</u>.*

**3) Сүз тәртибе.** Сүзләр билгеле бер тәртиптә торганда гына хәбәрлекле мөнәсәбәткә кереп, җөмлә төзи алалар. Мәсәлән: *<u>Яфраклары</u>*

<u>*яшел*</u> *ак каенга Юл буеннан аклар килделәр* (М. Җәлил) (*яфраклар*-ия, *яшел*-хәбәр; ике сүз нәкъ менә шушы тәртиптә торганда гына җөмлә төзи). *Яшел яфраклы ак каенга* дигәндә - җөмлә барлыкка килми. (*яшел* сүзе дә, *яфраклы* сүзе дә аергыч булалар) *Һава саф* – хәбәрлекле мөнәсәбәт*, саф һава* - ( төгәлләүле мөнәсәбәт, 1 сост. җөмлә).

**4) Интонация (хәбәр итү интонациясе).** Марат – студент. Гомумән, ия белән хәбәр нинди генә чаралар ярдәмендә бәйләнсәләр дә, аларда хәбәр итү интонациясе була.

Югарыда әйтеп кителгән бәйләүче чаралар берничәсе берьюлы да кулланылырга мөмкин.

**II. Т ө г ә л л ә ү л е м ө н ә с ә б ә т** булганда, ияртүче сүз ияртүче сүзне ачыклап, конкретлаштырып килә, ягъни ияртүче сүз ияртүче сүзнең мәгънәсен төгәлрәк итә (төгәлләүле). Икенче төрле атамасы да бар – **а ч ы к л а у л ы.**

Мәсәлән: *ак күлмәк* тезмәсендә *ак* сүзе (ияртүче) *күлмәк* сүзен (ияртүче сүзне) ачыклый, төгәллек өсти *(яшел түгел, кара түгел, ә ак).*

*Урманда йөрү – (урамда, шәһәрдә, авылда, паркта түгел).*

Төгәлләүле мөнәсәбәт үзе генә сөйләмне, җөмләне төзи алмый. Төгәлләүле мөнәсәбәт нәтиҗәсендә <u>**сүзтезмә**</u> барлыкка килә.

Ике яки берничә мөстәкыйль сүзнең төгәлләүле мөнәсәбәткә керүе һәм билгеле бер телгә хас грамматик юл белән төзелүе нәтиҗәсендә ясалган һәм төгәлрәк төшенчәне белдерә торган тезелмәсе **с ү з т е з м ә** дип атала.

Төгәлләүле мөнәсәбәткә кергән сүзләр арасында бик күп төрле мәгнә мөнәсәбәтләре була.

*Мәсәлән*: *китап уку – процессның объекты белдерелә;*

*ак күлмәк – предметның билгесе белдерелә;*

*тиз йөрү – процессның үтәлү рәвеше белдерелә һ.б.*

Төгәлләүле мөнәсәбәт җөмлә төзүдә 2 нче дәрәҗәдәге рольне уйный.

Төгәлләүле мөнәсәбәтне белдерә торган чаралар:

***1. Кушымчалар.***

*а) килеш: елгага бару, судан чыгу һ.б.;*

*б) тартым: минем дәфтәрем, Марат китабы;*

*в) фигыль кушымчалары:* *тырышып эшләү, баргач күрү, укыса белә, килгән кеше, укырга килү һ.б.;*

*г) сүз ясагыч:* *урамдагы машиналар (сыйфат ясагыч)*

*татарча китап (рәвеш ясагыч)*

**2. Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр.**

*Бәхет өчен көрәшү; синең белән бару; елга буйлап йөрү* һ.б.

**3. Сүз тәртибе** (*яшел яфрак*).

**4. Сүзләрне кабатлау**: *капчык-капчык бәрәңге, чиләк-чиләк җиләк*;

**5. Янәшә тору.** Кайбер очракларда сүзләр янәшә торып кына бәйләнешкә керәләр.

*Класста утыз студент утыра – утыз студент* янәшә килеп бәйләнгәннәр.

**6. Ияртүче теркәгечләр** *(алкаң ялтырый, гүя асылташ).*

**7. Лексик мәгънә** - сүзләр бәйләнешендә төп рольне уйный, башка төр бәйләнешләр белән бергә дә йөри. *Бүген безгә кунак килде* – җөмләсендә 3 бәйләнеш бар – *безгә килү; кунак килде, бүген килү* = “бүген” һәм “килү” сүзләре лексик мәгънә белән бәйләнгәннәр.

**8. Фраза басымы** – бу чара төгәлләүле мөнәсәбәтне белдерә торган башка чаралар белән бергә килә.

Мәсәлән: *яшел кара, татарча китап, капчык-капчык бәрәңге* кебек тезмәләрдә сүзләрнең бер басым астында әйтелсә генә бәйләнешләре аңлашыла. Әгәр һәр сүзгә аерым басым ясалса, төгәлләүле мөнәсәбәт булмас иде. ә санау интонациясе булыр иде *(яшел, кара, капчык, капчык, бәрәңге).*

**III. А н ы к л а у л ы   м ө н ә с ә б ә т** булганда, бер сүз икенче сүзне аныклап килә. Җөмлә төзүдә 3 дәрәҗәдәге рольне үти. Аныклаулы мөнәсәбәт җирлегендә, җөмләдә **аныклагыч** дигән җөмлә кисәге оеша (аныклау һәм аныкланмыш барлыкка килә).

Аныклагыч белән аныкланмыш түбәндәге чаралар ярдәмендә бәйләнәләр.

**1) Аныклау интонациясе:**

*Мин югалттым <u>аны</u> – <u>бәхетемне</u>,*

*Бәхетсезгә тормыш бик яман.*

*Очратсагыз: “Сине табар ул”, - дип*

*әйтегезче, зинһар, - мин табам.*

**2) Теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр белән**: (ягъни, аеруча, икенче төрле әйткәндә, һ.б.)

*Бу вакыйга, ягъни минем мәктәпкә беренче баруым, хәтеремдә мәңге сакланыр.*

Ярашкан аныкланмыш белән аныклагыч тезүле бәйләнешкә дә якын булалар (ләкин бу форма ягыннан гына шулай).

Тел белемендә ияртүле бәйләнешне, анда кулланылган синтаксик чараларның төренә карап һәм ияртүче сүз таләбе белән иярүче сүзнең нинди форма алуыннан чыгып, өч төргә бүлү традициягә кергән

-ярашу

-башкарылу

-янәшәлек

**Ярашу** булганда иярүче сүз үзенең формасын ияртүче сүзгә карап яраштыра.

(бер-берсенә ияргән сүзләрнең бер үк төрле формада килү күренеше)

1) - килеш категориясе формасында ярашу

-аныклагыч белән аныкланмыш арасында ярашу (тулы ярашу).

*Озакламый анда – кырларда таш пулатлар үсәр,*

*Озакламый монда – урамда виноградлар пешәр.*

(у.в. килеш кушымчасы ярдәмендә ярашканнар)

-аныклагычлар гадәттә ярашалар. Ярашмау очраклары бар:

*Без фәкыйрьне хәтерегездән чыгармагыз. (безне – фәкыйрьне түгел)*

2) - зат һәм сан категорияләрендә ярашу (өлешчә ярашу)

*Комбайннар уралар,* *Мин язам.*

*Сез язасыз.*

*Без укыйбыз.*

3) -тартым категориясе белән ярашу (тулы ярашу). Аныклагычлар белән аныкланмыш арасында була.

*Бу соңгысы – иң-иң көчлесе*

*Талантлы совет язучылары – кеше рухының инженерлары – безгә гүзәл әсәрләр бирделәр.* Димәк, тулы ярашу аныклагычларда була.

(Рус телендә - моя сестра –род, сан)

**Башкарылыш** (яки башкарылу) синтаксик төзелмә составындагы ияртүче сүз иярүче сүзнең нинди дә булса бер формада килүен тели яки таләп итә (бу очракта ике сүзнең дә бер үк формада килүе таләп ителми).

Мәсәлән: *бүлмәгә керү, бүлмәдән чыгу, бүлмәдә утыру, бүлмәнең ишеге* – дигән мисалларда *“бүлмә”* сүзе, билгеле бер соралган төшенчәне бирү өчен, үзе бәйләнгән, ягъни ияргән сүзнең таләбе буенча, килеш категориясенең әнә шундый формаларын ала.

Традицион грамматикада – иярүче сүзнең нинди дә булса килеш формасы яки бәйлек белән ияртүче сүзгә бәйләнүен башкарылуга кертәләр.

Мәсәлән: *(халык өчен тырышу; апа белән килү; урманга кер һ.б.).*

Кайбер телче галимнәр башкарылуны 2 төргә дә бүләләр (бер яклы һәм ике яклы).

Бер яклы булганда = 1 сүз 2 нче сүзнең билгеле бер формада килүен таләп итә (*урманга бару*).

Ике яклы башкарылыш булганда, иярүче сүз дә, ияртүче сүз дә икенчесенең билгеле бер формада килүен таләп итәләр.

Мәсәлән: *өстәлнең тартмасы, шкафның шүрлеге.*

Бу мисалларда икенче сүз (*тартмасы, шүрлеге*) беренче сүзнең иялек килешендә килүен таләп итә, ә икенче сүзләр беренче сүз таләбе буенча өченче зат тартымы формасында килә... (һ.б.)

**Янәшәлек** юлы булганда, сүзләр үзара янәшә тору, сүз тәртибе, интонация, лексик мәгънә аша бәйләнәләр.

Исеменә караганда, бу очракта сүзләр янәшә торырга тиеш кебек аңлашыла. Ләкин бу алай түгел. Төп үзенчәлек: ике сүзнең кушымчалардан, бәйлекләрдән башка гына, ә мәгънә белән генә бәйләнешкә керүе.

Мәсәлән: *шәп йөзү, бу китап, бүген эшләү ... һ.б.*

Сүзләр бәйләнеше

| *Тезүле бәйләнеш* | *Ияртүле бәйләнеш* |
|---|---|
| *сүзләр бер – берсе белән тезелеп килә, әлеге сүзләр барысы да бер генә сүзгә иярә, алар тиңдәш кисәкләр дип атала* | *бер сүз икенчесенә ияреп килә, ияреп килгән сүзләр җөмләнең иярчен кисәкләре була.* |

Ияртүле бәйләнеш

| *Хәбәрлекле мөнәсәбәт* | *Төгәлләүле (ачыклаулы)* | *Аныклаулы мөнәсәбәт* |
|---|---|---|
| *бер сүз икенче сүз турында нәрсә дә булса хәбәр итә* | *бер сүз икенче сүзне төгәлләп, конкретлаштырып килә* | *бер сүз икенче сүзне аныклап килә, әлеге сүз турында өстәмә мәгълүмат бирә* |
| *җөмлә оеша (ия – хәбәр)* | *сүзтезмә оеша* | *аныклагыч - аныкланмыш* |
| *Мин укыйм.* | *Ак күлмәк* | *Без аларны, ягъни кунакларны, түземсезлек белән көттек.* |

**Сүзтезмә**

Сүзтезмә төшенчәне башка шуңа охшаш төшенчәләрдән аерып, конкретлаштырып күрсәтә. Аерым сүз төшенчәне гомумән генә атый -

*өстәл.* Сүзтезмә төгәлләп атый – *буялган өстәл.* “*Китап*” – сүз ► “*кызыклы китап*” – сүзтезмә.

Сүзтезмәләрне өйрәнүенең максатлары:

1. Кайсы сүз төркемнәренең кайсы сүз төркемнәр белән бәйләнешкә керә алуын өйрәнү (Мәсәлән, исем кайсы сүз төркемнәрен ияртә һәм кайсы сүз төркемнәренә иярә).
2. Сүзләрнең үзара нинди юллар белән, чаралар белән бәйләнүен өйрәнү (Мәсәлән, фигыльләр исемнәрне килеш кушымчасы ярдәмендә ияртәләр; исемнәр сыйфатларны янәшә тору юлы белән ияртәләр – *яшел чирәм* һ.б.).
3. Сүзтезмәләрдәге сүзләрнең үзара нинди мәгънә мөнәсәбәтендә торуын өйрәнү.
4. Сүзтезмәнең төзелеше ягыннан төрен аеру (гади яисә катлаулы).

Сүзтезмәгә хас үзенчәлекләр:

– Сүзтезмә ике яки икедән артык мөстәкыйль сүздән торырга тиеш (Мәсәлән, “*балта белән*”, “*килү генә*”, “*укый иде*” – сүзтезмәләр түгел, чөнки *белән* – бәйлек; *генә* - кисәкчә, *иде* – ярдәмче фигыль. *Балта белән кисү* – сүзтезмә). Чөнки ярдәмлек сүзләрнең лексик мәгънәләре булмый.

– Сүзтезмәләр әйберләрне, төшенчәләрне атыйлар гына, алар чагыштырмача тәмамланган уйны белдермиләр, ягъни аларга хәбәрлекне һәм модальлекне (җөмләнең төп билгеләре) белдерү хас түгел. Мәсәлән: *Көн салкын.* Көннең салкынлыгы хәбәр ителә ► җөмлә; *салкын көн* – көнне башка шундый көннән аерып кына атый, конкретлаштыра, ягъни җылы түгел, ә салкын көн ► сүзтезмә барлыкка килә.

– Сүзтезмәдәге сүзләр билгеле бер телгә хас булган грамматик юллар белән бәйләнәләр (Мәсәлән, татар телендә бәйлекләр, кушымчалар, интонация һ.б.).

– Җөмлә төзүдә катнашканда, сүзтезмә кисәкләренең янәшә килүе мәҗбүри түгел.

*Врач бүген бераз урамда йөрергә кушты* – җөмләсендә: “*йөрергә*” сүзенә ияреп килгән *урамда* сүзе генә янәшә килгән, “*бераз*” һәм “*бүген*” сүзләре янәшә түгел.

**Сүзтезмәләрне өйрәнү тарихы**

Рус телендә сүзтезмәләрне өйрәнү Михаил Васильевич Ломоносов һәм Александр Христофорович Востоковлардан башлана.

Татар телендә сүзтезмәне XIX йөздә өйрәнә башлыйлар. Беренче мәгълүматларны Александр Троянскийның 1814 елда Петербургта басылган “Краткая татарская грамматика”сында таба алабыз. Ул теләсә нинди 2 сүз сүзтезмә барлыкка китерә дип саный (*әти белән*...).

Александр Казем-Бек “Общая грамматика турецко-татарского языка” (1839, 1846), Мартиньян Иванов “Татарская грамматика” (1842) хезмәтләрендә сүзтезмәләрне тикшерәләр. Алар исемнәрнең, фигыльләрнең нинди сүзләр белән ни рәвешле бәйләнешкә керүләрен тикшерәләр, ләкин “сүзтезмә” терминын кулланмыйлар.

Каюм Насыйри 1860 нчы елда дөнья күргән “Краткая татарская грамматика, изложенная в примерах...”, 1895 нче елда басылган “Әнмүзәҗ” исемле грамматикаларында сүзтезмәләрне 2 төргә бүлә:

– тулы сүзтезмә (ияртүче сүзе фигыль булган сүзтезмәләр): *утны сүндер...*

– ким сүзтезмә (ияртүче сүзе исем булган сүзтезмәләр): *тугры юл, яхшы сүз.*

Каюм Насыйрида кызыклы гына бүленешләр бар. Мәсәлән: җенесне билгеле торган сүзтезмәләр (*арыш оны; бодай ярмасы*).

Җамал Вәлиди 1919 елда нәшер ителгән “Татар теленең грамматикасы” исемле хезмәтендә сүзтезмәләрне тикшерә һәм җөмләне дә сүзтезмәләрнең бер төре итеп карый.

1959 елда В.Н. Хангилдинның “Татар теле грамматикасы” хезмәтендә һәм 1958 елда М.З. Зәкиевның “Хәзерге татар әдәби теле” хезмәтендә сүзтезмәләр инде бик җентекләп тикшерелә.

Сүзтезмәләрне төрле чорда галимнәр төрле төркемнәргә бүлгәннәр.

Кайбер галимнәр Александр Матвеевич Пешковский (1878 – 1933) сүзтезмәләрен ияртүле һәм тезүле сүзтезмәләренә бүлгән һәм тезүлеләргә "*син дә мин*", "*белә, ләкин әйтми*" кебек тезүле бәйләнешкә кергән сүзләрне дә керткән (ягъни тиңдәш кисәкләрне).

Каюм Насыйри тулы һәм кимнәргә бүлә дип әйттек.

Хәзерге "Татар грамматикасы"ның III томында түбәндәге бүленеш бирелгән.

I. Сүзтезмәнең кисәкләре арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләренең югалу-югалмавыннан һәм шуның нәтиҗәсендә сүзтезмәнең ныгып калу-калмавыннан чыгып, ике төргә бүленәләр.

– <u>фразеологик сүзтезмә</u>

– <u>ирекле сүзтезмә</u>

Фразеологик сүзтезмәләр, теге яки бу күренешне атау өчен, катып калган, тотрыклы булалар, сөйләмгә әзер килеш керәләр. Мәсәлән*, җил куу, трай тибү* һ.б.

Фразеологик сүзтезмәләрне лексикология бүлеге өйрәнә, чөнки алар сүзтезмәләрдән бигрәк, аерым сүзләргә якынайганнар (ике-өч сүз бер лексик мәгънә белдерә).

Ирекле сүзтезмәләр дип кирәк булганда гына, ягъни сөйләм барышында гына ясалган һәм кисәкләре арасында реаль мәгънә мөнәсәбәте югалмаган сүзтезмәләрне әйтәләр (синтаксик сүзтезмәләр). Сүзләр бер-берсенә карата ирекле булалар (*тупка тибү*).

Синтаксис фәне ирекле сүзтезмәләр белән эш йөртә.

II. Сүзтезмәдәге мөстәкыйль сүзнең санына карап, 2 төргә бүленәләр.

– <u>Гади сүзтезмәләр</u> (ике мөстәкыйль сүздән торалар: *теге атна, алты дәрес, белер өчен тырышу, сезгә барып җитү*).

– <u>Катлаулы сүзтезмәләр</u> (икедән артык мөстәкыйль сүздән торган сүзтезмәләр: *ике капчык бәрәңге, киләсе атнага кайту*).

Бу мисалларда "*ике капчык*" һәм "*киләсе атна*" дигән гади сүзтезмәләр дә бар. Ләкин "*капчык бәрәңге*" һәм "*атнага кайту*" дип

әйтеп булмый, булган очракта да тиешле мәгънәне бирми. Шуңа күрә өч сүзне бергә алып тикшерергә туры килә. Катлаулы сүзтезмәләрне таркатып тикшерергә ярамый.

III. Өйрәнү бурычларыннан чыгып төркемләнәләр. Монда өч төп мәсьәләне ачыкларга тиешбез. Мисал өчен, фигыль сүз төркеме мисалында аңлатырга була.

– Татар телендә фигыль кайсы сүз төркемнәрен ияртә ала?

– Нинди чаралар, формалар ярдәмендә ияртә?

– Мондый сүзтезмәләрдәге сүзләр арасында мәгънә ягыннан нинди мөнәсәбәтләр була?

Ияртүче сүзнең кайсы сүз төркеменнән булуына карап, сүзтезмәләрне 7 зур төркемгә бүләләр.

- ияртүчесе исем булган сүзтезмә;

- ияртүчесе сыйфат булган сүзтезмә;

- ияртүчесе сан булган сүзтезмә;

- ияртүчесе рәвеш булган сүзтезмә;

- ияртүчесе фигыль булган сүзтезмә;

- ияртүчесе алмашлык булган сүзтезмә;

- ияртүчесе хәбәрлек сүз булган сүзтезмә.

Үз чиратларында, аларның һәрберсе иярүче сүзнең нинди сүз төркеменнән булуына карап төркемләнә. Мәсәлән: *хат язу* (ияртүче сүз – *язу* (фигыль), иярүче сүз – *хат* (исем) ► исемле фигыль сүзтезмә.

- *биш сыман тоелу* ► санлы фигыль сүзтезмә;

- *күп язу* ► рәвешле фигыль сүзтезмә;

- *болай язу* ► алмашлыклы фигыль сүзтезмә;

- *кирәк дип эшләү* ► хәбәрлек сүзле фигыль сүзтезмә;

- *күрер өчен килү* ► фигыльле фигыль сүзтезмә һ.б.

Исем сүзтезмәләргә мисаллар:

- *укылган китап* – фигыльле исем сүзтезмә;

- *биш китап* – санлы исем сүзтезмә;

- *күп китап* – рәвешле исем сүзтезмә;

- *матур китап* – сыйфатлы исем сүзтезмә;

- *бу китап* – алмашлыклы исем сүзтезмә;

- *укучының китабы* – исемле исем сүзтезмә;

- *кирәк китап* – хәбәрлек сүзле исем сүзтезмә.

Сүзләр бәйләнешендә сүзтезмәләрне тикшерү:

*өйдә утыру* – ияртүле бәйләнеш; төгәлләүле мөн.; исемле фигыль сүзтезмә; бәйләүче чара урын-вакыт килеше кушымчасы *-дә*; ияртүче сүз иртүче сүздән аңлашылган процессның үтәлү урынын белдерә.

Сүзтезмәләрне тикшергәндә, аларның модельләрен дә төзергә мөмкин. Моның өчен түбәндәге шартлы билгеләр алына.

И – исем — Ф – фигыль

С – сыйфат — А – алмашлык

Сан – сан — Х – хәбәрлек сүз

Р – рәвеш

*Китапны уку* – И (-ны) – Ф (туры объект).

*Җырлый-җырлый эшләү* – $Ф^2$ – Ф (процессның үтәлү рәвеше).

*Ике капчык бәрәңге* – Сан+И (янәшәлек) – И (предметның күләмен белдерә).

Түбәндәге сүзтезмәләрнең модельләрен күзәтегез:

| | |
|---|---|
| *Абый белән килү* | *И (белән) – Ф (объект)* |
| *Шактый күп* | *Р (янәшәлек) – Р (билгенең күләме)* |

*Чиләк-чиләк җиләк* *$И^2$ – И (предметның күләме)*

*Укучының дәфтәре* *И (-ның) – И (е) (иялек мөнәсәбәт)*

*Басып сөйләү* *Ф (ып) – Ф (процессның үтәлү рәвеше)*

**5.2. Гамәли биремнәр.**

**1 нче бирем.** Түбәндәге җөмләләрдәге сүзтезмәләрнең модельләрен төзеп языгыз.

*Күктә йолдызлар җемелдәшә, өй артында күккә томырылып үскән тирәкләр утыра. Яфраклары ай яктысында тонык кына ялтырашалар. Якынлы-еракты гармун моңнары, яшьләр тавышы яңгырый.*

**2 нче бирем.** Бирелгән сүзләрне сүзтезмәгә әйләндереп языгыз. Әлеге сүзтезмәләрне берләштереп, җөмлә төзегез.

*Уку –*

*Күлмәк –*

*Китап –*

*Малай –*

**3 нче бирем.** Сүзтезмәләр арасыннан “артык” берәмлекне табыгыз.

1) *кызыл яулык, зәңгәр һава, сары яфрак, биш китап, кара карга;*

2) *баллы чәй, урамда уйнау, тәмле бәлеш, эссе көн, айлы төн;*

3) *шәһәрдә яшәү, әнине ярату, зур бүлмә, мәктәптән кайту, университетта уку.*

**4 нче бирем.** Сүзтезмәләр кулланып, "Минем иптәшем" дигән темага хикәя уйлап языгыз.

**5 нче бирем.** Ияртүле бәйләнештә торган сүзләрне хәбәрлекле, төгәлләүле, аныклаулы мөнәсәбәтләргә аерыгыз.

*Бөтен күк гөмбәзен тутырып торган болытлар каядыр китеп югалды. Ялтырап кояш чыкты. Кышкы урман малайларның күз алдында бөтен матурлыгы белән балкып китте. Ботакларында энҗе утлар җемелдәшкән агачлардан бөтен тирә-якка зәңгәрсу күләгәләр сузылган. Әйтерсең ниндидер күзгә күренми торган рәссам ак полотнога урман рәсемен ясап калдырган...* (Ф. Шәфигуллин).

**6 нчы бирем.** Тексттан сүзтезмәләрне аерып чыгарыгыз.

*Болдырдан киндер ыштанлы, чигүле түбәтәй кигән малай йөгереп чыкты да ябага тубын тибеп җибәрде. Ишек алдында гамьсез генә чүпләнгән тавыклар, пырхылдашып, як-якка сибелделәр. Дәррәү купкан тавыштан куркып, песи баласы капка астыннан урамга чыгып шылды. Туры лапас астыннан карлыгачлар ук кебек тышка атылдылар* (М. Галиев).

**7 нче бирем.** Сүзтезмәләрне аерып чыгарыгыз һәм анализ ясагыз.

*Атна буе салкын җил исте. Инешләр туңды, уҗым басулары, түгәрәк урман артында диңгездәй җәелеп яткан сазлык туңды. Корыган камышлар ачынып сызгырыштылар. Агач ботакларына эләгеп калган сары яфракларны рәхимсез җил бер селтәнү белән коеп төшерде дә ерак кырларга очырып китте. Ә көннәрдән бер көнне җил тынып калды. Һава, ничектер, җылынып, дымсуланып китте. Биектә, биектә өер-өер булып каядыр ашыккан болытлар, тизлекләрен киметеп, бер көчкә укмаштылар, авырайдылар, түбәнәйделәр, аксыл төстән болганчык-көлсу төскә керделәр* (Ф. Шәфигуллин).

**8 нче бирем.** Бирелгән мәгънә мөнәсәбәтләренә туры килерлек итеп сүзтезмәләр уйлап языгыз.

Билге + предмет

Вакыт + эш-хәл

Сан + зат

Корал + эш-хәл

Тәм + предмет

Урын + эш-хәл

**9 нчы бирем.** Сүзләр бәйләнешен күзәтегез, сүзтезмәләрнең төрләрен, бәйләүче чараларны билгеләгез.

*Безнең мәктәп, алтын балдак, мактанчык бала, киләчәк өчен тырышу, әниемә бүләк иту, төлкедәй хәйләкәр, эштән соң шалтырату, кылычтай үткен, чәчәкле болын, мичкә - мичкә бал, һавадагы йолдызлар, синнән сорау, чиләк-чиләк җиләк, табиб булып эшләү, өй артындагы каен, җәен кайту, сагынып яшәү, барасы юл, мәкаләне уку, берәр китап, юк-бар сүз, бүген кайту, кычкырып сөйләшү.*

**10 нчы бирем.** Бирелгән сүзтезмәләрне гади һәм катлаулы сүзтезмәләргә аерып языгыз.

*Авылга кадәр кайту, балаларга сөйләү, җиләкле болын, бер иптәш, укысаң белү, икенче урам, су буеннан кайту, биш кило алма, киләсе елда күрешү, кәрәзле бал, болынга хәтле озату, сөйли торган курчак, бакча уртасында тору, күргәч әйтеп салу, акка буяу, куркудан кычкырып җибәрү, каләм белән язу, тау артыннан күренеп тору, матурлап ясау, җырлый-җырлый бию, ике кило шикәр, алты сәгать эшләү, Айсылу исемле кыз.*

**11 нче бирем.** Бирелгән берәмлекләрне ирекле һәм тотрыклы сүзтезмәләргә аерып языгыз.

*Көч җыю, әтәч гөмбә, судан кайту, йөз баш сарык, әрем белән себерү, ак шигырь, ду килү, язгандай күренү, биредән алу, күз карасы, безнең улыбыз, вузда уку, сүз бирү, ант эчү, алтын куллы, ләчтит сату, киселгән агач, ялт итү, салам кыстыру, санаулы көннәр, пыр туздыру, кош теле хәтле, ут яну, кайнар су, эшлисе эш, су буеннан бару, аның шикелле кылану.*

## 5.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар.

1. Сүзләр арасындагы бәйләнеш нинди төрләргә бүленә?
2. Ияртүле һәм тезүле бәйләнешләр бер-берсеннән кайсы яклары белән аерылалар?
3. Ияртүле бәйләнеш нинди төрләргә бүленә?
4. Хәбәрлекле мөнәсәбәтне нинди чаралар белдерә?
5. Төгәлләүле мөнәсәбәт нинди чаралар ярдәмендә хасил була?
6. Аныклаулы мөнәсәбәтне белдерә торган нинди чаралар беләсез?
7. Хәбәрлекле мөнәсәбәт нәрсә оештыра?
8. Төгәлләүле мөнәсәбәт нигезендә нәрсә хасил була?
9. Сөйләм оешсын өчен нинди мөнәсәбәтләр кирәк?
10. Ярашу, башкарылу һәм янәшәлек юлларын ничек аңлыйсыз?
11. Тезүле бәйләнешне нинди чаралар белдерә?
12. Нәрсә ул сүзтезмә?
13. Гади һәм катлаулы сүзтезмәләр бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?
14. Өйрәнү максатыннан чыгып, сүзтезмәләрне нинди төрләргә аералар?
15. Ирекле һәм фразеологик сүзтезмә бер-берсеннән ничек аерыла?

**5.4. Презентация.**

**6.**
**Лекция № 4**

- **Җөмләнең баш кисәкләре. Баш кисәкләрнең хәбәрлек оештырулары. Ия. Аның төп билгеләре. Хәбәр. Исем хәбәрләр. Фигыль хәбәрләр. Гади һәм тезмә фигыль хәбәрләр. Кушма фигыль хәбәрләр.**

**Аңлатма.** Әлеге тема җөмләнең баш кисәкләре турында аңлатма бирә. Ия белән хәбәрнең структур төрләрен аерырга өйрәтә.

**Иң мөһим төшенчәләр.** Җөмләнең баш кисәкләре, ия, хәбәр.

**Методик киңәшләр.**

•Тема теоретик мәгълүматны үз эченә алган лекциядән гыйбарәт;

•Мөстәкыйль эш өчен гамәли биремнәр тәкъдим ителә;

•Теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү максатыннан, теоретик сораулар бирелә.

•Лекция презентация белән үрелеп бара.

**6.1. Җөмләнең баш кисәкләре. Баш кисәкләрнең хәбәрлек оештырулары. Ия. Аның төп билгеләре. Хәбәр. Исем хәбәрләр. Фигыль хәбәрләр. Гади һәм тезмә фигыль хәбәрләр. Кушма фигыль хәбәрләр.**

Җөмлә төзелешен тикшергәндә, җөмләне кисәкләргә таркатып өйрәнү әһәмиятле. Мондый кисәкләргә җөмләнең актуаль кисәкләрен, синтагматик кисәкләрен һәм логик-грамматик кисәкләрен кертергә була.

Логик-грамматик кисәкләрне “җөмлә кисәге” дип кенә атау да гадәткә кергән (бигрәк тә мәктәп дәреслекләрендә).

Әле фикерләү белән сөйләмне аерып карый белмәгән чорларда, җөмләне синтаксик берәмлекләргә түгел, ә логик төшенчәне аңлата торган

берәмлекләргә бүлеп өйрәнгәннәр. Мәсәлән: субъект (ия), предикат (хәбәр), объект (хәл яки тәмамлык), атрибут (аергыч) һ.б. Бу әле XIX гасырда да күзәтелә. Ләкин бу логик-грамматик кисәкләр түгел, ә бәлки семантик кисәкләр генә.

Хәзерге грамматикада да җөмләнең семантик кисәкләре дигән төшенчә бар.

Мәсәлән: *Безнең Марат Камил белән шәһәргә китә* җөмләсендә *Марат* – субъект, *китә* - предикат; *Камил белән* – объект; *шәһәргә* - ачыклагыч; *безнең* – атрибут. Семантик кисәкләр мәгънәгә генә карый (исеменнән үк күренгәнчә). Ә логик-грамматик кисәкләр мәгънәгә дә, формага да карыйлар.

Логик-грамматик кисәкләр семантик кисәкләргә туры киләләр дигән сүз түгел (ия – субъектка; хәбәр – предикатка һ.б.). Ул нигездә шулай. Мәсәлән:

*Ул дәфтәргә язды*. *Ул* – ия, субъект.

*Дәфтәргә* – тәмамлык, объект.

*Язды* – предикат, хәбәр.

*Дәфтәр язылган*. *Дәфтәр* – ия, объект.

*Язылган* – хәбәр, предикат.

Бу очракта “ия” субъектка туры килми. Димәк, җөмләнең семантик төзелеше икенче әйбер.

Татар телендә җөмләне кисәкләргә таркатып өйрәнүне XIX гасырда рус грамматикасы нигезендә эшли башлыйлар.

Александр Троянский (“Краткая татарская грамматика”, 1814, 1824) ия, хәбәр һәм бәйләгеч дигән җөмлә кисәкләрен күрсәтә.

М. Иванов (“Татарская грамматика”, 1842) ия белән хәбәргә өстәп аергыч һәм тәмамлыкны бирә. Тәмамлыкларны туры һәм кыекка бүлә. Хәбәргә иярсә туры, башка кисәккә иярсә кыек дип күрсәтә.

А. Казем-Бек ("Общая грамматика турецко-татарского языка", 1846), гомумән, иярчен кисәкләрне аерым терминнар белән атап бүлгәләми. 2 зур төркемгә бүлә:

- ияртүче кисәккә янәшәлек юлы белән бәйләнүчеләр;

- ияртүче кисәккә башкару юлы белән бәйләнүчеләр.

Баш кисәкләр дип субъект белән предикатны күрсәтә.

Җ. Вәлиди ("Татар теле грамматикасы", 1919) аергычларны тикшерә, тәмамлыкларны берничә төргә бүлә (төшем, күчем, урын, вакыт, сәбәп, максат, рәвеш һ.б.).

Г. Ибраһимов ("Татар нәхүе", 1919) 8 иярчен кисәк бар дип күрсәтә: вакыт, урын, рәвеш, сәбәп, аергыч, тәмамлык, эндәш һәм кереш сүз.

Г. Алпаров ("Шәкли нигездә татар грамматикасы", 1926) баш кисәк итеп хәбәрне генә таный. Ияне хәбәрнең баш тәмамлыгы дип бирә.

Бүгенге көндә ("Татар грамматикасы", III том) 8 җөмлә кисәге күрсәтелә:

Баш кисәкләр **– ия, хәбәр.**

Иярчен кисәкләр – **аергыч, тәмамлык, хәл, аныклагыч.**

Модаль кисәкләр – **эндәш сүзләр, кереш сүзләр.**

## Баш кисәкләр

### Ия

Җөмләдә баш килештәге сүз белән бирелеп, хәбәрне үзенә ияртә торган грамматик бәйсез кисәк **ия** дип атала (хәбәрлекле мөнәсәбәткә кергән сүзләрнең ияртүчесе). Ия һәрвакыт баш килештә килә, аңа төшем һәм иялек килеше кушымчаларын куеп карап булмый. Ия янында беркайчан да бәйлек һәм бәйлек сүзләр килми.

Ия җөмләдә төрле мәгънәләрдә килә ала:

1) киң мәгънәдә үтәүчене (субъектны) белдерә.

*Теләкләрем минем сезнең чорда, сезнең кырда чәчәк атачак.*

(В. Хангилдин әлеге форманы актив ия дип тә атый).

2) эшнең объектын, эшкә дучар ителүчене белдерә ала.

*Хат берничә тапкыр укылды.*

(В. Хангилдин пассив ия дип атый).

3) ия эшкә кушучыны, йөкләүчене белдерә ала (хәбәр йөкләтү юнәлешендә булса бигрәк тә).

*Кешеләр малайлардан яңгыр боткасы да пешертеп карадылар* (И. Гази).

4) хәбәр фигыльдән башка сүз төркемнәре белән бирелсә, ия нинди дә булса бер үзенчәлеге хәбәр ителә торган әйберне, затны, предметны белдерергә мөмкин.

*Суың тәмле, кырың ямьле, шифалы һаваларын* (предметның билгесе).

*Капчыктагы бүре башы бит уникe* (предмет саны) һ.б.

Төзелеше буенча ияләр 2 төрле булалар. 1 генә сүз белән бирелсә - **гади ия** (*Гөлләр шиңгән*). Составында мөстәкыйль һәм ярдәмче сүзләре аерыла торган, шуның аркасында тоташ бер лексема, ягъни сүз дип таныла алмаган синтаксик төзелмәләр ►**тезмә ия** дип аталалар. Мәсәлән: *Ярдәм итү-итмәү – сезнең эш. "Кубрат хан" – тарихи роман.*

Ия, нигездә, исем сүз төркеме белән бирелә: *Тормыш матур, дөнья киң.*

Башка сүз төркемнәре белән дә бирелергә мөмкин:

*Мин – укытучы* (алмашлык).

*Уку – энә белән кое казу* (фигыль).

*Икәү килә елга буйлатып* (сан).

*Аз-маз җитми* (рәвеш).

*Җылы сөяк сындырмый, салкын җанны туңдырмый* (сыйфат) һ.б..

**Хәбәр**

Җөмләнең ия турында хәбәр итә һәм аңа грамматик буйсына торган икенче баш кисәге **хәбәр** дип атала. Хәбәр ияне эше, хәле, сыйфаты, билгесе, микъдары кебек якларыннан характерлап ачыклый.

Хәбәрнең белдерелүе мәсьәләсендә тел галимнәрендә төрле карашлар яшәп килә. Берәүләр фигыль сүз төркеме генә хәбәр була ала дип раслый (Александр Матвеевич Пешковский (1878-1933), Евгений Федорович Будде (1859-1929)). Александр Александрович Шахматов (1864-1920) төрләнми торган сүз төркемнәре хәбәр була алмый дигән караштa тора. Татар тел белеме галиме Латыйф Җәләй хәбәрләрне исем, фигыль һәм сыйфат хәбәрләргә бүлә.

Казем-Бек (Мирза Мухамет Али Казембек – Александр Касимович) исем, сыйфат, сан, алмашлык белән бирелгәннәрне гади; фигыль хәбәрләрне кушма дип карый.

К. Насыйри белән А. Троянский исә тиңдәш хәбәрләрне генә кушма дип билгелиләр. Гомумән, хәбәрләрне төркемнәргә бүлүдә фикерләр бик күп төрле (Әле 70 нче елларда чыккан М.З. Зәкиев хезмәтләрендә дә тезмә хәбәрләр турында әйтелми).

Бүгенге көндә, татар грамматикасында бирелгәнчә, хәбәрләрне мәгънәләре буенча 2 төргә бүләләр.

- фигыль хәбәрләр
- исем хәбәрләр (шартлы рәвештә)

Фигыль хәбәрләр фигыль сүз төркеме белән белдерелә һәм һәрвакыт процессны, эшне, хәрәкәтне белдерәләр.

Исем хәбәрләр фигыльдән башка сүз төркемнәре белән белдереләләр һәм иядән аңлашылган әйбернең билгесен белдерәләр.

Көн жылы. Без - өчәү. Эш юк.

Фигыль хәбәрләр дә, исем хәбәрләр дә төзелешләре буенча кушма, тезмә, гади төрләргә бүленәләр (схематик рәвештә түбәндәгечә күрсәтергә мөмкин).




**Фигыль хәбәрләр**

Гади фигыль хәбәрләр фигыль сүз төркеме белән белдереләләр һәм бер генә сүздән торалар:

- *Карлар эреде, бозлар йөгерде* (хикәя фигыль белән).
- *И, сабыйлар, эшләгез сез* (боерык фигыль белән
- *Төн уртасы авышса, җил бераз тынар иде* (шарт фигыль).

Шуны искәртү мөһим: шарт фигыль кушма җөмләләрдәге иярчен җөмләнең генә хәбәре булып килә ала.

Тезмә фигыль хәбәрләрнең ике төрен күрсәтергә була.

1. Кайбер исемнәргә, сыйфатларга, саннарга һ.б. фигыль булмаган сүз төркемнәре сүзләренә ярдәмче фигыльләр кушылып ясала:

Мәсәлән: *Алар бәйрәм итә* (исем+ *ит* ярд. фигыле).

*Дошманнарны юк иттек* (хәб.сүз+*ит*).

*Ул һаман үзенекен итә* (алм.+*ит*).

Боларга тагын *һәлак булу, дәвам итү, мыскыл итү, тәкъдим итү, риза булу* һ.б. керә.

2. Идиоматик төзелмәләрдән торган фигыльләр тезмә фигыль хәбәр барлыкка китерәләр (фразеологик әйтелмәләр).

*Як-ягына күз салды* (Г. Бәширов).

*Зурайган саен акылга утыра* (М. Әмир).

*Кичен чәчәк аткан була, ә таңында инде коела* (Һ. Такташ).

*Хәлимнең эченә җылы керде* (И. Гази).

*Таңга калсын тиречеләр, итчеләр* (Г. Тукай).

Кушма фигыль хәбәрләр, кимендә, ике сүздән тора һәм тезмә фигыль хәбәрдән аермалы буларак, төп сүзе фигыль белән бирелергә тиеш һәм хәбәр составындагы сүзләр идиома барлыкка китермәскә тиешләр (гади генә әйткәндә, кимендә 2 сүздән торып, тезмә фигыль хәбәргә кермәгән хәбәрләр кушма фигыль хәбәрләр булалар).

Мәгънәләре буенча төрләре бик күп.

1) шартны белдерә торган кушма фигыль хәбәрләр:

*Җир җиләге белән мине иркәм сыйласа иде* (Ф. Кәрим).

2) теләкне белдерә торган кушма фигыль хәбәрләр:

*Йөгереп китәрдәй булам да, кайтып җитәрдәй булам* (Җыр).

3) үтенүне белдерә торган кушма фигыль хәбәрләр:

*Син үзең төзәткән булсаң*. (озакка чыдаган булыр иде).

4) эшнең ничек һәм ни дәрәҗәдә үтәлүен белдерә торган кушма фигыль хәбәрләр (фигыль дәрәҗәләре):

- башлану дәрәҗәсе: *Студентлар яза башладылар*.
- кабатлау: *Ул килгәләп тора*.
- тәмамлану дәрәҗәсе: *Күргәннәрне сөйләп бетердем*.
- кинәтлек дәрәҗәсе: *Бик еракта пароход кычкырып куйды һ.б.*

**Исем хәбәрләр**

Гади исем хәбәрләр фигыльдән башка төрле сүз төркемнәре белән бирелеп, бер генә сүздән тора:

*Син минем бәхетем.* (исем)

*Син бүген бай, бәлки, шайтаннан да ярлы иртәгә* (Г. Тукай). (сыйфат)

*Бүре башы бит унике* (Г. Тукай). (сан)

*Араларыбыз – ерак*. (рәвеш)

*Ничек соң тормышың, Ничек көнкүрмешең?*(Г. Тукай) (алм.)

*Бар да бар, тик юк туганнар.* (хәб.сүз)

Тезмә исем хәбәрләр фигыльдән башка сүзләр белән төзелгән тезмә сүзләр белән бирелергә мөмкин.

*Бу бина – Казан дәүләт университеты.*

*Бу үлән – үги ана яфрагы.*

Шулай ук контекстта аерым кисәкләргә таркалмый торган синтаксик сүзтезмәләр белән дә бирелергә мөмкин:

*Өйләре – калай түбәле.*

*Сабан туе – яз бәйрәме.*

*Безнең урам – зур урам.*

*Бердәнбер якын кешем - әни карчык* (Г. Әпсәләмов).

Кушма исем хәбәрләр берничә төрле юл белән биреләләр.

1) фигыльдән башка сүз төркемнәренә **иде, икән, бул** ярдәмче фигыльләре кушылып ясала:

*Көн салкын иде.*

*Сары чәчлесе ул – мин идем* (Һ. Такташ).

*Монда хәлләр кызык икән.*

2) төрле бәйлекләр ярдәмендә ясала:

*Сагынганда айга карыйм, ай да гел синең төсле.*

*Көн салкын кебек.* (шикелле, төсле)

*Һәр таш миңа таныш сыман* (Зөлфәт).

3) *түгел* сүзе ярдәмендә:

*Артык дан кирәк түгел.*

*Үзе болай бер дә усал түгел кебек шикелле* (Һ. Такташ).

*Төз түгел куллар, аяклар* (Г. Тукай).

4) модаль сүзләр ярдәмендә:

*Ул укытучы бугай. (ахры, ич, шул һ.б.)*

### 6.2. Гамәли биремнәр.

**1 нче бирем.** Җөмләләрнең баш кисәкләренең асларына сызыгыз, төрләрен билгеләгез.

*Урман тып-тын. Ямь-яшел наратлар арасыннан, чәчелешеп яткан күркәләргә баса-баса, эчкә узабыз. Сизелер-сизелмәс кенә искән иртәнге җил Камадан салкын өрә. Шиңеп бетә язган ромашкалар чугында салкын чык җемелди. Чалбар балакларыма ябышкан быелгы яфракларны, чүп-чар, черегән агач тузанын сыпырып-сыпырып төшерәм.*

*Әтинең яраткан аланына килеп чыгабыз. Түрдә чыршы утыра. Аның янәшәсендә үк усакның сары яфраклары лепердәшә. Каен инде шәрәләнеп бетә язган. Кояш нурлары аның соңгы яфракларын җылыта. Каен шул хәлсез яфракларын саклап калырга, аларга яшеллек сеңдерергә теләгәндәй, җилдән ышыкланырга тырышып, чыршыга таба авышала* (Р. Бәшәр).

**2 нче бирем.** Баш кисәкләр арасына тыныш билгеләрен куегыз, ия белән хәбәрләрнең төрләрен билгеләгез.

*Мәңгелек безнең изге җиребез, зәңгәр планетабыз. Мәңгелек безнең зәңгәр күгебез, мәңгелек нурлы кояш, ягымлы-ягымлы ай, гомеребезне бизәп, бәйрәм ясап балкыган сансыз-исәпсез йолдызлар. Безнең күңелләргә Бетховен, Шаляпин, Григлар да иркен керә, океан-диңгезләр, елга-*

*дәрьялар, Кавказ-Кырым таулары да сыя, алар да синеке, син – кеше, синең күңелең күпне тели, күпне үз итә ала* (А. Гыйләҗев).

## 6.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар.

1. Җөмлә кисәкләре нинди төрләргә бүленә?
2. Җөмләнең баш кисәкләренә нәрсәләр керә?
3. Җөмлә кисәкләрен кем ничек тикшергән?
4. Нәрсә ул ия?
5. Иягә нинди сыйфатлар хас?
6. Ия нинди төрләргә бүленә?
7. Ия нинди сүз төркемнәре белән белдерелә?
8. Нәрсә ул хәбәр?
9. Хәбәргә нинди сыйфатлар хас?
10. Хәбәр нинди төрләргә бүленә?
11. Хәбәр нинди сүз төркемнәре белән белдерелә ала?
12. Исем хәбәр белән фигыль хәбәрнең аермасы нидә?
13. Гади, тезмә һәм кушма исем хәбәрләр бер-берсеннән ничек аерыла?
14. Гади, тезмә һәм кушма фигыль хәбәрләр бер-берсеннән ничек аерыла?
15. Ия белән хәбәр нинди очракларда ярашал Ия белән хәбәр нинди очракларда ярашалар?

**6.4. Презентация.**

**7.**
**Лекция № 5**

- **Иярчен кисәкләр. Иярчен кисәкләрне өйрәнү тарихы. Аергыч. Тәмамлык, аның төрләре. Хәл, аның төрләре. Аныклагыч. Модаль кисәкләр.**

**Аңлатма.** Әлеге тема җөмләнең иярчен кисәкләре турында аңлатма бирә. Аергыч, тәмамлык, хәл һәм аныклагычның төрләрен аерырга өйрәтә. Модаль кисәкләр хакында мәгълүмат бирә.

**Иң мөһим төшенчәләр.** Җөмләнең иярчен кисәкләре, аергыч, тәмамлык, хәл, аныклагыч, эндәш һәм кереш сүз.

**Методик киңәшләр.**

•Тема теоретик мәгълүматны үз эченә алган лекциядән гыйбарәт;

•Мөстәкыйль эш өчен гамәли биремнәр тәкъдим ителә;

•Теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү максатыннан, теоретик сораулар бирелә.

•Лекция презентация белән үрелеп бара.

**7.1. Иярчен кисәкләр. Иярчен кисәкләрне өйрәнү тарихы. Аергыч. Тәмамлык, аның төрләре. Хәл, аның төрләре. Аныклагыч. Модаль кисәкләр.**

К. Насыйри иярчен кисәкләрне икегә бүлгән (ачыклагычлар, тәмамлагычлар). Беренче төркемгә иялек килеше белән белдерелмәгән аергычлар һәм хәлне; икенче төркемгә тәмамлыклар һәм иялек килеше белән белдерелгән аергычларны кертә (Әнмүзәҗ, 1895). Василий Алексеевич Богородицкий (1857-1941) иярчен кисәкләрне шулай ук 2 төркемгә аерган (аергыч, тәмамлык).

Г. Алпаров аергыч, тәмамлык һәм ачыклау дигән иярчен кисәкләрне аерып чыгара. Аергычларга исемгә бәйләнгән иярчен кисәкләрне кертә (бу хәзер дә шулай). Фигыльгә, ярдәмлекләргә бәйләнеп килгән кисәкне

тәмамлык дип атый. Сыйфатка бәйләнеп килә торганнарын “ачыклаулар” дип күрсәтә.

М. Корбангалиев иярчен кисәкләрне өчкә бүлә: аергыч, тәмамлык, хәл. Вәли Нигъмәтуллович Хангилдин (1891-1971), М.З. Зәкиев тә шушы өч иярчен кисәкне һәм аныклагычны күрсәтәләр. Дөрес, 1959 елда басылган “Татар грамматикасында” В. Хангилдин “өстәмә сүз” дигән термин да куллана (*Мин үзем, без укытучылар*) һәм аларны аергычларның бер төре дип карый. Тәмамлыкларны төшем, юнәлеш, чыгыш, урын тәмамлыкларына бүлә. *Белән* бәйлеге белән килгән тәмамлыкларны “катнашлык тәмамлыгы” дип атый, мәсәлән: *директор белән аңлаштык*

Бүгенге көндә дә, кайбер очракларда, теге яки бу иярчен кисәкнең аермасын табу кыенлык тудыра.

*Мин **сезгә** барам.* (урын хәле дип карала)

*Мин **сезгә** ышанам.* (тәмамлык)

*Мин **сездән** китәм.* (урын хәле)

*Мин **сездән** куркам.* (тәмамлык)

*Мин **сездә** утырдым*. (урын хәле)

*Мин **сездә** бер борчылу сиздем.* (тәмамлык)

Бу мисаллардан күренгәнчә, бер үзенчәлек бар: ияртүче сүзе хәрәкәт, кыймылдау төшенчәсен бирә торган сүзләр (фигыльләр) булсалар *(барам, киләм, утырам)* – бу сүзләрне *(сезгә, сездән, сездә)* урын хәле дип алырга мөмкин.

Ияртүче сүзе хәрәкәтне белдерми, хис-тойгыларны белдерсә *(ышанам, куркам, сиздем)*, бу сүзләр тәмамлык булалар.

Ләкин бу бүленеш фәнни принципка нигезләнми. Г. Алпаров, шуңа күрә булса кирәк, хәлләрне һәм тәмамлыкларны бергә туплап карарга тырышкан.

**Аергыч**

Җөмләнең исем яки предмет төшенчәсен атый торган башка кисәгенә ияреп, шул предметның билгесен, санын, кемгә (нәрсәгә) каравын белдерә торган иярчен кисәк **а е р г ы ч** дип атала.

Мәсәлән: *Зәңгәр-аксыл болытлар һәр җәйне киң кырларга яңгырлар ташыдылар.* Аергыч ачыклап килгән сүзне **аерылмыш** диләр. Төрки телләрдә шул исәптән татар телендә дә аергычлар күп төрле сүз төркемнәре белән бирелә алалар.

1. Исем белән бирелгән аергычлар:

*Зиннәтнең гармун тавышы ишетелә.* (аерылмышка иялек кил. куш. белән бәйләнгән)

*Хәйдәрнең аты булган.* (аерылмышка иялек кил. куш. белән бәйләнгән)

*Бакча капкасы янында очраштык.* (янәшәлек һәм тартым)

*Тимер мич кызу ягылган.* (янәшәлек)

*Ике арада кечкенә ишек кебек капка да бар.* (*кебек* бәйлеге)

2. Сыйфатлар белән бирелгән аергычлар:

*Алсу йөзе белән килде кеше, саф йөрәге белән шатланды.* (янәшәлек)

*Ике тәрәзәле өй күренде.* (*-ле* ясагыч кушымча ярд.)

3. Рәвешләр белән бирелгән аергычлар:

*Гөлстандай илгә дошман керде.* (*-дай* рәв. ясагыч кушымча)

*Борын заман бер ир белән хатын торган.* (янәшәлек)

4. Саннар белән бирелгән аергычлар:

*Ун танк, унбишләп машина, өч-дүрт пушка санады.* (янәшәлек, *-ләп*)

5. Хәбәрлек сүзләр белән бирелгән аергычлар:

*Юк сүз сөйләмә.* (янәшәлек)

*Кирәк кадәр мал бирермен.* (кадәр бәйлеге)

6. Алмашлыклар белән бирелгән аергычлар

*Безнең авыл зур авыл. (иялек килеш. куш.)*

*Билгеле бу кап-кара урманда ерткыч та бар. (янәшәлек)*

*Бер җирдә юк андый урманнар.*

7. Фигыльләр белән (бик күп очракта сыйфат фигыль) бирелгән аергычлар:

*Баскан эзем җирнең күкрәгендә югалмаслык булып калса иде.*

*Җырланасы җырлар алда әле һ.б.*

Кайбер дәреслекләрдә иялек килешендәге теләсә кайсы сүз аергыч була дип белдерелә. Әгәр сүз исемне ачыкласа, бу кагыйдә дөрес, ләкин фигыльне ачыклаганда, ул тәмамлык булып саналырга тиеш.

*Аның сүзләрендә хаклык бар.*

*Аның болай әйтүендә хаклык бар.*

*Аның тизрәк төп сүзгә күчәсе килде* (Н. Фәттах).

Татар телендә тиңдәш һәм тиңдәш түгел аергычлар бар. Тиңдәш аергычлар үзләре ияреп килгән сүзне бары тик бер генә яктан ачыклыйлар, һәм, тезүче теркәгечләр булмаганда, тиңдәш аергычлар арасында өтер куела.

*Бу тавышлар старостаның болай да нечкә, зәгыйфь тавышын бөтенләй күмеп китәләр иде* (Ф. Хөсни).

Тиңдәш түгел аергычлар исемне төрле яктан ачыклыйлар, һәм алар арасына өтер куелмый.

*Тыгыз соры болытлы күк гөмбәзеннән кыр казлары китеп бара* (М. Мәһдиев).

**Тәмамлык**

Җөмләнең процесс белдерә торган сүз белән бирелгән теләсә кайсы кисәгенә ияреп, процессның объектын, үтәүчене, нинди дә булса бер хәл кичерә торган әйберне белдерә торган иярчен кисәк **т ә м а м л ы к** була.

Тәмамлыкларның 2 төре бар (туры һәм кыек тәмамлыклар).

Әгәр тәмамлык процесс турыдан туры кагыла торган әйберне, төшенчәне белдерсә, **туры тәмамлык** дип атала.

- Төшем килеш кушымчасы ярдәмендә бәйләнергә мөмкиннәр.

*Бал татлы дип бармакны йотмыйлар* (Мәкаль).

*Мылтыгымны кысып тотам, көчле минем беләгем.*

*Бар җырымны илгә багышладым* (М. Җәлил).

*Казан урамнарын ташлап китәм* (Һ. Такташ).

- Янәшә тору ярдәмендә бәйләнәләр:

– *Тәрәзә ачтым, җимнәр сиптем*

*Килегез кошкайларым* (Җыр).

- Чыгыш килеше белән бәйләнергә мөмкиннәр:

*Бер пуля аның башыннан яралады.*

*Ул аны якасыннан эләктерде.*

*Үзегез яраткан коймактан авыз итегез* (Г. Әпсәләмов).

- Бәйлекләр белән килергә мөмкиннәр:

*Гаризасына кадәр язып китергәннәр.*

- Инфинитив туры тәмамлык булып килә:

*Укытучы керергә кушты.*

*Ул мактанырга ярата.*

Тәмамлык процесс турыдан-туры кагылмый торган әйберне, затны белдерсә, **кыек тәмамлык** була.

- Бәйлекләр белән килгән тәмамлыклар:

*Безнең Гали бигрәк тату кәҗәгә белән* (Г. Тукай).

*Газизә ире өчен үлеп тора* (Ә. Фәйзи).

- Төрле килеш кушымчасы белән:

*Мондый вак-төякләргә игътибар итмибез.*

*Галинең дә безгә киләсе бар.*

**Хәлләр**

Җөмләнең фигыль, сыйфат, рәвеш һәм процесс белдерә торган башка сүзләр белән бирелгән кисәгенә ияреп, процессның яки билгенең билгесен, яисә процессның үтәлү рәвешен, вакытын, урынын, юнәлешен, максатын, сәбәбен, шартын, күләмен белдерә торган кисәкләр **х ә л** дип йөртеләләр.

Хәлләр мәгънәләре буенча 8 төргә бүленәләр.

– Процессның үтәлү яки билгенең булу урынын белдерә торган хәл **урын хәле** дип атала.

*Киткән урманга утынга.* (исем)

*Җил кайдан иссә, болыт шуннан килә.* (алмашлык)

*Кояш югары күтәрелгән.* (рәвеш)

Урын хәлләре шулай ук бәйлек һәм бәйлек сүзләр белән дә килергә мөмкин.

*Агач өстендә табак, табак өстендә кибет,*

*Кибет эчендә бер егет* (Табышмак).

– Процессның үтәлү, үтәлмәү яки билгенең булу булмау вакытын белдерә торган кисәк **вакыт хәле** дип атала.

Исемнәр белән белдерелә: *Яз кайтмасак, көз кайтырбыз.*

Фигыльләр белән: *Куаналар өч-дүрт бүре, моны күргәч,*

*Алларына сарык белән кәҗә килгәч.*

Рәвешләр белән: *Җәен соры, кышын ак (*Табышмак).

*Хәзер эшләр җәйланды.*

Бәйлек һәм бәйлек сүзләр ярдәмендә: *Сезгә хат язарга утыру белән, кинәт, хат язуны артык зур бер эш дип санадым* (Һ. Такташ).

**Сәбәп хәле** – процессның үтәлү-үтәлмәү яки билгенең булу-булмау сәбәбен белдерә торган кисәк.

Бәйлекләр һәм башка ярдәмлекләр белән бирелә:

*Озак йөрү сәбәпле, ул арып кайтты.*

*Ялкаулыгы аркасында, белми калган.*

Фигыльләр белән:

*Аһ, оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә* (Г. Тукай).

*Белмәгәч сөйләмәдем.*

**Максат хәле** – процессның үтәлү-үтәлмәү, билгенең булу-булмау максатын белдерә торган кисәк.

*Киткән урманга утынга.* (исем)
*Шәһәргә укырга килгән.* (фигыль)
*Эшләргә дип килгән.* (фигыль+ярд.сүз)
*Җиңү өчен ант итәләр.*(фигыль + бәйлек)

**Рәвеш хәле** – процессның ничек һәм ни рәвешле үтәлүен яисә нинди дә булса бер хәлнең яки билгенең билгесен, сыйфатын белдерә торган кисәк.

*Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата.* (рәвеш)
*Ник, Мокамай, соң син тормышыңны чабатадай матур үрмәдең.* (сыйфат)
*Моңланып-хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата.* (фигыль)
*Кигән кием ничек туза, яшь гомер шулай уза.* (алмашлык)
*Тир белән тапсын ашарын.* (исем+бәйлек)

*Тау башында салкын чишмә челтер-челтер агадыр.* (аваз ияртеме)

**Күләм хәле** процессның яки билгенең күләмен, дәрәҗәсен белдерә (В. Хангилдин "микъдар хәле" дип атаган).

*Бер карадым күзләреңә, икенче йөзләреңә.* (сан)
*Күп күрдем мин филдәй кешеләрне.* (рәвеш)
*Безнең Гали бигрәк тату.* (рәвеш)
*Миңлебай ул берүзе өч кеше хәтле эшли.* (исем+бәйлек)
*Никадәр укысаң, шулкадәр белемең артыр.* (алмашлык)

**Шарт хәле** – ияртүче кисәктән аңлашылган процессның үтәлү-үтәлмәвенә шарт булып тора торган процессны белдерә торган кисәк.

*Китсәм кайта алмам инде.*
*Барам икән күрәм.*

**Кире хәл** ияртүче кисәктән аңлашылган процессның киресе булганын белдерә.

*Сүз юктан сүз чыгарып булса да, үзара сөйләшәбез* (М. Әмир).

*Бер тәүлек йокламавына карамастан, буыннарына гаҗәп бер көч җыела барганын тойды* (Г. Ибраһимов).

### Аныклагыч

Ияртүче кисәктән соң килеп, аңа аныклык кертә торган кисәк **а н ы к л а г ы ч** дип атала. Аныклагычлар җөмләдә төрле сүз төркемнәре белән бирелгән төрле кисәкләрнең мәгънәләрен аныклап, төгәлләп киләләр. Башка иярчен кисәкләр, төгәлләүле мөнәсәбәткә нигезләнеп, җөмлә оештыруда 2 нче дәрәҗәдәге рольне уйнасалар; аныклагычлар, аныклаулы мөнәсәбәткә нигезләнеп, 3 нче дәрәҗәдәге рольне уйныйлар.

XX гасырның ≈ 60 елларына кадәр аныклагычлар аерым бер җөмлә кисәге буларак өйрәнелмиләр. 1954 елда басылып чыккан "Татар теле грамматикасында" (авторлары: М. Корбангалиев, Х. Хисматуллин) алар аергычларның бер формасы буларак карала. 1956 нчы елда басылган

“Татар телендә тыныш билгеләре” (К. Сабиров) китабында “өстәмә сүзләр” дип, ә алар ачыклап килгән сүзләрне “өстәлмешләр” дип күрсәтә. Монда “өстәмә сүз” рус телендәге “приложение” белән дә тәңгәлләштерелә. Мәсәлән, рус телендә *девочки-подростки, женщины-колхозницы, инженер-механик*. Татар телендә шуларга туры килгән мисаллар китерелә:

*Нишлим, сугыш дустым-пистолетым*

*Соңгы сүздән кинәт баш тартты* (М. Җәлил).

Ләкин рус телендәге югарыда күрсәтелгән мисаллардагы приложениеләр татар телендә гади аергычка әйләнәләр (*үсмер кызлар, колхозчы хатын-кызлар* һ.б.) яки икесе бер лексик берәмлек буларак кабул ителәләр (*инженер-механик, интернат-мәктәп*). Татар телендә приложениегә туры килә торган кисәк юк.

Кайбер элеккеге грамматикаларда аныклагычны аерым җөмлә кисәге итеп карамауда аның аныкланмыш белән бер үк сорауга җавап бирүен төп сәбәп итеп күрсәтәләр. (Г. Алпаров) – “Үзенә генә хас синтаксик функциясе юк” – диелә.

Димәк, аныкланмыш нинди җөмлә кисәге булса, аныклагыч та шул ук җөмлә кисәге була. Ләкин алар икесе бер үк төрле сорауга җавап бирмиләр (алай булса алар тиңдәш кисәкләр булырлар иде).

Мәсәлән:

*Сөйләшә ул төшләрендә күреп*

*Искәндәрен – батыр баласын* (Ш. Маннур) дигән җөмләдә *Искәндәрен* сүзе *“төшләрендә күреп”* тезмәсенә буйсына һәм *кемне*? – соравына җавап бирә, ә *“батыр баласын”* кисәге исә берьюлы ике кисәккә иярә: *“Төшләрендә күреп” кемне*? – *батыр баласын* һәм *Искәндәрен* сүзенә дә ияреп, *“ягъни кемне?”* соравына да җавап бирә.

Димәк, аныкланмыш белән аныклагыч икесе ике төрле функцияне үтиләр, шулай булгач, аныклагыч – җөмләнең аерым бер иярчен кисәге. Татар грамматикаларында В. Хангилдин, М.З. Зәкиев һ.б. галимнәр аныклагычларны шулай күрсәтәләр дә.

Кайсы сүз төркемнәре белән бирелүенә карап, аныклагычларны 2 төркемгә бүләләр.

1. Фигыльләр белән бирелгән аныклагычлар:

*Кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә* (Г. Тукай).

*Дөнья мине үзгәртте: еламаска өйрәтте* (Х. Туфан).

2. Фигыльдән башка сүзләр белән бирелгән аныклагычлар:

*Ә шул чак мин, авыл сабые,*

*Гел көткәнмен Апуш абыйны* (М.Хөсәен).

Аныклагычларны шулай ук аныкланмыш белән ярашкан яки ярашмаган төрләргә дә бүләләр. Ярашкан аныклагыч аерымланып, ярашмаганы аерымланмыйча килә.

*Урман кызы умырзаяны искә төшерде.* (ярашмаган);

*Һәйкәл күк торадыр Ак аю, үз иле Котыпны күзәтеп* (Ә. Фәйзи). (ярашмаган)

*Бармак белән каткан җирне казып булмый.*

*Әлифбасыз (алфавитсыз) язып булмый* (Г. Тукай).

*Мин озаттым аны сугышка, йөрәгемнең сүнмәс кояшын* (М. Җәлил). (ярашкан*)*

Төзелешләре белән аныклагычлар ике төргә бүленә.

1. **Ялгыз аныклагычлар.** Алар бер мөстәкыйль мәгънәле сүздән тора.

*Баламны – бердәнберемне – миңа күрсәтмәс өчен, әлләниләр кыланалар* (Ә. Рәшит).

*Газета актара торгач, башваткыч табып, каләм алып, түр якка, гаилә янына, чыкты* (“Татарстан яшьләре”).

2. **Җәенке аныклагычлар.** Бу очракта аныклагыч берничә мөстәкыйль мәгънәле сүздән тора.

*Әллә кайдан, бөтенләй уйламаган яктан, вак-вак кына болыт кисәкләре кабарып чыкты* (Ф. Хөсни).

## Модаль кисәкләр

Модаль кисәкләрнең синтаксик статусын билгеләүдә төрле карашлар яшәп килә. Шактый еллар буе эндәш һәм кереш сүзләр җөмлә кисәге буларак танылмады. Рус теле белемендә модаль кисәкләрне җөмләдән аерып караучылар арасында А.А. Шахматов, А.М. Пешковский һ.б. бар.

Татар тел белемендә бу караштa торучы галимнәрнең (Җ. Вәлиди, М. Корбангалиев, Х. Бәдигый, Г. Алпаров, В. Хангилдин) үз фикерләрен исбатлау өчен китергән төп дәлилләре мондый: эндәш һәм кереш сүзләр җөмләдәге башка кисәкләр белән грамматик яктан бәйләнми. Г. Алпаров, мәсәлән, болай ди: “Җөмлә эчендә ни берәр кушымча, яки ярдәмлек сүз белән, ни бер тәртип белән үзеннән соңгы сүзгә бәйләнмичә, аерымрак бер тавыш белән әйтелгән сүзләр дә булырга мөмкин. Боларның башка сүзләргә һичбер төрле бәйләнеше булмаганга күрә, җөмлә кисәге булып саналырга хаклары юк”.

Бу карашны яклаучы галимнәрнең тагын бер дәлиле: бу кисәкләрне төшереп калдырсаң да, җөмлә үзгәрми, җөмләлек саклана.

Эндәш һәм кереш сүзләрне җөмлә кисәге итеп каручы галимнәр арасында да аларны җөмлә кисәкләренең кайсы төренә кертү мәсьәләсендә карашлар төрлелеге күзәтелә. Г. Ибраһимов, татар теле белемендә беренче буларак, эндәш һәм кереш сүзләрне җөмлә кисәге итеп таный һәм иярчен кисәкләргә кертә (алда әйтелде).

Татар теле белемендә генә түгел, ә төрки тел белемендә беренче булып М.З. Зәкиев эндәш һәм кереш сүзләрне җөмләнең модаль кисәкләре икәнлеген исбатлый.

Беренче концепцияне яклаган галимнәрнең “Эндәш һәм кереш сүзләр башка җөмлә кисәкләренә грамматик юл белән бәйләнми” дигән карашка каршы, М.З. Зәкиев: “Эндәш һәм кереш сүзләрне җөмләнең калган өлеше белән бәйли торган төп чара – үзенчәлекле интонация,” – дип яза (эндәш сүзләрдә - эндәшү интонациясе).

Бу тышкы бәйләнеш (форма ягыннан); эчке, ягъни мәгънәви яктан да эндәш һәм кереш сүзләр җөмлә белән органик рәвештә бәйләнә, чөнки модаль мөнәсәбәттән башка җөмлә була алмый (искә төшерегез: хәбәрлек һәм модальлек – җөмләнең төп үзенчәлекләре). Ә эндәш һәм кереш сүзләр бу мөнәсәбәтне белдерүнең бер формасы.

Ә эндәш һәм кереш сүзләрне төшереп калдырсаң да җөмлә саклана, - диючеләргә шуны әйтергә була: гомумән җөмләлек саклана... Ләкин җөмлә шул килеш сакланмый, автор әйтергә теләгән фикерне бирә алмый.

Мәсәлән: *Әйтче, зинһар, мәрхәмәтсез, кем син, исемең кем синең?* (Г. Тукай)

(автор *мәрхәмәтсез* дигән эндәш сүзгә күпме хис-тойгы салган; *“зинһар”* дигән кереш сүзгә шулай ук)

Күргәнебезчә, эндәш һәм кереш сүзнең синтаксик статусын билгеләүдә төрле карашлар яшәп килә. Хәзерге татар теле белемендә М.З. Зәкиев тарафыннан эшләнгән концепция кабул ителгән. Шулай итеп, эндәш һәм кереш сүзләр җөмләгә эчтәлек ягыннан да, форма ягыннан да органик бәйләнгән тулы хокуклы кисәкләр булалар һәм алар җөмләнең модаль кисәкләре исеме астында өйрәнеләләр.

**Эндәш сүзләр**

Сөйләм төбәлгән затны, әйберне, күренешне белдергән сүзләр **эндәш сүзләр** дип атала.

Эндәш сүзләр баш килештәге исем, яки исемләшкән сүзләр, сирәгрәк алмашлыклар белән белдерелә. Җөмләдәге урыны ирекле. Рус синтаксистларына ияреп, җөмләдәге урынына бәйле рәвештә эндәш сүзләрне

– **препозицион** (җөмлә башында килгән);

– **интерпозицион** (җөмлә уртасында килгән);

– **постпозицион** (җөмлә ахырында килгән) төрләргә бүләләр.

Җөмлә башында килгән эндәш сүзләр кайбер очракларда мөстәкыйль мөрәҗәгать җөмлә (вокатив җөмлә) барлыкка китерәләр.

Мәсәлән: *Кадерле туган-үскән җирем! Көчле егетләрең бар да китеп беткәч, сиңа күңелсез булгандыр* (М. Максуд).

Галимнәр тарафыннан эндәш сүзләрнең адресатны характерлау сыйфаты да карала. Җ. Вәлиди: “Сөйләмдә эндәш сүзләр, нигездә, кешенең игътибарын җәлеп итү өчен кулланылсалар да, кайбер очракларда эндәш сүз белән тыңлаучының берәр сыйфатын әйтү, аны хурлау яки мактау да күздә тотыла”, - ди.

*И җүләр, кысканга былтыр, кычкыралармы быел* (Г. Тукай).

Эндәш сүзләрне гомум кулланышка туры килү-килмәү ягыннан икегә бүлеп карап була.

1 – узуаль (гомум кулланылышка туры килә торган мөрәҗәгать номинацияләре):

*И сабыйлар, эшләгез сез* (Г. Тукай).

2 – оккозиональ (кайбер кешеләр генә файдалана торган, гомум кулланылышта булмаган эндәш сүзләр):

*Синең өчен утка керәм, җан алмам* (М. Әмир). (Басыйр Фатыймага сәламен җырга салып җибәрә)

Эндәш сүзләрнең бирелеше:

1. Исем сүз төркеме белән:

а) эндәш сүз буларак антропонимнар кулланыла (кеше исемнәре):

*Юк, Гөлчәчәк, сине онытмам*

*Мин җыр язам сиңа фронттан* (Ф. Кәрим).

б) эндәш сүз буларак туганлык терминнары (*әти, әни, энем, сеңлем, апа, абый, әби, бабай, кияү, килен, җизни, балдыз* һ.б.):

Алар үзләре генә дә, исемнәргә кушылып та киләләр.

*Яз, газиз угълым, кара тактаны сыз акбур белән* (Г. Тукай).

Татар телендә берничә булган бер төрле туганны аеру өчен эпитет-аергычлар да кулланыла (*алма апа, дәү апа, дәү абый, ерак әби, олы җиңги, Миңгәр бабай* һ.б.).

в) адресантның яшенә һәм җенесенә караган мөрәҗәгать номинацияләре (*туташ, ханым, егет, кызый, яшьтәш, кардәш, малай, сабый* һ.б.):

*Батыр егет, атың җилкәсендә көннәр буе инде киләсең* (Һ. Такташ).

г) адресантның һөнәр-кәсебенә, эшенә, хезмәт урынына, вазифасына караган мөрәҗәгать сүзләр (*табиб, солдат, профессор, депутат, директор, полковник* һ.б.):

*Иптәш полковник, утырыгыз.*

д) яшәгән-торган урынга, нинди дә булса уртаклыкка бәйле атамалар (*авылдаш, юлдаш, хезмәттәш, классташ, милләттәш, адаш* һ.б.):

*Кадерле милләттәшләр, 7 майда барыгыз да митингка!*

е) кош-корт, хайваннарны атый торган сүзләр:

- аларның үзләренә атап әйтү:

*И кошым, син мескенем, син чыпчыгым*

*Мин сөйләим, тыңла сүземнең чып-чынын* (Г. Тукай).

- кешеләргә карата әйтелә (*сандугачым, былбылым, асылкошым, карлыгачым* һ.б.):

*Күбәләгем-түгәрәгем, асыл кошым, сандугачым*

*хатлар көтәмен синнән* (Ф. Кәрим).

2. Исемләшкән сыйфатларның эндәш сүз булып китүе (*гүзәлем, чибәрем, аппагым, акыллым, кадерлем* һ.б.):

*Бир кулыңны, гүзәлем,*

*Синсез өзелә үзәгем* (Җыр).

3. Исемләшкән фигыльләрнең эндәш сүз булып килүе (*үскәнем, сөйгәнем* һ.б.):

*Үскәнем, бар, кереп йокла инде.*

4. Исемләшкән саннарның эндәш сүз булып килүе:

*Бөрлегәнем, бөрлегән, сагындырдың, бергенәм* (Җыр).

5. Алмашлыклар белән белдерелгән эндәш сүзләр (*сез, син, кем*):

*Зәңгәр күзле егет кунак итеп сезне чакыра, әй, сез!*

*Ишетәсезме?* (Һ. Такташ).

6. Җансыз предметларны, әйберләрне, табигать күренешләрен атый торган эндәш сүзләр:

*Җырларым, сез шытып йөрәгемдә...* (М. Җәлил).

*Сау булыгыз, кырлар,*

*Хәзер инде минем күңелем шәһәр кулында* (Һ. Такташ).

*Сау бул инде, хуш, бәхил бул*

*И минем торган җирем* (Г. Тукай).

*Хуш, гомер иткән шәһәр, инде еракта калдыгыз!*

*Аһ, таныш йортлар, тәмам күздән дә*

*сез югалдыгыз* (Г. Тукай).

**Кереш сүзләр**

Җөмләдә белдерелгән фикергә карата сөйләүче яки язучының ныклы ышанычын, шикләнүен, ризалыгын – риза түгеллеген, фикерләрнең тәртибен, чыганагын, эмоциональ-экспрессив бәясен һәм башка төрле мөнәсәбәтләрне белдерә торган сүзләр **кереш сүзләр** дип атала.

Нинди сүз белән бирелүенә карап, кереш сүзләр 2 төркемгә бүленәләр.

I. Теге яки бу сүз төркеменнән аерылып, башлыча кереш сүз булып йөрүгә күчкән һәм морфологиядә модаль сүзләр дип йөртелә торган сүзләр белән бирелгән кереш сүзләр: (*ниһаять, әлбәттә, ахрысы, димәк,*

*ихтимал, зинһар, бәлки, янәсе, һичшиксез, гомумән, ягъни, мәсәлән, имеш* һ.б.):

*Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк* (Г. Тукай).

*Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр* (Ф. Кәрим).

II. Икенче төр кереш сүзләр теге яки бу сүз төркеме белән арасын өзмәгән сүзләр белән яки ияртүче кисәге шундый сүз булган сүз тезмәләре белән бирелгән сүзләр керә. Берничә төре бар.

а) исем белән бирелгән кереш сүзләр (*бәхеткә каршы, оятка каршы, нигездә, нәтиҗәдә*):

*Укытучылар, нигездә, барысы да килделәр.*

б) сыйфатлар белән бирелгән кереш сүзләр (*билгеле, табигый, кыскасы*):

*Билгеле, бу кап-кара урманда һәр ерткыч та бар* (Г. Тукай).

в) алмашлыклар белән бирелгән кереш сүзләр (*никтер, ни өчендер, әллә ничек*):

*Очырмакчы булсам былбыл күкрәгемнән,*

*Әллә ничек, мыр-мыр итеп мәче чыга* (Г. Тукай).

г) рәвешләр (*минемчә, белгәнемчә, дөрес, аеруча, өлешчә*):

*Минемчә, иң ышанычлы юл - әйләнчек юл* (А. Шамов).

д) фигыль (*күрәсең, әйтик, җитмәсә*):

*Күңел ул, күрәсең, 15 тә дә, 35 тә дә шул ук күңел* (Ш. Камал).

е) сан (*бердән, икенчедән*):

*Бердән, су бик тирән, икенчедән, салкын, өченчедән, йөзә белмим* (М. Әмир).

В. Хангилдин ымлыкларны да кереш сүзләрнең бер төренә кертә. Мисал: *Ах, бу нинди аерылу, гомеремдә бер тапкыр күрәм.*

Ләкин хәзерге граматикада ымлыклар җөмлә кисәге буларак каралмаган.

Кереш сүзләрне мәгънә ягыннан төркемләү:

1) авторның сөйләмдә белдерелгән фикергә ышанып, икеләнмичә каравын, шуны раславын белгертә торган кереш сүзләр (*әлбәттә, һичшиксез, шөбһәсез, бәхәссез, билгеле, дөрес, чыннан да*):

*Алдагы көзгә арыш, һич шөбһәсез, булыр чибәр* (Г. Тукай).

2) өметләнү, чамалау яки икеләнү, шикләнү, мөмкин санау кебек төсмерләрне белгертә торган кереш сүзләр (*бәлки, ихтимал, мөгаен, ахры, күрәсең, икән, шаять*):

*Инде, шаять, бер сәгатьсез тирләмәм дип уйлагач* (Г. Тукай).

*Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр* (Ф. Кәрим).

3) үтенүне белдерә торган кереш сүзләр (*зинһар*):

*Кыр казлары, зинһар, мактанмагыз*

*Ерак түгел безнең арабыз* (Һ. Такташ).

*Әйтче, зинһар, мәрхәмәтсез* (Г. Тукай).

4) фикер чыганагын белдерә торган кереш сүзләр (*минемчә, синеңчә*):

*Минемчә, бүген көн салкын.*

5) нәтиҗәләү, гомумиләштерү, йомгаклау, әйтелгән фикерләрнең үзара мөнәсәбәтен күрсәтү, әйтелгән фактларның тәртибен һәм әһәмиятлелек дәрәҗәсен һ.б. күрсәтә торган кереш сүзләр (*кыскасы, ниһаять, гомумән, әйтик, беренчедән, өстәвенә, башлыча, хәер, өлешчә, иң мөһиме...*):

*Беренче, үзең белән салкын алып кердең,*

*Икенче, уйларымны бүлдең;*

*Өченче, ник килдең* (Һ. Такташ).

6) сөйләүченең җөмләдәге фикерне күптән билгеле, гадәттәге фикер итеп каравын белдергән кереш сүзләр (*табигый, гадәттәгечә*):

*Гадәттәгечә, эш көнен гәзитә укудан башлый* (Х. Мохтаров).

7) тыңлаучыны җәлеп итә торган яки хәбәр ителгән фактка игътибар иттерә торган кереш сүзләр (*гафу ит, кара әле, әйтсәм-әйтим, беләсең килсә*):

*Әйтсәм-әйтим, син белеп кал, чын атым*

*Былтыр минем* (Г. Тукай).

8) әйтелгәннең тәэсир көчен белдерә торган кереш сүзләр (*дөресен әйткәндә, иң яхшысы, дөресрәк, турысын әйткәндә*):

*Турысын әйтим, тарихи роман-повестьлар да күбәеп китте* (Л. Шагыйрьҗан).

9) төрле тойгыларны белдерә торган кереш сүзләр (*ичмасам, валлаһи, бәхетсезлеккә каршы, янәсе, кызганычка каршы*):

*Кызганычка каршы, без экскурсиягә бара алмадык.*

Сөйләүченең җөмләдән аңлашылган фикергә төрле мөнәсәбәтен кереш сүзләр генә түгел, бәлки хәбәр составына керә торган башка сүзләр дә белдерә ала. Алар тыныш блгеләре белән аерымланмыйлар.

*Мич дөрләп кабынып китте, кемдер аның күмерләрен актарып җибәрде ахры* (Ә. Фәйзи).

| **Кереш сүз** | **Кереш сүз түгел** |
|---|---|
| *Ихтимал, бу егет музыкадан да беренчелекне алыр.* | *Бу егетнең музыкадан да беренчелекне алуы ихтимал.* |
| *Дөрес, юлда йөргән кешегә янчык авыр, диләр.* | *Дөрес юлда булган кеше һәрвакыт җиңеп чыга.* |
| *Әйтик, үткән җәйдә ничәмә гектар карабодаебызның балы гына җилгә китеп әрәм булды* (М. Әмир). | *Син терелттең дип әйтик, яме* (З. Хәким). |

**7.2. Гамәли биремнәр.**

**1 нче бирем.** Текстны укыгыз. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз, җөмлә кисәкләренең төрләрен билгеләгез.

*Мин, башыма бишмәт бөркәнгән нәни малай, ниндидер могҗиза күргәндәй, әсәрләнеп, шул серле дөньяга текәлә идем.*

*Урман аланына ат сакларга баргач, Җидегән йолдыздан чамалап, вакытны белергә өйрәндек. Шулай итеп, бу йолдыз минем өчен ниндидер бер абстракт салкын җисем генә түгел, бәлки туган авылымны, газиз анамны, балачагымны исемә төшерә торган "үз" йолдызыма әверелгән иде.*

*Менә шул йолдыз белән чишмә бергә кушылудан, дөресрәге шуларның поэтик тәэсире белән, "Җидегән чишмә" дигән яңа җыр туды.*

(Гомәр Бәшировтан)

**2 нче бирем.** Текстны укыгыз. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз, җөмлә кисәкләренең төрләрен билгеләгез.

*Кич.*

*Иманкул бай йорты тәрәзәләреннән сибелгән якты нурлар, кара пәрдәгә сызылган көмеш рәсемнәр шикелле, караңгы ишек алдына төште. Заһидулла шул яктылыкта үзенең колгадай озын шәүләсен күреп туктап калды. Шүрәлемени?! Шулай озын гәүдәле булып үссәң, кешеләрнең исләре китәр иде... Малай байның атларын караучы Шәйхи бабай йоклый торган урынга юнәлде. Көне буе табак-савыт юып арыган Заһидуллага юеш, караңгы бүлмәдә ятуга караганда, ачык һавада, Шәйхи бабай янында йоклау рәхәтрәк иде. Җәйге төннең җиләс һавасы, йолдызлы күге, баш астындагы яшел печәннең хуш исе бер дөнья аңа. Шәйхи бабай сөйли торган әкиятләр ни тора! Ул әкиятләрдәге Алып батыр кебек көчле егетләр унике башлы аҗдаһаларны кылыч белән бер селтәнүдә юк итәләр бит. Эх, шулар кебек батыр булсаң иде! Теләсә кем, ата мәче сыман, колакка килеп тотына алмас иде аннары.*

- *Килдеңме, улым? Нишләмәк кирәк инде?! Чыныгырга туры килә. Мунча ташын да бер кыздыралар, аннары, салкын су салып, тагын*

*суындыралар... Адәм баласын да шулай итәләр. Менә бит мин дә синең сыман малай чактан ялланган идем. Гомер әнә, һавадан атылган йолдыз күк, үтте дә китте. Малайдан бабай булдым. Ияккә сакал ябышты. Чәчләрем коелып бетте. Ә бәхет? Күреп торасың. Әлениләр генә күрмәдем?! Бер чак атым югалып торды. Бай шуның өчен башыма тимер көрәк белән сукты да аударды. Бәхетем бар икән әле. Бер атна дигәндә Кама буендагы ерак болынлыктан барып таптым.*

(Мәгъсүм Латыйфидан)

**3 нче бирем.** Тәкъдим ителгән җөмләләр арасыннан “артык” җөмләне табыгыз.

1. *Шунда кайтып кердеме – ул бөек була алмый* (М. Мәһдиев).

2. *Су коенсам, дулкыннарга чалкан ятып, һаман күккә бактым* (Г. Сабитов).

3. *Адымнарыңны кызулаттыңмы – син инде култык астына калын папка, портфель тотып ашыгучы, башкалага авыл-районнардан килгән эшкуарлар төркеменә эләгәсең* (М. Галиев).

4. *Аннары тирә-якка күз йөртеп, акрын гына артына борылды* (Ә. Еники).

5. *Әгәр соңга калсам, җитешә алмаячакмын* (М. Галиев).

### 7.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар.

1. Җөмләнең иярчен кисәкләренә нинди җөмлә кисәкләре керә?
2. Иярчен кисәкләр ничек һәм кем тарафыннан өйрәнелгән?
3. Нәрсә ул аергыч?
4. Нәрсә ул аерылмыш?
5. Аергыч аерылмышка нинди чаралар ярдәмендә ияртә?
6. Нәрсә ул тәмамлык?
7. Туры һәм кыек тәмамлыклар бер-берсеннән ничек аерыла?

8. Нәрсә ул хәл?

9. Хәл нинди төрләргә бүленә?

10. Сәбәп белән максат хәле бер-берсеннән ничек аерыла?

11. Урын, вакыт, рәвеш, күләм хәлләре ияртүче сүзгә нинди чаралар аша ияреләр?

12. Максат, сәбәп, шарт, кире хәлләр ияртүче сүзгә нинди чаралар аша ияреләр?

13. Нәрсә ул аныклагыч?

14. Нәрсә ул аныкланмыш?

15. Аныклагыч аныкланмышка нинди чаралар ярдәмендә ияреә?

16. Аныклагычлар янында нинди тыныш билгеләре куела?

17. Ярашкан һәм ярашмаган аныклагычлар ничек белдерелә?

18. Нинди кисәкләргә модаль кисәкләр диләр?

19. Нәрсә ул эндәш сүз?

20. Эндәш сүз нинди формаларда бирелә ала?

21. Нәрсә ул кереш сүз?

22. Кереш сүзләрдә нинди мәгънәләр күзәтелә?

### 7.4. Презентация.

## 8.
## Лекция № 6

- **Тиңдәш кисәкләр. Җөмләнең синтагмаларга бүленеше. Аерымланган кисәкләр. Җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше. Сүз тәртибе. Тематик (күзаллаулы) баш килешле әйләнмәләр. Өстәлмәләр.**

**Аңлатма.** Әлеге тема җөмләнең синтагмаларга бүленеше, тиңдәш һәм аерымланган җөмлә кисәкләре, җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше турында аңлатма бирә. Уңай һәм кире сүз тәртибе, өстәлмә хакында мәгълүмат алырга мөмкин.

**Иң мөһим төшенчәләр.** Синтагматик кисәкләр, аерымланган кисәкләр, тема, рема, уңай сүз тәртибе, инверсия, баш килешле әйләнмә, өстәлмә.

**Методик киңәшләр.**

•Тема теоретик мәгълүматны үз эченә алган лекциядән гыйбарәт;

•Мөстәкыйль эш өчен гамәли биремнәр тәкъдим ителә;

•Теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү максатыннан, теоретик сораулар бирелә.

•Лекция презентацияләр белән үрелеп бара.

## 8.1. Тиңдәш кисәкләр. Җөмләнең синтагмаларга бүленеше. Аерымланган кисәкләр. Җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше. Сүз тәртибе. Тематик (күзаллаулы) баш килешле әйләнмәләр. Өстәлмәләр.

Җөмләдә бер үк төрле кисәк ике яки берничә булырга мөмкин. Бу бер төрле кисәкләр, җөмләдә үзара тезү юлы белән бәйләнеп, мәгънә ягыннан бер үк уртак сүзгә карыйлар. 1945 елда басылып чыккан Г. Алпаровның "Сайланма хезмәтләрендә" мондый кисәкләре булган җөмлә оешма (оешкан) җөмлә дип атала. (Рус синтаксисында – А. Пешковский, слитное). Ни өчен оешма, чөнки җөмләләрдә бер төрле кисәкләре ничә булса, ул җөмләне шул сандагы аерым гади җөмләләргә таркатып була дип уйланылган (өч гади җөмләдән оешкан җөмлә -> *Алтын бабай безгә алма, чия, җиләк алып килә* (Җ. Тәрҗеманов).). Бүгенге көндә тиңдәш кисәкле гади җөмлә дип күрсәтелә.

**Үзара тезүле бәйләнештә торган, бер үк функция үтәгән һәм уртак бер сүзгә караган кисәкләр җөмләнең тиңдәш кисәкләре дип атала.**

Тиңдәшлек күренешенең берничә нигезе (шарты) бар.

1. Тиңдәш кисәкләр үзара тезүле бәйләнештә торалар.
2. Тиңдәш кисәкләр җөмләдә бер үк функция үтиләр => җөмләнең бер үк кисәге булалар.
3. Тиңдәшлек ияртүле бәйләнешсез була алмый.

Мәсәлән: *Поэманың эчтәлеге, мәйданы, офыгы киңәя бара* дигән мисалда – *эчтәлеге, мәйданы, офыгы* сүзләре тиңдәшләнеп килгәннәр, чөнки алар һәрберсе "*киңәя бара*" сүзенә ияргән. Кайбер ким җөмләләрдә тиңдәш кисәкләр үзләре генә дә киләләр. Мәсәлән: *Фатыйма һәм*

*сандугач* (Г. Тукай). Ияртүле бәйләнеш юк, ләкин мәгънә буенча бар = *Фатыйма һәм сандугач турында шигырь*.

Җөмләнең барлык кисәкләре дә тиңдәш була ала.

**а) тиңдәш ияләр** (гадәттә уртак хәбәргә бәйләнәләр):

*Пароходлар, баржалар күренә* (К. Нәҗми).

**б) тиңдәш хәбәрләр** (уртак иягә, яки гомумиләштерүче сүзгә бәйләнәләр):

*Гәрчә анда тумасам да, мин бераз торган идем,*

*Җирне аз-маз тырмалап, чәчкән идем, урган идем* (Г. Тукай).

**в) тиңдәш аергычлыр** (үзенчәлекле иярчен кисәк). Бер үк сүзгә (аерылмышка) ияреп, формаль яктан бер үк төрле аергычлыр тиңдәш яки тиңдәш булмаска мөмкин.

*Кояш үзенең шаян, тере, алсу нурлары белән иркәли*. (тиңдәш аергычлар)

*Аның сап-сары куе алтын сакалы кояшта ялтырый*. (тиңдәш түгел, чөнки аерылмышны төрле яктан характерлый, төрле сорауга җавап бирәләр).

Җөмләдә бер үк кисәккә (аерылмышка) караган аергычларның тиңдәш булу – булмауларын текстның мәгънәсеннән, эчтәлегеннән чыгып билгеләргә кирәк. Аергычлар предметны яки күренешне бер генә яктан ачыкласалар тиңдәш булалар. Мәсәлән, төсе буенча: *Бакчада ал, кызыл, зәңгәр, чәчәкләр үсә.*

Предметны төрле яктан сурәтли торган аергычлар тиңдәш булмыйлар.

*Кибеттә киң яшел ефәк материал сатыла*.

1) тиңдәш түгеллеген белү өчен, лексик-грамматик күрсәткечләр ярдәм итә.

Морфологиядә асыл һәм нисби сыйфатлар бар. Алар янәшә килгәндә, нигездә, тиңдәш булмыйлар (*Язгы җиләс һава; маяклы озын юл*).

2) текркәгеч куеп карарга мөмкин (икенче мисалда куеп булмый).

3) тиңдәш булмаган аергычларның берничәсе янәшә килгәндә, һәрбер аергыч турыдан-туры предметка карамый, бәлки үзеннән алда килгән аергыч белән предметка бергә карый. (*Ак таш кибетләр – ак – таш кибетләр*) (*Җылы йомшак язгы җил*) һ.б.

**г) хәлләрнең** тиңдәшлеге турында сүз барганда, аларны үз эчендәге аерым төрләрнең тиңдәшлекләре генә күз алдында тотылырга тиеш.

*Мин уйныйм урманда, болында, кырларда* (Г. Тукай).

**д) тиңдәш аныклагычлар**:

*Зур бәйрәмнәрдә - октябрь бәйрәмендә, 1 нче майда – хезмәткәрләр өчен кичәләр оештырабыз.*

**е) тиңдәш кереш сүзләр:**

*Минемчә дә, сезнеңчә дә, бу биремдә ниндидер хата киткән.*

**ж) тиңдәш эндәш сүзләр:**

*Әлфия, Гөлназ, иртәгә дәрескә соңга калмагыз.*

**Тиңдәш кисәкләр үзара төрле чаралар ярдәмендә бәйләнәләр.**

1. Җыючы теркәгечләр ярдәмендә:

*Мин моны тиз генә эләктердем **дә** әнигә китердем* (Г. Ибраһимов).

*Бу төшләргә килеп җитә алмый **ни** бер сәлам, **ни** хат, **ни** хәбәр* (Х. Туфан).

Пар-пар тиңдәшләнү: *Иртәдән кичкә чаклы балта һәм пычкы, китмән һәм көрәк кулдан төшмәде.*

2. Каршы куючы теркәгечләр ярдәмендә:

*Ваемсыз булып, гүя кешеләр арасыннан түгел, ә урман эченнән барам* (М. Галиев).

*Мин түгел, **бәлки** син бу мәсьәләдә гаепле* (Г.Бәширов).

3. Бүлүче теркәгечләр ярдәмендә:

*Авыл унбиш көн чамасы* ***әле*** *аклар,* ***әле*** *кызыллар кулына күчеп торды* (Г. Бәширов).

*Чәче агарган кеше* ***әллә*** *курыкканга,* ***әллә*** *бүтән сәбәптән туры җавап бирмәде* (Г. Кутуй).

4. Санау интонациясе ярдәмендә:

<....> *ул бөтен авылның яланнарын, тауларын, чокырларын үзенең биш бармагы кебек белә* (Г.Ибраһимов).

5. Каршы кую интонациясе ярдәмендә:

*Ул нидер әйтмәкче иде - әйтмичә калдырды* (Г. Бәширов).

Тиңдәш кисәкләрне бергә туплап тора торган, алар белән аныклаулы мөнәсәбәткә керә торган лексик берәмлек **гомумиләштерүче сүз** дип атала. Мондый функциядә билгеләү алмашлыклары һәм гомуми мәгънәле сүзләр килә ала. Алмашлыклардан *бөтенесе, һәммәсе, барчасы, барысы, һичнәрсә, һичбере* һ.б. шундый берәмлекләр гомумиләштерүче сүз булып йөри. Гомумиләштерүче сүз я тиңдәш кисәкләр алдыннан урнаша, я тиңдәш кисәкләрдән соң килә. Тиңдәш кисәләрдән алда килгән гомумиләштерүче сүздән соң көттерү паузасы ясала.

***Барысын да****: сагыну-юксынуларын да, җыр-әкиятләрен дә бабай үзе белән бергә кабергә алып китте* (Ә. Еники).

*Күк, җир, тереклек, үсемлекләр –* ***барчасы*** *аның иркенә буйсынып ята* (Ә. Гаффар).

*Яланнар, басулар, болыннанр, таулар, урманнар, кырлар –* ***һәммәсе****, киң күкрәкләрен ачып, көчле яңгырның рәхәтенә чумдылар* (Г. Ибраһимов).

**Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре**

Тиңдәш кисәкләр янында <u>өтер, сызык, нокталы өтер</u> һәм <u>ике нокта</u> куелырга мөмкин.

1. Тиңдәш кисәкләр бер-берсенә санау яки җиңелчә каршы кую интонациясе ярдәмендә бәйләнсәләр, алар арасына өтер куела.

*Директор тиешле кешеләрне чакыртып алды, чыгарылыш кичәсен иртәгә үк уздырырга боерды* (Н. Фәттах).

2. Каршы куючы яки кабатланып килгән җыючы һәм бүлүче теркәгечләр белән бәйләнгән тиңдәш кисәкләр арасына өтер куела.

*Тәнәфес вакытында гел кызлар арасына кереп утырды, ә эш беткәч, мине көтмичә, ашыга-ашыга китеп бара торган булды* (Ә. Еники).

3. Тиңдәш кисәкләр алдыннан гомумиләштерүче сүз килсә, яки санап китү көтелгән очракта, ике нокта куела.

*Бөтенесе: өе, алачыгы, keләте, кәҗәсе, тавык-чебешләре күз алдында тора* <....> (Ә. Еники).

*Бәхетле булу өчен, күп кирәкмени соң кешегә: җаның теләгән эш, семьяңны урнаштырырга җылы куыш һәм киң күңел* (Г. Ахунов).

4. Тиңдәш кисәкләрдән соң гомумиләштерүче сүз килсә, сызык куела.

*Казан кунагының яратып ашаган ризыклары, яратып эчә торган эчемлекләре – бөтенесе-бөтенесе ачыкланды* (Ф. Садриев).

*Балачагын, егет вакытларын, каз өмәләрен, туйларын, җыеннарын, ярминкәләрен – барысын да кызык итеп, тәмле итеп, күрсенеп һәм юксынып сөйләп утырырга ярата торган иде* (Ә. Еники).

5. Тиңдәш кисәкләр кискен каршы кую интонациясе белән бәйләнсәләр, сызык куела.

*Бурычка ала – кайтармый* (А. Гыйләҗев).

6. Тиңдәш кисәкләр җәенке булып, үз эчләрендә тагын тыныш билгеләре булса, һәм теркәгечсез бәйләнеп килсәләр, ноталы өтер куелырга мөмкин.

*Өс-башын чишенмичә генә, мендәргә башын төрткән көе генә черем итеп алды; беразга онытылып, төш белән өн арасында буталды.*

**“Ярашу” мәсьәләсе.**

Тиңдәш сүзләр, нигездә, бер үк сүз төркеме белән белдерелгән булалар һәм бертөрле грамматик формада киләләр, ягъни “ярашалар”.

Исем һәм исем ролендәге сүз төркеменнән торган тиңдәш кисәкләр сан, килеш, тартым формалары белән ярашалар.

Фигыльләрдән төзелгән тиңдәш кисәкләр заман, зат-сан формалары белән ярашалар.

Төрләнми торган сүз төркемнәре (сан, сыйфат, рәвеш) белән бирелгән тиңдәш кисәкләр үзләренең нигез формалары белән ярашкан булалар.

*Мин торам кырларда, болында, урманда*. (У.в.к.)

*Уйныймын, очамын якты көн булганда*. (Зат-сан; хәбәрлек)

*Иркәли һәм сөя кояшның яктысы*. (Зат-сан; заман)

Ярашмаган тиңдәш кисәкләр дә була.

- тавтология булмасын өчен, тиңдәш кисәкләрнең соңгысы гына билгеле бер форма кушымчасын ала.

*Сахра, болын, игеннәрне су басты*. (т.к. кушымчасы төшеп кала)

- *белән* бәйлеге теркәгеч урынында килеп, тиңдәш кисәкләрне бәйләгәндә.

*Мәдинә белән Гөлбанудан башка хатын-кызларның һәммәсе тары утарга билгеләнде* (Ш. Камал).

**Җөмләнең синтагматик һәм актуаль кисәкләре.**

**Синтагматик кисәкләр.**

**Синтагма** – грек теленнән кергән сүз (термин). Грекча бергә төзелгән, бергә береккән мәгънәсенә туры килә.

Билгеле булганча, аралашу процессында сөйләм тоташ агым рәвешендә булмый. Ул җөмләләргә, җөмлә исә, мәгънәнең нинди булуына карап, бер-берсеннән пауза яки башка интонацион чаралар ярдәмендә аерыла торган интонацион буыннарга – синтагмаларга бүленә.

Мәсәлән: *Менә шул бабай* │ *үләр алдыннан* │ *үзенә чакырды да* │ *миңа* │*бер уч тутырып* │ *орлыклар бирде.* Бу җөмләдә 6 синтагма бар. Аларның һәрберсе бер көчле басым астында берләшә, һәм бер-берсеннән пауза, тон югарылыгы, әйтелеш темпы белән аерыла.

**Димәк, сөйләмнең бер көчле басым астында әйтелә һәм бер-берсеннән пауза, ярымпауза, шулай ук авазның югарылыгы, көче, әйтелеш темпы һәм тембр төсмерләре белән аерыла торган мәгънәле кисәкләре синтагма була.**

Синтагманың синтаксик төзелеше һәм күләме даими түгел. Ул обстановкага, сөйләм ситуациясенә, җөмләнең мәгънәсенә карап, үзенең чикләрен бик тиз үзгәртә. Мәсәлән: *Фәттах мулла булып китте.* Бу җөмләне бер синтагма белән әйтсәк, сүз Фәттах мулланың килеп китүе турында бара; ә Фәттахтан соң пауза ясап, бу җөмләне 2 синтагма белән әйтсәк, Фәттах исемле кешенең мулла булып китүе турында бара. (Алдагы җөмләне дә үзгәртергә була, синтагманы Менә шул сүзеннән соң куеп: Менә шул │ бабай үләр алдыннан... һ.б.).

Димәк, сөйләмдә, җөмләнең синтагматик кисәкләре дә мәгънә белдерүдә зур роль уйныйлар.

Җөмләдә язма телнең иң кечкенә мәгънәви берәмлеге сүз булса, аралашу процессында җанлы сөйләмнең иң кечкенә мәгънәви берәмлеге – синтагма. Җөмлә яки берничә синтагмага бүленергә, яки үзе бер синтагма хасил итәргә мөмкин. *Җылы яңгырлар яуды* (1 синтагма). 1 синтагма эчендәге сүзләр уңай тәртиптә булып, бер көчле басым астында әйтелергә һәм һәрвакыт янәшә торырга тиешләр. Сөйләүче синтагма эчендә

сөйләмен бүлеп сулыш алырга тиеш түгел. Бу очракта пауза бер күренешне белдерә торган сүзләрне ике кисәккә аера.

Тулаем җөмлә бер синтагма төзегән очракта, синтагма интонацион яктан тәгәлләнгән була.

*Якты кояш карады.*|

Синтагманы җөмләнең бер өлеше генә хасил итсә, ул интонацион яктан тәгәлләнми, бәлки, аның дәвамы таләп ителә.

*Ниндидер бер явыз* | *кара таш белән бастырып киткән.*

Моны Ш.Н. Асылгәрәев эксперименталь юл белән раслый.

Тел белемендә хәзерге синтагма теориясенә нигез салучыларның берсе итеп Лев Владимирович Щербаны саныйлар. Ләкин синтагма теориясенең беренче яралгыларын инде антик чорда да табарга мөмкин. Борынгы грек галимнәре, ораторлык теориясен өйрәнгәндә, синтагмаларга да игътибар иткәннәр (Алар аны “колоннар” дип атаганнар).

Рус теле белемендә синтагмамаларны А.Х. Востоков, И. Свенцов дигән галимнәр өйрәнә башлый.

XX гасырда Л.В. Щерба, В.В. Виноградов, Л.Р. Зиндер тикшерәләр.

Татар теле белемендә сөйләмнең синтагматик бүленешенә беренче мәртәбә М.З. Зәкиев мөрәҗәгать итә (“Синтаксический строй татарского языка”, 1963). 1968 елда Ш.Н. Асылгәрәев “Татар сөйләменең синтагмаларга бүленеше” дигән кандидатлык диссертациясен яза. Монда синтагма бик җентекләп тикшерелә.

Фәнни әдәбиятта сөйләмнең мәгнәле интонацион кисәкләре күп төрле терминнар белән атала: сөйләм такты, сөйләм звеносы, ритмик группа, сулыш группасы һ.б.

Ш.Н. Асылгәрәев раславынча, сөйләм такты һәм сөйләм звеносы синтагмага синоним буларак кына йөриләр.

М.З. Зәкиев “Бер басым астында әйтелгән иҗекләр группасы сөйләм такты дип атала”, - ди. Сораулар туа: нинди иҗекләр группасы? Бүленешендә нинди принцип ята? Чөнки ул бер басым астында әйтелә

торган мәгънәсез иҗекләр группасын атау өчен кулланылмый, ә бәлки сөйләм барышында барлыкка килгән мәгънәле интонацион буыннар турында сүз бара. Бер синтагмадагы сүзләр дә янәшә урнашкан иҗекләр группасыннан торалар. Димәк, синтагма чиге белән сөйләм такты чикләре туры килә, алар бер үк әйбер.

**Сулыш группасы** – бер сулыш алу тукталышыннан икенчесенә кадәр булган арада әйтелгән сүзләрдән тора. Кайбер очракларда синтагма сулыш группасы белән туры килә. Ләкин күбрәк бер сулыш группасында берничә синтагма булырга мөмкин.

с у л ы ш с у л ы ш

*Ул* | *бик карт иде* | *бөтенләй ялгыз иде.*

3 синтагма; 2 сулыш группасыннан тора.

с у л ы ш с у л ы ш

*Тиресне* | *себереп түктек* | *ташларны* | *читкә аттык.* |

Бер синтагмада берничә сулыш группасы булырга мөмкин түгел.

**Синтагма белән сүзтезмә арасында мөнәсәбәт.**

| Синтагма | Сүзтезмә |
|---|---|
| - 1 генә сүздән дә торырга мөмкин | - һәрвакыт 2 яки икедән артык мөстәкыйль сүздән тора. |
| - сүзләр янәшә урнашырга тиешләр | - сүзтезмә төзи торган сүзләр җөмләнең теләсә кайсы урынында урнашырга мөмкиннәр |
| - төгәлләүле мөнәсәбәт тә, хәбәрлекле мөнәсәбәт тә булырга мөмкин | - сүзләр арасында һәрвакыт төгәлләүле мөнәсәбәт була |

**Җөмлә кисәкләренең аерым синтагма төзи ала яки**

**төзи алмый торган очраклары**

Теге яки бу обстановкада, җөмләнең теләсә кайсы кисәге үзе генә яки үзенә ияргән башка сүзләр белән синтагма төзергә яки төземәскә мөмкин. Ләкин гомумиләштереп, берничә кагыйдә формалаштырырга мөмкин.

- Җөмлә ия белән хәбәрдән генә торып, аларга аерым басым ясалмаса, икесе бер синтагма эчендә әйтеләләр:

*Мин язам. Җил исә.*

- Төгәлләүле мөнәсәбәткә кергән сүзләрнең иярүчесе иярүче сүз белән янәшә килсә, алар бер синтагма төзиләр:

*Җылы яңгырлар яуды.* |

*Китап укыйм.* |

*Менә шул бабай* | *миңа* | *бер уч тутурып* | *орлыклар бирде.* ||

- Җыйнак җөмләнең иясе яки хәбәре көчле басым белән әйтелсә, ия үзенә, хәбәр үзенә синтагма төзи:

*Мин – студент.*

*Түбән очның күпере* | *бу ташуга түзә алмады.*

- Төгәлләүле мөнәсәбәткә кергән кисәкләр үзләре ияргән сүздән ераклашсалар, аерым синтагма төзиләр:

*Ап-ак чәчәк аткан алмагач* | *хәзер* | *кара пәрдә япкан.* | (в.х.)

- Өстәлмәләр аерым синтагма төзиләр:

*Кичә шәһәргә бардым, әти белән.*

- Модаль кисәкләр, нигездә, аерым синтагма төзиләр:

*Курыкмагыз,* | *кошлар,* | *күреп сез* | *янызгызда мин барын* (Г. Тукай).

- Ярашкан аныклагычлар, кагыйдә буларак, аерым синтагма төзиләр:

*Бик югарыда,* | *биек агач башларында,* | *салават күпере күренде.*

- Аерымланган кисәкләр һәрвакыт аерым синтагма төзиләр.

*Хәят,* │ *күтәрелеп,* │ *Михаилның йөзенә карады.* (Ф. Әмирхан).

- Тиңдәш кисәкләрнең ияртүче кисәк белән янәшә тормаганнары аерым синтагма хасил итәләр:

*Бер атнадан* │ *матур сабаклар* │ *яшел яфраклар чыкты* (Г. Ибраһимов).

**Җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше**

Җөмләнең, грамматик төзелеше белән бергә, һәрвакыт акуталь төзелеше дә була. Аралашу процессында, башка җөмләләр белән логик бәйләнешкә керүе ягыннан караганда, җөмлә ике кисәккә бүленә ала. Менә шул кисәкләр җөмләнең **актуаль кисәкләре** дип атала, аларны икенче төрле җөмләнең **актуаль өлешләре** дип тә йөртәләр.

Җөмләнең бер өлеше тыңлаучы яки укучы өчен инде таныш, билгеле булган күренешләр, вакыйгалар турында хәбәр итә, аны сөйләм предметы яки тема дип йөртәләр (данное). Җөмләнең икенче өлеше шул билгеле, таныш хәбәр нигезендә нинди дә булса яңалык алып килә, бу кисәк сөйләм яңалыгы яки рема була (новое). Гадәти сөйләмдә, кагыйдә буларак, тема – алдан, рема аннан соң урнаша. Сөйләм предметын белдерә торган кисәккә логик басым төшми.

тема рема

*Ишек алдында эш*│ *тәмамланып килә иде* (Г. Минский).

Актуаль кисәкләрне җөмләнең грамматик кисәкләре белән бутамаска кирәк. Аларны аерып чыгару нигезендә ике төрле принцип ята. Җөмләне грамматик кисәкләргә бүлгәндә, формаль як өстенлек ала; биредә лексик берәмлекләрнең үзара конкрет чаралар ярдәмендә бәйләнеп килүе карала. Актуаль кисәкләрне тикшергәндә, сөйләүче ниятенә, хәбәрнең инде танышмы, яңамы булуына игътибар итәләр.

Сөйләм предметына – теләсә кайсы грамматик кисәк, сөйләм яңалыгына шулай ук теләсә кайсы грамматик кисәк туры килергә мөмкин. Мәсәлән:

- *Кояш*| *үзенең нурларын каршы яктан бәрә иде.* (сөйләм предметы - ия)
- *Ишек алдында*| *эш тәмамланып килә.* (сөйләм предметы - урын хәле)
- *Укучыларны*| *ашханәгә илттеләр.* (сөйләм предметы - тәмамлык)

Грамматик кисәкләрне өйрәнгәндә, без җөмләнең грамматик төзелешен тикшерәбез, ә актуаль кисәкләрне караганда, җөмләнең коммуникатив төзелеше тикшерелә.

Тыныч хикәяләү стилендә акуталь кисәкләрнең ике төрле урнашу тәртибе бар.

1. Сөйләм предметы – алдан, сөйләм яңалыгы аннан соң урын ала. Сөйләм яңалыгын хәбәр үзе генә яки хәбәр төркеменә керә торган сүзләр тәшкил итә.

Сөйләм предметы сөйләм яңалыгы

*Кызның исеме*| *– Вера* (Ш. Усманов).

Сөйләм предметы сөйләм яңалыгы

*Кичен Габдулла*| *аскы өйгә төште* (Ә. Фәйзи).

2. Башта сөйләм предметы килә, аннан соң – сөйләм яңалыгы, җөмләнең азагында яңадан сөйләм предметы урын ала.

Сөйләм предметы сөйләм яңалыгы сөйләм предметы

*Бу җырны,*| *һичшиксез, Җиргән кызлары*| *чыгаргандыр* (М. Әмир).

Сөйләм предметы сөйләм яңалыгы сөйләм предметы

*Бу киемне* | *ирең Ибраһим* | *алып китте* (Ф. Әмирхан).

**Җөмлә кисәкләренең аерымлануы**

Кайчандыр җөмләләрне тоташтан, бернинди тыныш билгесе куймыйча язганнар. Болай язу дөрес укуны, аңлауны кыенлаштырган. Соңрак аерым синтагмаларны төрле тыныш билгеләре белән бер-берсеннән аера башлаганнар. Шул рәвешчә, җөмлә кисәкләренең аерымлануы теориясе барлыкка килгән, һәм аның кагыйдәләре эшләнгән.

Теоретик билгеләмә түбәндәгечә бирелә: **"җөмләнең интонация һәм пауза белән аерып әйтелгән кисәге аерымланган иярчен кисәк дип атала, һәм андый кисәк башкаларыннан тыныш билгесе белән аерыла"**.

Бу каршылыклы әйбер чөнки, теләсә кайсы кисәк билгеле шартларда аерым интонация белән әйтелә, ягъни пауза белән аерыла, ләкин тыныш билгесе куелмый.

Бөтен тыныш билгеләре дә, үз чиратында, пауза ясалган урыннарга гына куелмый.

Җөмлә кисәкләренең аерымлануы грамматик категория түгел, ул бары тик – кайбер синтагмаларны язуда тыныш билгеләре ярдәмендә аерып күрсәтү кагыйдәләренең җыелмасы.

Димәк, аерымланган иярчен кисәкләр җөмләнең синтагматик бүленешенә нигезләнгәннәр, алар синтагмаларның традицион рәвештә тыныш билгеләре белән аерыла торганнарын гына үз эченә алалар, тыныш билгесе белән аерылмый торган синтагмалар аерымланган иярчен кисәк дип саналмыйлар.

Шулай итеп, тыныш билгеләре куюның да, аерымланган иярчен кисәкләр теориясенең дә нигезендә тел төзелешен өйрәнүдән килеп чыккан фәнни принциплар түгел, бәлки синтагмаларның аерым очракларын гына күрүдән туган традицион принцип ята.

Аерымланган иярчен кисәкләр, аерымланмаганнарына караганда мәгънә ягыннан әһәмиятлерәк дигән караш та чынбарлыкка туры килми (ярым хәбәрлек төшенчәсе).

Киресенчә, нәкъ менә аерымланган чагында, иярчен кисәк хәбәрдән ераклаша. Ә логик басым төшкән сүз, ягни тыңлаучы өчен иң әһәмиятле сүз, нәкъ менә хәбәр алдында, янәшә килә һәм аерымланмый.

*Укуны тәмамлагач, Шамил лагерьга китте* җөмләсендә аерымланган кисәк бар (вакыт хәле). Ләкин җөмләдә төп мәгънәне бирә торган сүз – логик басым төшкән “*лагерьга*” сүзе. Җөмләгә сорау да шулай куела. *Шамил кая китте?*

Җөмләне үзгәртеп төзесәк, *Лагерьга Шамил укуны тәмамлагач китте.* – аерымланмый. Ә логик басым төшә. Сорау да шулай куела: *Шамил лагерьга кайчан китте?*

Шулай итеп, аерымланганда теге яки бу кисәкнең мәгънә ягыннан әһәмияте артмый, бәлки кими.

Аерымланган кисәк дигән грамматик җөмлә кисәге дә юк.

*Өйдән чыккач, ул урам буйлап китте* җөмләсендә *өйдән чыккач* аерымланган вакыт хәле дип карала. Ләкин бу берникадәр шартлы. Җөмлә кисәкләренә таркатсаң, вакыт хәлен *чыккач* сузе генә үти, ә *өйдән* урын хәле була.

Аерымланган иярчен кисәкләр сөйләмнең аерым категориясен тәшкил итмиләр, алар сөйләм категориясе булган синтагмаларның язуда тыныш билгесе белән аерыла торганнары гына. Ә нинди синтагмаларның язуда тыныш билгесе белән күрсәтүләрен истә калдырырга гына кирәк.

Җөмләнең баш кисәкләре (ия, хәбәр) беркайчан да аерымланмый. Үзара бәйләнештә генә алар хөкемне тәкъбир итә алалар һәм грамматик бөтен булалар.

Җөмләнең башка кисәкләре төрле шартларга карап аерымлана. Нигездә, ул шартлар түбәндәгеләр:

- Җөмлә кисәкләренең гадәти тәртиптә килмәүләре;
- Интонация һәм пауза йогынтысы;

- Җөмлә кисәкләренең җәенкеләнүе;
- Мәгънә таләбе.

Ләкин бу шартларның аерымланган кисәктә берьюлы табылуы мәҗбүри түгел.

**<u>Аерымланган аергычлар.</u>**

Аергычлар, нигездә, аерымланмый торган җөмлә кисәге. Чәчмә әсәрләр өчен бигрәк тә. Алар күп очракта аерылмышларыннан алда килеп, шуның белән интонацион яктан тыгыз бәйләнгән бөтен тәшкил итәләр.

Аерылмышларыннан ерак яки соң килсәләр дә, язуда тыныш билгеләре белән аерымланмыйлар. Мәсәлән: *Мәктәбебез элекке мәчет бинасында безнең.*

Тезмә әсәрләрдә аергыч үзенең аерылмышыннан соң килергә һәм аерымланырга мөмкин. Бу очракта аергыч үзенең мәгънәсе белән җөмләнең хәбәрен хәтерләтә, шуның белән мәгънә ягыннан мөстәкыйльлеге арта, әйтелешендә дә үзгәреш туа: паузалар ясала.

*Бер җирдә юк камыш сабаклары,*

*Андагыдай шаулый торганнар* (Һ. Такташ).

Язуда аерымланган аергычлар өтерләр белән күрсәтеләләр:

*Бар егетләр, бик тәкәбберләрчә тоткан позасын,*

*Чөнки дөнья бакчасының күргән ул тик розасын* (Г. Тукай).

**<u>Аерымланган тәмамлыклар.</u>**

Тәмамлыкларның аерымлануы шулай ук бик чикле. Килеш кушымчалары белән килгән тәмамлыклар, җөмләнең хәбәренә тыгыз бәйләнештә торып, хөкемне белдерү өчен, беренче чиратта, әһәмиятле булган объектны белдерәләр һәм ритмик-мелодик яктан үзләре караган җөмлә кисәге (иң күп очракта хәбәр) белән бер бөтен итеп әйтеләләр. (Кайбер телләрдә, мәсәлән грузин телендә, тәмамлык җөмләнең III баш кисәге).

Матур әдәбиятта җәенке тәмамлыкларны урынсызга өтерләр белән бүлгәләү фактлары очрый:

*Ни өчендер бик сөям мин, җәйге көннең иртәсен* (М. Гафури).

*Күптән түгел, безнең тәрәзә капкачын,*

*Оя итте минем сөйгән карлыгачым* (Г. Тукай).

Бу җөмләләрдә туры тәмамлыкларны өтерләр белән аерып бирелүен тик шигырь ритмына, ике арада азмы-күпме тукталыш ясауга ияреп ясалган ялгышлар итеп карарга кирәк.

Бик сирәк очракларда тәмамлыклар аерымлана.

1) Кайбер бәйлек ролендәге сүзләр белән килгән җәенке тәмамлыклар аерымланырга мөмкин. Мондый бәйлек сүзләргә түбәндәгеләр керә: *тыш, башка, бүтән, бергә, урынына, битәр, бигрәк, буларак* һ.б.

*Аның кара гына чәченнән битәр, көләч йөзенә рәхәтләнеп карады* (Г. Исхакый).

*Кәгазьгә язылганнардан тыш, телдән әйтелә торган күрсәтмәләр дә барлыгын белми иде Шаһинур* (Р. Низами).

2) Инверсияләнеп җөмлә ахырында килгән һәм интонацион яктан җөмлә эчендә калган ( ягъни өстәлмә булып формалашмаган) кыек тәмамлыклар аерым синтагма төзиләр һәм аерымланалар.

*Мин сездән кияүгә китәргә җыенам, шәһәр егетенә* (Х. Вахит).

*Ул яхшы поэма язган, мәхәббәт турында.*

*Шәһәрдән кичә генә кайттык, әти белән* (Ш. Усманов).

## Хәл кисәкнең аерымлануы.

Аерымлана торган кисәкләр арасында хәлләр - иң үзенчәлеклесе. Аларның барлык төрләре дә, урын хәленнән башкалары, аерымланып килә ала. Моның төп сәбәбе – хәл кисәкләрнең фигыль белән янәшәлек бәйләнәшендә торуында. Янәшәлек бәйләнеше – ярашу һәм

башкарылышка караганда, шактый тотрыксыз алым. Хәл кисәкләрнең аерымлануы өчен түбәндәге шартлар кирәк.

- хәлнең үзе бәйләнгән сүздән ераклашуы;
- аның процесс белдерә торган кисәк белән бирелүе (фигыль);
- мөстәкыйль интонация белән әйтелүе;
- мәгънәгә басым ясалуы;
- күп очракта җәенкеләнүе….

Җәенке хәл кисәкләр, чагыштырмача мөстәкыйль мәгънә алып, эчтәлекләре ягыннан да, әйтелешләре белән дә иярчен җөмләләргә якын киләләр һәм язуда өтерләр белән аерымланалар. Җәенке хәл кисәкләрне өтер белән аеру яки аермау яки тыныш билгесен төрлечә кую әйкән фикернең мәгънәсен ике төрле аңлауга юл калдыра.

Мәсәлән: *Алсу, бүлмәсенә керү белән,*

*Өс киемен салып ташлады* ( Һ.Такташ ).

Бу мисалда *Алсу* сүзеннән соң өтер куелмаса, *Алсу* аергыч булып китәргә мөмкин ( кемнең бүлмәсенә?).

*Солдатларның берсе юлны яктырту өчен алган фонарена ут кабызды* мисалында да “*юлны яктырту өчен*” тезмәсе “*алган*” сүзенә дә, “*ут кабызды*” тезмәсенә дә буйсына ала.

Урын хәлләренең аерымланмавының төп сәбәбе аның процессны белдерә торган кисәк белән бирелмәвендә!

Формалашуы ягыннан караганда, урын хәлләре башлыча килеш кушымчалары алган исем яки алмашлыклар белән белдереләләр. Дөрес, башка хәлләр дә (вакыт, сәбәп) килеш кушымчалары алырга мөмкин (мәсәлән: *ишектән килеп керүгә... кечкенә булганлыктан*). Әмма бу төр хәлләрдә килеш кушымчалары фигыль һәм фигыльдән ясалган исемнәргә генә ялганып, исемгә хас килеш функцияләрен (юнәлеш, чыгыш, урын) үтәмиләр. Урын хәлләре чын мәгънәсендә килеш кушымчалары алган исемнәр белән белдереләләр (*Урамга керәм, шәһәрдән кайтыш* һ.б.).

Урын хәлләре кыек  тәмамлыкларга бик якын торалар. Күп вакытта алар арасында кискен чик куеп та булмый (*Мин апаларга барам. Мин авылга барам. Мин сезгә ышанам.*).

Ә тәмамлыклар үзләре караган сүз белән мәгънә һәм интонацион яктан тыгыз бәйләнештә торалар. Гомумән, тәмамлыклар сирәк аерымлана. Урын хәлләре дә шулай ук.

Рәвешләр белән белдерелгән урын хәлләре, нигездә, үзе кергән сүз белән янәшә килә, шуңа күрә аерымланмый:

*Самолет биектән оча.*

*Кояш югары күтәрелгән.*

**Вакыт хәле** – җөмләнең төрле урынында килеп, җиңел аерымлана.

*Сезгә хат язарга утыру белән,*

*Кинәт хат язуны артык зур эш диеп санадым* (Һ. Такташ).

Инверсияләнеп килгән вакыт хәле шулай ук аерымлана.

*Әйдә, җаный, озат мине, уйсу җиргә җиткәнче.*

Вакыт рәвешләре белән, урын-вакыт килешендәге бәйлекле һәм бәйлек сүзле исемнәр һәм исем ролендәге сүзләр белән белдерелгән вакыт хәле аерымланмый.

*Кич белән без разведкага киттек.*

**Сәбәп хәле.**

*Кечкенә вакытта ук бергә уйнап үскәнгә күрә, алар бер-берсенә бик ияләнгәннәр иде* (Ф. Әмирхан).

Җөмлә башында килгән “*шуңа күрә*”, “*шунлыктан*”, “*шуның өчен*”, “*шул сәбәпле*” кебек теркәгечләр өтер белән аерылмыйлар.

Инверсион сәбәп хәлләре шулай ук аерымланалар:

*Син иркәмә хатлар язам,*

*Якын күргән сәбәпле* (Жыр).

**Максат хәле.**

Нигездә, *өчен, дип* бәйлекләре белән килгән җәенке максат хәлләре аерымлана:

*Мин ярама куйдым ул яулыкны, басар өчен аккан*

*канымны* (М. Җәлил).

*Кичке ашны ашарга дип, алар өйгә таба киттеләр.*

Ләкин *өчен* бәйлеге белән максат хәлләре генә килми. Мәсәлән: *Энем өчен фотоаппарат сатып алдым.* (тәмамлык)

**Рәвеш хәле** аерымлануга бик иркен биреләләр (төрле фигыль формалары белән, бигрәк тә *-ып, -еп, -ый, -ә*, бәйлекләр ярдәмендә).

*Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата* (Г. Тукай). Җөмлә уртасында килгәндә, *-ып/-еп* формалы хәл кисәк группасыннан элек пауза зәгыйфьрәк булганга, гадәттә, өтерне аерымланган кисәктән соң гына куялар. Мәсәлән: *Заһид [,] әкрен генә барып, бу урындыкларның берсенә утырды.* Шуның нәтиҗәсендә ия белән хәбәр бер өтер белән аерыла. Типик ялгыш.

*Ак каенга асылынып менгән кебек,*

*Мин тормышта һаман яктыга ,*

*Югарыга таба юл алдым...* (Һ. Такташ).

Үзенчәлекле интонация һәм озын пауза белән әйтелә торган рәвеш хәлләре, хәбәр белән янәшә килгәндә дә аерымланырга мөмкин. Ләкин бу системалы күренеш түгел.

*Байлыкларын күреп - сокланам мин,*

*Эшләреңне күреп шатланам* ( С. Хәким).

**Шарт хәле** шулай ук үзе иялгән кисәктән ераклашса аерымлана:

*Үзеңне уйламасаң, безне кызганыр идең* (Г. Минский).

**Кире хәлгә** мисал: *Зөфәр, күпме колагын салып ятса да, аның сүзләрен аера алмады.*

**Күләм хәлләре** сирәк аерымлана. Мәктәп дәресләрендә аерымланмый дип тә йөртелде.

*Январьдан алып бүгенге көнгә кадәр, Айтуганов Уфа шәһәрендә лекцияләр укыды.*

**Аерымланган аныклагычлар.**

Аныклагычлар, нигездә, аерымланалар. Бер генә чыгарылма бар. Ияртүче сүз белән формасы ягыннан ярашмаган аныклагычлар аерымланмый.

Мәсәлән: *Без өчәү эшли башладык,*

*Мин үзем эшлим.*

Тыныш билгеләре күп төрле:

1) Сызык белән аерымлану. Аныклагыч та, аныкланмыш та исем белән белдерелеп, икесенең дә мәгънәләре бердәй булса, аныклагыч ике яктан да сызык белән аерыла.

Мәсәлән: *Нектар – баллы сыекча – күбәләкләр өчен генә түгел, башкаларга да азык.*

Аныклагычтан соң янәшә аныкланмыш ияргән сүз (ягъни хәбәр) килсә, сызык аныклагыч белән аныкланмыш арасында гына куела.

*Умырзаялар – кар гөлләре күренде.*

Тиңдәш аныклагычлар килгәндә шулай ук сызык куеларга мөмкин (аныклагыч, аныкланмыш исем белән белдерелмәсә дә).

*Без – руслар, украиннар, татарлар – корыч стена булып, сине якларга киттек* (Г. Кутуй).

2) Аныклагыч фигыль белән белдерелгән кисәкне ачыклап килсә, аныклагыч кисәк алдыннан ике нокта куела.

*Кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә* (Г. Тукай).

*Яшь акчарлаклар да ата-аналары кебек тырышалар: көне буе балык тоталар* (Ш. Камал).

3) Аныклагычлар тәрҗемә итү, искәрмә яки аңлатма бирү характерында булсалар, җәя эченә алыналар.

*Черелдәвекләр (сызгырак чыпчыклар) кешедән курыкмыйлар* (К. Тәһау).

4) Башка очракларда (зат алмашлыкларын, рәвешләрне, урын, вакыт хәлләрен аныклаганда, аныклаучы теркәгечләр белән килгәндә, һ.б. очракларда) өтер куела.

*Иртән без, өч кеше, катерда утыра идек.*

*Әнә тегендә, Агыйделнең аргыяк читендәге камышлыкта, аккошлар йөзә.*

Тиңдәшләнеп килергә дә мөмкин.

*Ә сез, гөлләр, гашыйкларның яры,*

*Миңа иң саф чәчәк бирегез* (Ш. Маннур).

**Җөмләдә сүз тәртибе**

Сөйләмдә сүз тәртибен өйрәнү бик әһәмиятле. Чөнки сүз тәртибе сүзтезмәләрдә һәм җөмләләрдәге сүзләр арасында мәгънә мөнәсәбәтләрен урнаштыруда катнаша. Мәсәлән, "*һава саф*" дигән тезмәдәге исем белән сыйфат арасында хәбәрлекле мөнәсәбәт урнашкан. Әгәр сүз тәртибе алмашынса, исем белән сыйфат арасында төгәлләүле мөнәсәбәт барлыкка килер иде: "*саф һава*".

Әйтмә сөйләмдә сүзләр шактый ирекле урнаша алалар, чөнки шулай да алар арасындагы бәйләнеш һәм мәгънә аңлашыла (бу очракта интонация ярдәмгә килә ала). Сөйләмә стиль 2 төрле була: гади сөйләм, әдәби сөйләм. Әдәби сөйләмдә сүз тәртибе шактый тотрыклы була. Гади сөйләмдә ирекле була.

Язма сөйләмдә сүз тәртибенә интонация артык зур тәэсир итә алмый. Шуңа күрә язма сөйләмдә сүзләрнең билгеле бер урнашу тәртибе, закончалыклары була. Гомумән, сүзләрнең ике төрле тәртибе бар:

- уңай (яки туры) тәртип;
- кире тәртип.

Сүз тәртибе төшенчәсе үзара ияртүле бәйләнештә торган сүзләрне генә карый. Тезүле бәйләнештә торган сүзләргә (ягъни тиңдәш кисәкләргә ул карамый).

**Уңай тәртип булганда**, хәбәрлекле мөнәсәбәттә ия алдан, хәбәр азактан урнаша. Тәгәлләүле мөнәсәбәттә торган сүзләрнең ияртүчесе алдан, ияртүчесе аннан соң килә. Аныклаулы мөнәсәбәткә кергән кисәкләрнең баш компоненты – алдан, ияреп килүче компоненты аннан соң урын ала. Сүзләрнең мондый тәртибе **туры тәртип** дип атала. Ул – гомумхалык телендә тарихи урнашып киткән закончалык. Сүзләрне шул рәвешле урнаштыру татар теленең грамматик үзенчәлекләреннән берсе булып санала, һәм аның әдәби нормасын тәшкил итә.

Җөмлә кисәкләренә күчереп, нәтиҗә ясасак, татар теленә түбәндәге закончалык хас дип әйтергә була.

1. Ия хәбәрдән алда килә.
2. Аергыч, тәмамлык, хәл үзләре ияргән сүздән алда киләләр.
3. Аныклагыч һәм өстәлмә үзләре ияргән сүздән соң урнашалар.

Мәсәлән: *Еракта-еракта, яшел болыннарның теге тарафында, сыек кына сөремгә бөркәнгән таулар күренә.*

Ләкин төрле сәбәпләр аркасында сүзләр, үзләренең гадәти урыннарыннан күчеп, башкача урнашырга мөмкин. Бу тәртипне сүзләрнең **кире тәртибе** яки **инверсия** дип атыйлар. Татар телендә кире тәртипнең берничә очрагы бар, ул 1) шигъри сөйләмдә, 2) тойгылы сөйләмдә, 3) җанлы сөйләмдә һәм 4) рәсми эш кәгазьләре стилендә күзәтелә. **Шушы очракларда сүзләрнең кире тәртибе татар теле өчен норма итеп карала.**

*1. Таң калып, мин карап торам*
*Кабынган йолдызларга...*

*Һич аңлатыр хәлләрем юк.*

*Ни булды бу дөньяга* (Зөлфәт).

Бу шигырьдәге сүзләрне туры тәртиптә урнаштыра алабыз, ләкин андый шигырь үзенең матурлыгын, төзеклеген югалтачак.

2. Тойгылы сөйләм хисле, тәэсирле яңгырарга тиеш. Хисләр, тойгылар байлыгын, матур яңгырашны бирер өчен, сүзләрнең кире тәртибе ярдәмгә килә. Тойгылы сөйләмдә, кагыйдә буларак, ия хәбәрдән соң урын ала.

*Шулай да бар иде бу кырларның сокландыгыч чаклары!* (Г. Бәширов).

*Остарды кеше врачларның башын әйләндерергә*! (Ә. Еники).

3. Сөйләм телендә дә, язма әдәби тел белән чагыштырганда, сүзләрнең урнашу тәртибе иреклерәк. Бу ирекле лек сөйләмнең алдан уйланып куелмаган булуы белән бәйле. Аралашканда, кеше әйтәсе фикерен алдан ук бөтен тулылыгы белән уйлап җиткерә алмый, соңыннан, исенә төшкән саен, сүзләрнең берсе артыннан икенчесен әйтә бара.

*Нәкъ шуны искәрткәндәй, Әхмәтсафа артык коелып төшмичә генә сүз башлап азаплана әнә:*

- *Кызлар килгән авылга, яңа мәчет тирәсендә кайнашалар, шуны әйтеп китим дигән идем дә...*

*Хәлфә сагаеп калды.*

- *Ни эшләргә соң миңа, энекәш? Бала-чага түгел икәнеңне беләм, дөресен әйтим, Шәмсия белән...* (Ф. Сафин).

4. Рәсми эш кәгазьләрендә, борынгыдан килә торган традиция белән, хәбәр үзе ияркән сүзләр алдына чыгарыла.

***“Белешмә***

*Бирелә Зөфәр Хәйрулла улы Биккининга шул хакта: чыннан да ул Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтының “Россия Федерациясе халыклары телләре” белгечлеге буенча читтән торып уку бүлегенең I курсында укый”.*

**Тематик (күзаллаулы) баш килешле әйләнмәләр**

Татар телендә **тематик баш килешле әйләнмәләр** дип атала торган төзелмәләр бар. Алар баш килештә булалар һәм, нигез җөмлә алдына чыгарылып, интонацион яктан аерылып куелалар.

*Туган җир. Аның нәрсә икәнлеге аерылгач беленә* (Ә. Баян).

*Ялгызлык... Мин бу сүздән куркам* (Н. Гыйматдинова).

Мондый әйләнмәләр фикерне калкурак, үтемлерәк, тыгызрак бирергә омтылу максатыннан килеп чыгалар. Алар аркылы авторлар үз фикерләрен кисәкләп-кисәкләп, сегментлаштырып белдерәләр кебек тоела.

Тематик баш килешле әйләнмәләр форма ягыннан эндәш сүзләргә һәм атау җөмләләргә охшаган булалар, ләкин аларны бу берәмлекләрдән аерып тора торган берничә үзенчәлек бар.

1. Гадәттә, нигез җөмләдә тематик баш килешле әйләнмәгә ишарә итә торган өченче зат күрсәтү алмашлыгы яки өченче зат тартым кушымчалы исем урын ала.

*Диңгез, диңгез, диңгез! Ул гүя җирне кочагына алган, ул бөтен табигать өстеннән хакимлек итә* (Ә. Еники).

*Мәче башлы ябалак. Аның бите миңа кеше бите булып күренде* (М. Галиев).

2. Эндәш сүзләр һәрвакыт икенче затка карый һәм җөмләнең теләсә кайсы урынында килә ала, күзаллауны белдерә торган баш килешле әйләнмә өченче зат белән мөнәсәбәттә була һәм үзе бәйләнгән җөмләдән алда килә.

*Рушад абый! Сез инде дөньяда мин барын оныткансыздыр да* (М. Мәһдиев). – эндәш сүз.

*Эзләр... Алар, чыннан да, ниләр генә сөйләми* (Г. Хәсәнов). – тематик баш килешле әйләнмә.

3. Атау җөмләләр үзләреннән соң килә торган җөмләгә интонацион, структур яктан бәйле түгел, алар аерым кулланыла ала. Тематик баш килешле әйләнмәләрнең андый мөстәкыйльлеге юк.

*Җәйге җылы төн. Күк йөзе яп-якты* (Г. Әпсәләмов). – атау җөмлә.

*Туган җир. Аның нәрсә икәнлеге аерылгач беленә* (Ә. Баян). – тематик баш килешле әйләнмә.

4. Тематик баш килешле әйләнмә һәрвакыт баш килештә була.

*Әни, әни!.. Ул бит Шәмсинең атасын да әнә шул ук станциядән, шулай ук елый-елый герман сугышына озатып калган* (Г. Бәширов).

*Салават күпере... Менә ул ерактагы таулар эргәсенә тын гына барып таяна, ничәмә төсләр белән балкып, үзенең дугалы капкасыннан санап-санап кына, болытлар кәрванын үткәрә* (Р. Низами).

**Өстәлмә (өстәлмә конструкцияләр)**

Сөйләмә телдә җөмләнең берәр кисәген җөмлә ахырына чыгарып, өстәп әйтү гадәти күренеш. Чөнки сөйләмә телдә, әдәби тел белән чагыштырганда, сүз тәртибе ирекле була. Сүзнең шундый ирекле тәртибе сөйләмә телдән әдәби телгә дә килеп керә. Ягъни әдәби телдә дә җөмләнең аерым кисәкләрен җөмлә ахырына калдырып, җөмләдән пауза белән аерып әйтәләр. Язуда мондый кисәкләрне нокта белән аералар. Шулай итеп “**өстәлмә**” дигән синтаксик күренеш барлыкка килә. Мәсәлән:

*Мин шунда банкетка чакырулы идем. Студентлар исеменнән* (М. Мәһдиев).

Җөмләнең аерым кисәкләрен җөмлә тышына чыгарып, “өстәлмә” итеп формалаштырып, язучы яки сөйләүче аларның мәгънәләренә игътибарны тагын да ныграк җәлеп итә. Безнең мисалда өстәлмә сүз җөмлә эченә кертеп әйтелсә, гадәти тәмамлык булыр иде: *Мин студентлар исеменнән шунда банкетка чакырулы идем.* Бу җөмләне *студентлар исеменнән* тезмәсен логик басым төшә торган итеп үзгәртергә була:

*Мин шунда банкетка студентлар исеменнән чакырулы идем.* Бу очракта, *“студентлар исеменнән”* тезмәсенең мәгънәсе билгеле арта. Ләкин өстәлмә итеп формалаштырсаң, аның мәгънәсе логик басым алган сүз мәгънәсеннән дә әһәмиятлерәк була.

Өстәлмәләр, аерым җөмлә кебек ул, алдагы төп җөмләдән зур пауза белән аерылалар.

Шулардан чыгып билгеләмәне түбәндәгечә бирергә була:

Мәгънәсенә ныграк игътибар иттерү өчен, төп җөмлә ахырына чыгарылган һәм аерым җөмлә интонациясе белән әйтелгән сүз яки сүзтезмә **өстәлмә** дип атала.

Өстәлмәләрне татар телендә беренчеләрдән булып Каюм Сабиров өйрәнә. 1956 елда нәшер ителгән “Татар телендә тыныш билгеләре” китабында рус телендәге “присоединительные конструкции” терминын тәрҗемә итеп “өстәлмә бәйләнеш” термины белән атый. Ф.С. Сафиуллина, Ш. Сайкин “өстәлмә конструкцияләр” термины астында өйрәнәләр. Академик грамматикада (М.З. Зәкиев) “өстәлмә” дип бирелгән.

Өстәлмәләрнең түбәндәге үзенчәлекләре бар:

- Өстәлмә үзе генә җөмлә төзи алмый, аңа хәбәрлек хас түгел;
- Өстәлмә төп җөмләдән зур пауза белән аерыла, фонетик яктан һәрвакыт мөстәкыйль фраза төзи;
- Төп җөмләдән нокта белән аерылып куела;
- Өстәлмә җөмлә ахырында урын ала;
- Өстәлмәләр төп җөмлә белән өстәлмә интонациясе һәм сүз тәртибе ярдәмендә бәйләнешкә керә;

(өстәмә чаралар булып төрле формаль күрсәткечләр килә ала)

**Өстәлмәләрнең төрләре**

Төзелешләре буенча өстәлмәләрнең **җыйнак һәм җәенке** төрләре бар.

- Бер мөстәкыйль сүздән торган өстәлмә **җыйнак** өстәлмә була. Мәсәлән: *Кранда эшләүче апа ялга киткәч, аның урынына чибәр генә бер кыз килде. Эльвира* (Җ. Тәрҗеманов).

- Берничә мөстәкыйль сүздән торган өстәлмә **җәенке** була. Мәсәлән: *Сандалда тимердән чүкеп ясаган чәчәк ята. Роза гөле чәчәге* (Казан утлары).

Кайсы кисәк (ия, тәмамлык, хәл һ.б.) белән бирелүләреннән чыгып төрләре:

Җөмлә була алмый, хәбәрлеге юк, шулай булгач өстәлмә хәбәр белән бирелә алмый, ким җөмләдә каралалар.

*Мин бик әсәйне сагынам. Кызганам да.*

Өстәлмә ия:

- *Аның янына көн саен бер матур карчык килә. Хатыны.*

Өстәлмә аергыч:

- *Күк йөзендә болыт ертыклары арасыннан кәкре ай сыныгы күренгәләп куя. Тонык, ямьсез* (Э. Касыймов).

Өстәлмә тәмамлык:

- *Утыз ел кешеләрнең йөрәк тибешен тыңладым. Солдат йөрәген* (А. Шамов).

Өстәлмә хәл:

- *Рәхәтләнеп бер туйганчы көлдем. Шатлыктан шартлый язып.*
- *Пальмалар алар читтән килгәннәр. Көньяктан.*
- *Җыелыш иртәгә булыр. Кичке сигездә һ.б.*

Өстәлмә аныклагыч:

- *Ул энесен сагына. Кечкенә генә энесен.*

Өстәлмә кереш сүз:

- *Хат язып сал әле. Зинһар!*

Өстәлмәләрнең мәгънәләренә басым ясауны арттырып, сөйләм яңалыгын белдерүләрен көчәйтеп, алар алдында: *бигрәк тә, өстәвенә, җитмәсә, аеруча* кебек сүзләр дә килә.

*Балалар тиз үсүчән була. Бигрәк тә оныклар.*

Өстәлмәләр инверсион кисәкләргә шактый якын торалар. Хәтта формаль яктан бер үк кисәк бер очракта өстәлмә, икенче очракта инверсион кисәк булырга мөмкин. Инверсион кисәк җөмлә тәмамланганчы әйтелә. Җөмләнең интонацион составына керә. Пауза өстәлмә белән чагыштырганда азрак була.

*Син китәсең, безне базга бикләп.*

*Хуш, иске ел, көмеш сакаллы.* (*көмеш сакаллы* – инверсион кисәк)

Инверсион кисәкләр поэзиядә еш очрыйлар. Өстәлмәләрдән аермалы буларак, аларның җөмлә белән бәйләнеше ныграк була. Ә өстәлмәләрнең бәйләнеше йомшак. Аларны төшереп калдырырга мөмкин.

## 8.2. Гамәли биремнәр.

**1 нче бирем.** Текстны укыгыз. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз. Аерымланган кисәкләрне билгеләгез.

*Кошлар рәхмәте*

*Бер төлке – хәйләкәр җанвар – кыр үрдәген оясыннан йолкып алып, урманга чаба. Аны бер абый күреп кала. Борчылып, шул урынга ашыга ул. Анда, ягъни ояда, ун йомырка күрә. Йортына алып кайтып, аларны кыртлап йөргән тавык астына сала. Бераздан ун бәбкә борын төртеп чыга.*

*Тавык үз вазифасын җиренә җиткереп үти: җәй буе чебешләрен (бәбкәләрен) ияртеп йөри, хәвеф-хәтәрдән саклый.*

*Кошлар (әлеге үрдәк бәбкәләре) үсә шулай. Җәй уза, һәм көз җитә. Бер көнне бәбкәләр, җирне калдырып, һавага күтәреләләр дә оча башлыйлар. Тавык, тревога игълан итеп кычкырса-кытакласа да, берни эшли алмый.*

*Тавыкны кызганса да, хуҗа моңа борчылмый. Шулай кирәклеген аңлый ул. Ә үрдәкләр, тавык белән хуҗага рәхмәтләрен белдереп, йорт өстендә берничә түгәрәк ясап, тыйнак кына бакылдашып, көньякка юл тоттылар. Шулай итеп, җәйге изгелекнең әрәмгә китмәвен сиздергәннәр алар.* (Әхсән Баяновтан)

**2 нче бирем.** Текстны укыгыз. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз. Аерымланган кисәкләрне билгеләгез.

*Чебешләр хакына*

*Чуар тавык белән Сарбайның дуслыгы бер дә әллә ни түгел иде. Тавык, чарылдап, каурыйларын кабарта. Ә Сарбай шаккатмый. Игътибарсыз гына узып китә. Күп вакыт исә үзенең такта куышы янында күзләрен-кашларын гына кыймылдаткалап, чебеннәр белән бәхәсләшеп ята. Сарбай шулай көннәр буе саклый үзенең кадерле оясын. Тавык җир тырный, җим эзли. Һәркемнең үз шөгыле.*

*Шулай да тавыкның мәшәкатьләре күбрәк. Көннәр буе җим эзләп тырнашу гына түгел, түл җыйгач, кытаклый-кытаклый йомырка саласы да бар. Йомырканы хуҗалар чүпли тора. Ә тавыкның исә чебеш чыгарасы килә.*

*Быел да башкалар салган йомыркаларны җылытып карады ул. Ләкин аны чырыйлатып кудылар. Инде йомыркаларны бакча буендагы әрекмән арасына салган иде, тик чөрләргә йөргәндә генә, ниндидер алама ерткыч йомыркалардан кабыклар гына калдырып китте.*

*Ниһаять, тавык гадирәк җир сайлады. Мамык-каурыйларын кабартыбрак йөрергә туры килсә дә, ояны Сарбай өе артында үскән кычыткан арасында ясады һәм йомыркаларны шунда сала башлады. Сарбай йомыркаларны иснәп карамады. Тавык чебеш чыгарырга утыргач та, узган-барганга аны-моны сиздермәде. Чебешләр чыккач исә, якынлык тагын да арта төште. Чебешләр әле курка белмиләр. Үз ояларыннан чыккач, беренче ныклап караган әйберләре эт оясы булды. Үз өйләрендәге кебек, һич тартынмыйча сикергәләп йөрделәр. Сарбай ятсынмады, кагылмады. Соңынтын, тегенди-мондый ерткыч үрмәләсә, чебешләрне*

*яклый, саклый торган булды. Сарбай белән чуар тавык дуслыгы чебешләр хакына озак дәвам итте.* (Әхсән Баяновтан)

**8.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар.**

1. Нинди кисәкләр тиңдәш кисәкләр дип атала?
2. Җөмлә кисәкләре тиңдәш булып килсен өчен, нинди шартлар кирәк?
3. Нинди җөмлә кисәкләре тиңдәш була ала?
4. Тиңдәш кисәкләрне теркәп, нинди грамматик чаралар килә ала?
5. Нәрсә ул гомумиләштерүче сүз?
6. Тиңдәш кисәкләр янында нинди гомумиләштерүче сүзләр килә ала һәм алар янында нинди тыныш билгеләре куела?
7. Нинди кисәкләргә синтагматик кисәкләр диләр?
8. Нәрсә ул синтагама?
9. Синтагма һәм сүзтезмә арасында нинди аерма бар?
10. Кайсы очракта җөмлә кисәкләре аерым синтагма төзи алалар?
11. Кайсы очракта җөмлә кисәкләре аерым синтагма төзи алмыйлар?
12. Нинди күренешкә җөмлә кисәкләренең аерымлануы дип әйтәләр?
13. Нинди җөмлә кисәкләре аерымлана ала?
14. Барлык хәл кисәкләре дә аерымланып килә аламы?
15. Җөмлә нинди актуаль кисәкләргә бүленә?
16. Тема белән рема җөмләдә ничек урнашалар?
17. Актуаль кисәкләргә бүленеше ягыннан рус һәм татар телләренең аермасы нидә?
18. Җөмләдә сүз тәртибе мәгънә белдерүдә катнашамы? Ничек?
19. Уңай һәм кире сүз тәртибендә җөмлә кисәкләре ничек урнаша?
20. Нинди мөнәсәбәттә инверсия була алмый?
21. Нәрсә ул өстәлмә?
22. Нинди җөмлә кисәкләре өстәлмә булып килә ала?

23. Өстәлмәләр һәм ким җөмләләр бер-берсеннән ничек аерыла?

24. Өстәлмәләр белән инверсион кисәкләр арасында нинди охшашлык һәм аерма бар?

**8.4. Презентация № 1.**

**8.5. Презентация № 2.**

**8.6. Презентация № 3.**

## 9. Лекция № 7

- **Җөмлә төрләре. Раслау һәм инкяр җөмләләр. Хикәя, сорау, боеру,тойгылы җөмләләр. Тулы һәм ким җөмләләр. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. Ике һәм бер составлы җөмләләр.**

**Аңлатма.** Әлеге тема гади җөмлә төрләре турында аңлатма бирә.

**Иң мөһим төшенчәләр.** Раслау, инкяр, хикәя, сорау, боеру, тойгылы, тулы, ким, җыйнак, җәенке, ике һәм бер составлы.

**Методик киңәшләр.**

- Тема теоретик мәгълүматны үз эченә алган лекциядән гыйбарәт;
- Мөстәкыйль эш өчен гамәли биремнәр тәкъдим ителә;
- Теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү максатыннан, теоретик сораулар, контроль эш биремнәре һәм тест бирелә.
- Лекция презентация белән үрелеп бара.

### 9.1. Җөмлә төрләре. Раслау һәм инкяр җөмләләр. Хикәя, сорау, боеру,тойгылы җөмләләр. Тулы һәм ким җөмләләр. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. Ике һәм бер составлы җөмләләр.

**Җ ө м л ә** - телнең, сөйләмнең иң төп синтаксик берәмлекләренең берсе. Кешеләр үзара җөмләләр ярдәмендә аңлашалар. Аңлашу вакытында сүзләр я турыдан туры җөмлә функциясенә куелалар (*Кыш. Төн.*) яки

җөмләнең бер кисәге функциясендә файдаланып, җөмлә оештыралар. Шул рәвешчә, сүз һәм сүзләр группасының аралашу, аңлашудагы функциясе җөмләдә реальләшә. Җөмлә булып формалашмаган сүз яки сүзләр аңлашу функциясен тиешенчә, кирәгенчә үти алмый, чөнки сүзләр һәм сүзтезмәләр җөмлә төзү өчен кирәкле материал гына. Үзара аңлашу, хәбәрләшү чарасы булсыннар өчен, алар грамматиканың билгеле бер кагыйдәләре, законнары буенча җөмлә итеп оештырылырга тиеш.

Нәрсә соң ул җөмлә? Сүздән һәм сүзтезмәләрдән ул үзенең нинди билгеләре белән аерыла?

Тел белемендә "җөмлә" терминына төрлечә билгеләмә биргәннәр. Беренче башлап синтаксис язган Аполлони Дископ (грек галиме) җөмләне сүзләрдән төзелгән берәмлек дип атаган.

К. Насыйри "Ике кәлимәдән төзелгән сүз тезмәсе" дип билгели (яки субъект, предикат).

Г. Алпаров "Баш килештәге иягә бәйләнеп, аңа ярашып әйтелгән хәбәрдән гыйбарәт сүзләр тезмәсе" һ.б.

Җөмләнең төп билгеләре түбәндәгеләр:

1) Интонация – пауза (хәбәр итү интонациясе). Сүз яки сүзләр тезмәсеннән аермалы буларак, җөмлә һәрвакыт хәбәр итү интонациясе белән әйтелә.

Мәсәлән: *Әминә, врач, Вил, инженер* – тиңдәш кисәкләр.

Хәбәр итү интонациясе белән: *Әминә - врач, Вил – инженер.*

Аерым сүзләр дә җөмлә төзи ала. Ләкин алар шулай ук тиешле интонация белән әйтелә.

Мәсәлән: *Көзге төн.* (җөмлә)

*Кыш.* (җөмлә)

Икенче бер җөмләләрдә шушы ук сүзләр җөмлә кисәге функциясен генә үтәргә мөмкиннәр.

*Көзге төн озын һәм караңгы була.*

*Кыш салкын була.*

Шулай итеп, интонация җөмләне грамматик формалаштыра торган чара булып тора.

2) Хәбәрлек (предикативлык), ягъни ике яки икедән артык сүздән торган төзелмәләрдә бер сүз икенче сүз турында нәрсә дә булса хәбәр итәргә тиеш. Бер генә сүз булганда, шулай ук, нәрсә турында булса да, нәрсәнең булса да булу-булмавы турында хәбәр итәргә тиеш.

Сәхнә. Урман. Кайтам. Кар эреде.

3) Модальлек (җөмлә эчтәлегенең чынбарлыкка булган мөнәсәбәте). Морфологиядә модальлек кушымчалары бар.

Хәбәр итү сөйләүченең тыңлаучыга, әйтелә торган фикергә, тирә-яктагы төшенчәләргә нинди дә булса мөнәсәбәттән тыш булмый. Сөйләүче шатланып, кайгырып, шикләнеп, гаҗәпләнеп һ.б. хәбәр итәргә мөмкин. Хәбәрлек гомумән хәбәр итү булса, модальлек ничек хәбәр итү. Швейцария галиме Шарль Балли “модальлек – җөмләнең рухы, җаны” дигән.

- *Нинди матур күл.* (соклану)
- *Алар урманга киткәннәрдер.* (ихтималлылык)
- *Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр.* (уфтану, шикләнү)

Җөмләнең төп билгеләренең тагын берсе – сүзләрне билгеле бер телгә хас грамматик юл белән бәйләнүе ► бу сүзтезмәләрдә дә шулай.

Сөйләмнең фикерне, кичерешне һәм ихтиярны хәбәр итә һәм сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерә торган иң кыска берәмлеге **җөмлә** дип атала.

Татар телендә гади җөмләнең типлары һәм төрләре бик күп. Телчеләр бу фактка күптән игътибар итткәннәр.

1846 елда ук А. Казембек 9 төрле җөмлә күрсәткән (тулы, ким, җыйнак, җәенке, хикәя, сорау, шарт, барлык, юклык).

К. Насыйри исем, фигыль, сорау, урын (*Атам Казанда торадыр*) җөмләләрне күрсәтә.

1919 елда М. Корбангалиев тулы-ким, өндәү-сорау-хикәя, ияле-иясез, барлык-юклык, җәелгән-җәелмәгән, оешма җөмләләр турында яза.

≈ 40-60 нчы елларда төзелгән урта мәктәп грамматикаларында сөйләүченең куйган максатлары буенча: хикәя, сорау, өндәү, боерык; составындагы кисәкләр, сүзләр нигезендә: җыйнак-җәенке, ияле-иясез, тулы-ким, инфинитив, атау җөмләләр күрсәтелә (В.Н. Хангилдин).

## I. Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре.

Аралашу процессында сөйләүче үз алдына төрле максатлар куярга мөмкин. Сөйләүче нәрсәне дә булса белергә теләп, сорау куярга, нәрсәне дә булса теләп боерырга яки гади генә хикәяләргә мөмкин. Шулардан чыгып, хикәя, боерык, сорау җөмләләр аерылып чыгарыла. Алдарак, җөмләне белдерә торган бер билге итеп интонация булуын әйтеп үткән идек. Татар телендәге хикәя, сорау, боерык җөмләләрдә без аның ролен аеруча нык сизәбез. Бер үк җөмләне төрле интонация белән әйтеп, җөмләнең төрен үзгәртергә мөмкин.

*Димәк, миңа булган бурычыңны иртәгә түлисең.* (хикәя)

*Миңа булган бурычыңны иртәгә түлисеңме?* (сорау)

*Күп сөйләнеп торасы юк. Миңа булган бурычыңны иртәгә үк түлисең.* (боерык)

**Хикәя җөмлә** булганда чынбарлыкта булган күренеш, әйберләр турында талгын ачышлы хикәяләү тонында хәбәр ителә:

*Тау башына салынгандыр безнең авыл.*

*Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул* (Г. Тукай).

Хикәя җөмләләр, чагыштырмача тыныч тавыш белән әйтеләләр. Конкрет күрсәткечләре юк.

**Сорау җөмлә** – нинди дә булса сорауны белдергән һәм сорау интонациясе белән әйтелгән җөмләләр.

Махсус сорау интонациясе белән белдерелүдән тыш, төрле лексик-грамматик чаралар ярдәмендә белдерелә.

а) *-мы, -ме; -мыни, -мени* сорау кисәкчәләре ярдәмендә:

*Апалар кайттымы? Апалар кайттымыни?.* Шуны да искәртергә кирәк: бу кисәкчәләрнең мәгънә төсмерләрендә беркадәр аерма бар.

- беренче очракта (*-мы*) сөйләүчегә алдан бөтенләй билгеле булмаган әйбер турында сорала;

- икенче очракта (*-мыни*) сөйләүче бераз күзаллаган, нигездә, аңа мәгълүм булган әйберне сорый. Бу кисәкчәләр янында *икән, соң, әллә* сүзләре дә килергә мөмкин:

*Сандугачлар килгән безгә,*

*Китмәсләр микән көзгә?* (М. Җәлил).

*Бу синме соң?*

б) сорау җөмләне формалаштыруда *-дыр, -дер, -тыр, -тер* кисәкчәләренең дә әһәмияте зур:

*Апаларның кайтачагы сезгә билгеледер?*

в) *бәлки, әллә* кебек сүзләр кайбер очракларда сорау җөмлә формалаштыралар:

*Әллә инде килеп тә җиттеләр?*

г) сорау алмашлыклары ярдәмендә:

*Кем идең, кем булдың?* (Г. Тукай). (исем алмашлыгы)

*Нинди упкынга төштегез?* (сыйфат алмашлыгы)

*Ничек соң тормышың, ничек көн күрмешең?* (рәвеш алмашлыгы)

Сорау җөмләләрне тагын җавап таләп итеlә һәм җавап таләп ителми торган сорау җөмләләргә дә бүләләр. Икенче төрне риторик сорау җөмлә дип атыйлар.

*Бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадерен белү?!*

*Без аны кайдан белик, мискин, үлеп аңлатмагач?!* (Г. Тукай).

Сорау күрсәткечләре булу бу әле сорау җөмлә дигән сүз түгел.

Мәсәлән: *Мин сезгә Илдарны җибәрәмме?* (сорау)

*Җибәрәмме соң үзеңне генә, җибәрмим.* (хикәя)

*Бу нинди савыт?* (сорау)

*Нинди генә савыт юк монда?!* (сорау җөмлә түгел)

**Боеру җөмлә.** Сөйләүченең тыңлаучыга яки тыңлаучы ролендәге предметка берәр эшне яки хәлне башкарырга яисә аннан тыеларга кушу, үтенү, боеру, чакыруны белдерә торган җөмлә.

Татар әдәби телендә боеру җөмләгә түбәндәге үзенчәлекләр хас:

1) Боеру җөмләнең үзенә хас интонациясе була.
2) Боеру җөмләнең хәбәре боеруны белдерә торган формалар ала.

- Боерык фигыльләр белән:

*Җырлыйк дусларым, җырлыйк бергәләп;*

*Чыкчы, и фикерем кояшы, китсен өстеңнән болыт* (Г. Тукай).

- Инфинитив белән:

*Алдынгылык өчен көрәшергә, кулдан ычкындырмаска.*

- Хикәя фигыль белән:

*Тавышны бетердек.*

- Шарт фигыль белән:

*Бирсәгезче бер тиен тик, тәңкә түгел бит, тиен* (Г. Тукай).

3) Боеру җөмләдә *әйдә, әйдәгез, әйдә әле, ягез әле* кебек күрсәткечләр була (әйдә - импер. ымлык).

*Әйдәле, Акбай, өйрән син!* (Г. Тукай).

4) Хәбәрлек сүзләр катнашырга мөмкин.

*Бу мәсьәлә турында күбрәк укырга кирәк.*

*Аны тыңламыйча ярамый.*

**II. Җөмләләрне көчле хис-тойгы белән әйтү-әйтмәүгә карап тойгылы яки тойгысыз** җөмләләргә бүләләр. (Бүленештә ныклы фәнни принцип ятмый, чөнки теге яки бу җөмләне сөйләүче үз теләге белән тойгылы итеп тә, башкача да әйтергә мөмкин) (элекке грамматикаларда өндәү җөмлә дигән термин алынган иде. Өндәү сүзе күбрәк боеру мәгънәсен белдерә, шуңа күрә уңышлы термин түгел).

Көчле тойгы белән әйтелә торган җөмләне **тойгылы җөмлә** дип атыйлар. Тойгы белдерүне ике төргә бүлеп йөртәләр:

а) сөйләүченең эчке кичерешләрен, эчке халәтен белдерү (ачу, кәеф китү, соклану, үкенү, нәфрәт, кайгыру, курку һ.б.);

б) сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерү (ышану – ышанмау, шикләнү, гаҗәпләнү, хуплау, ризасызлык, ирония, кимсетү, кызгану, иркәләү һ.б.).

Тойгылы җөмләләр иң югары тонда ачык итеп әйтеләләр. Тавыш хәрәкәте кискен була (кинәт күтәрелә яки төшә ...). Тойгыны белдерә торган иң әһәмиятле чара – интонация (тойгы интонациясе). Тойгы интонациясе белән әйтеп, хикәя, сорау, боеру җөмләләрдән тойгылы хикәя, тойгылы боеру һәм тойгылы сорау җөмләләр барлыкка килә.

**Тойгылы хикәя җөмлә**: *И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!* (Г. Тукай).

*Ах, таныш йортлар, тәмам күздән дә сез югалдыгыз!* (Г. Тукай).

**Тойгылы боеру җөмлә**: *Тор, шәкерт! Җиттек Казанга* (Г. Тукай).

*Әйтегезче миңа, мәтрүшкәләр!* (И. Юзеев).

**Тойгылы сорау җөмлә**: *Кайгымени бу?!*

*Әле син безнең арага кермәкче буласыңмыни?!*

Тойгылы җөмләләрне интонация белән генә түгел, махсус грамматик чаралар белән дә белдерергә була:

а) ымлыклар ярдәмендә (*их, ух, и,һай, аһ ...*);

*Их, кичә генә әле февраль иде* (Һ. Такташ).

б) *кит аннан, менә сиңа мә, кара син аны* кебек сүзләр һәм сүзләр тезмәсе белдерергә мөмкин:

*Кара син аны, нәрсә дип торган була.*

в) кабатлаулар белән:

*Кадерле, бик кадерле ул үткән гомер!* (Ә. Еники).

*Әйе, дөнья матур, чиксез матур!* (М. Әмир).

г) сорау алмашлыклары ярдәмендә:

*Нинди аяз, нинди тыныч, нинди гаҗәеп рәхәт!* (Ф. Әмирхан).

д) хәбәрнең *-сы/-се + иде; -са/-сә +иде; -чы/-че* формалары белән килүе:

*Бөдрә талга килеп кунсаңчы!* (Ш. Мөдәррис).

*Их, туйганчы бер йокласаң иде!* (Г. Ибраһимов).

**III. Җөмләнең иярчен кисәкләренең булу-булмавыннан чыгып, җәенке һәм җыйнак җөмләләр була.**

Бер һәм ике составлы гади җөмләләрнең бары тик баш кисәкләрдән генә торган төрләрен **җыйнак җөмлә** дип атыйлар.

а) ия һәм хәбәрдән торырга мөмкин:

*Атлар да чабышты, малайлар да йөгереште, яулыклар да алынды* (Г. Тукай).

*Шаулый диңгез, җил өрәдер* (Дәрдемәнд).

б) бер баш кисәкле җыйнак җөмлә:

*Сәхнә. Палатка. Төн. Тантана.*

*Аңламадым.*

Иярчен кисәкләр белән җәенкеләндерелгән җөмләләр **җәенке җөмлә** дип атала (“таркау” җөмлә дигән термин да кулланылган).

*Әкрен генә ал таң ата* (Г. Тукай).

**IV. Оештыра торган үзәкнең санына карап, гади җөмләләр I составлы һәм II составлы дигән төрләргә бүленәләр.** Җөмләнең барлык кисәкләре бер баш кисәк янына оешса, 1 составлы җөмләләр барлыкка килә. I составлы җөмләләргә икенче баш кисәкне өстәп карап та булмый. Мәсәлән: *Чебешне көзен саныйлар* (иясе юк, һәм куеп карап та булмый, димәк бу I составлы җөмлә).

Җөмләнең ике баш кисәге дә булса бу II составлы җөмлә була: *Безнең Гали бигрәк тату кәҗә белән* (Г. Тукай).

Җөмлә бер баш кисәктән генә торып, аңа икенче баш кисәкне (ияне) куеп карап булса, II составлы җөмлә була.

*Киләм синең рәсемең каршына.* дигән җөмләдә хәбәр – *киләм*, иясе юк, ләкин аны куеп карап була. Иясе – *мин*, чөнки *киләм* дигән хәбәргә башка бер сүзне дә куеп булмый. Бу шулай ук II составлы җөмлә. Димәк, берәр баш кисәге булмаса һәм аны куеп карау мөмкинлеге дә булмаса, I составлы җөмләләр барлыкка килә:

*Кыш. Буран. Салкын һава.*

Баш кисәкләрнең бирелүенә карап I составлы җөмләләр өч төргә бүленәләр.

- фигыль (иясез);
- атау (исем);
- сүз.

**Фигыль җөмлә** (иясез җөмлә дип тә аталалар). Баш кисәге фигыль һәм процессны белдерә торган башка сүзләр белән бирелгән җөмләләр (ияләре юк, куеп карап та булмый). Бу төр җөмләләр процессны, эшне

хәбәр итәләр. Ләкин бу эшне үтәүче, субъект билгеле булмый, билгеле булса да аны ия итеп куеп булмый. Шуннан чыгып, иясез җөмләләр билгеле үтәүчеле һәм билгесез үтәүчеле җөмләләргә бүленәләр.

**Билгеле үтәүчеле** җөмләләрнең үтәүчесе конкрет билгеле була. Мәсәлән: *Аларга озак шатланырга туры килмәде.* (үтәүчесе – *Аларга,* ләкин ия түгел, чөнки баш килештә түгел).

Билгеле үтәүчеле җөмләләр:

*Сиңа эш эзләргә кирәк. Минем бер дә ялгыз каласым килми.*

*Хәзер эчәсем килми (минем), билгеле.*

*Кичә күп йөрелде, арылган.* (үтәчесе – сөйләүче үзе)

*Бер яткач, озак йокланылган* (И. Гази).

**Билгесез үтәүчеле** (үтәүчесез, гомуми үтәүчеле) җөмләләрдә үтәүче билгеле булмый.

- *Чебешне көзен саныйлар.*
- *Яктыра башлады. Туңдырды. Салкынайтты.*
- *Фәхрине яраталар иде.*
- *Ни чәчсәң, шуны урырсың.*
- *Урамда яланаяк йөрерлек түгел.*

**Атау җөмлә** әйберләрнең, билге, күренешләрнең исемнәрен атау юлы белән аларның булу-булмауларын хәбәр итә торган җөмлә (бер составлы исем җөмлә).

- Табигать күренешләрен тасвирлыйлар: *Кыш. Буран. Салкын һава.*
- Билге, процессны атап күрсәтәләр: *Кичә, биюләр, җырлар.*
- Төрле обстановканы, урынны: *Сәхнә. Урман. Матур алан. Зур кабинет, ике якта өстәл* (сәхнә әсәрләрендә файдаланалар).
- *Энә, менә* сүзләре белән килү очраклары күп.

*Менә фронт. Әнә урман.*

**Сүз җөмлә** - 1 генә сүз белән бирелеп, башка сүзләрне ияртеп җәенкеләндерелми торган җөмләләр.

Сүз җөмләләрне җөмләнең аерым бер логик-грамматик кисәгенә тиңләп булмый.

Бу җөмләләр сөйләүченең төрле тойгыларын белдерәләр. Ымлыклар, аваз ияртемнәре, хәбәрлек сүзләр белән бирелергә мөмкин.

*Тукта! Чү! Ямьсез тавышлы әллә нәрсә кычкыра.*

*Яхшы. Хуш. Батты кояш.*

*Әйе, Ә. Уф.* һ.б.

**V. Хәбәрлекнең реаль булу-булмавыннан чыгып, раслау яки инкяр җөмләләр була.** Раслау җөмләләр процессның, күренешнең булуын раслыйлар. Нигездә, инкяр кушымчаларын алмыйлар: *Бүген лекция була.*

Кайбер очракларда берьюлы ике инкяр күрсәткече алып, раслау җөмлә барлыкка килә.

- *Фронттан кайтучыларның берсе генә дә орденсыз түгел.*
- *Кат-кат кияүгә сорап тилмертүче егетләр дә булмады түгел* (Ф. Сафин).

**Инкяр җөмләләр** процессның, күренешнең, билгенең булуын инкяр итәләр.

Түбәндәге чаралар ярдәмендә бирeләләр:

а) *түгел* сүзе белән: *Тик чуклары ал түгел* (М. Җәлил).

б) *юк* хәбәрлек сүзе белән: *Үпкә дә юк, артык ачу да юк,*

*Болай гына борын салынган* (Һ. Такташ).

в) юклык кушымчалары белән: *Эт оясы кыегына сандугач кунып сайрамый* (Мәкаль).

г) *-сыз/-сез* кушымчалары ярдәмендә: *Бу илдә без барыбыз да бәхетсезләр.*

д) интонация (ирония белән әйтелә):

- *Ул әле кайтканмы?*

- *Кайткан ди! (кайтмый ни)*

е) интонация һәм сорау алмашлыклары бергә килә:

- *Син авылга кайтасыңмы?*

- *Нәрсә калган соң анда миңа?!*

Инкяр җөмләләр тулы һәм өлешчә инкяр җөмләләргә бүленәләр.

Җөмләнең хәбәре инкяр ителсә, **тулы инкяр җөмлә** була. Хәбәрдән башка кисәге инкяр ителсә **өлешчә инкяр җөмлә** дип атала.

*Күптән түгел безнең тәрәзә капкачын,*

*Оя итте минем сөйгән карлыгачым* (Г. Тукай).

*Ерак түгел моңаеп утыра ромашка кызы* (М. Җәлил).

**VI. Тулы һәм ким җөмләләр.**

Җөмләдә әйтелергә мөмкин булган сүзләрнең булу-булмавыннан чыгып, гади җөмләләр **тулы һәм ким җөмләләргә** бүленәләр.

Тулы җөмләдә бер генә элемент та төшерелмәгән була һәм аңа үзеннән-үзе аңлашыла торган бер генә элемент та өстәп булмый.

Тулы җөмләләр текст, бүлек башларында күбрәк кулланылалар. Төрле кагыйдәләр, карарлар, боерык, закон, указлар тулы җөмләләр белән языла.

**Ким** җөмлә дип контекст, обстановка, мимика, жестлардан аңлашылган кисәге төшеп калдырылган, кулланылмаган җөмлә атала.

Мәсәлән: *Мин заводта эшлим. Абыем шәһәр мәгариф бүлегендә эшли*. дигән җөмләләр тулы җөмләләр: *Мин заводта эшлим. Абыем шәһәр мәгариф бүлегендә*. булса, 2 нче җөмлә ким, чөнки беренче җөмләдән аңлашылган *"эшли"* сүзе (хәбәр) төшеп калган.

Ким җөмләләрнең кимлек сәбәпләре берничә төрле:

- Кулланылмаган кисәкнең мәгънәсен контекст бирә. (безнең мисал)
- Теге яки бер сүз обстановкадан аңлашыла:

Мәсәлән: *Көймәдә баручы бер кеше икенчесенә*

- *Иш әйдә, иш! – дип әйтә икән* (бу ким җөмлә) барысы да аңлашыла. Тулы җөмлә булса: *Син, әйдә, көймәне иш*! – дип әйтергә тиеш була.

Кайсы кисәкнең кулланылмавына карап, ким җөмләләрнең төрләре:

- Иясе әйтелмәгән ким җөмләләр:

*Аңа ышанмыйм инде хәзер*. (мин)

- Хәбәре әйтелмәгән ким җөмләләр:

- *Кайда эшлисез?*

- *Мин заводта. Абыем мәгариф бүлегендә.*

- Берничә кисәге (иясе, хәбәре дә) берьюлы әйтелмәгән:

- *Кайдан килдегез?*

- *Авылдан.* (без, килдек)

- *Кайчан?*

- *Кичә.*

- Иярчен кисәкләре төшеп калган ким җөмләләр:

*Театрга барасың киләме? Килә.* (театрга)

**VII. Тиңдәш кисәкле яки тиңдәш кисәксез.**

**VIII. Аерымланган кисәкле яки аерымланмаган кисәксез.**

**IX. Гади һәм кушма.**

**X. Тәмамланган һәм тәмамланмаган.**

*Алмагачы бүген бөрелгән,*

*Чәчәк атар, ахры, иртәгә.*

1. Гади, тулы, җәенке, 2 составлы раслау, хикәя, тойгысыз, тиңдәш кисәкле, аерымланган кисәксез җөмлә.

2. Сүзләр бәйләнеше.

3. Синтагма.

4. Тыныш билгеләре.

5. Сүз тәртибе (кире).

## 9.2. Гамәли биремнәр.

**1 нче бирем.** Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз, төрләрен билгеләгез. Җөмләләргә билгеләмә бирегез.

*Яшь имәннең төбен йомшартып, яфракларын сөртеп торганда, әрәмә башындагы Олы күл ягыннан кинәт кенә җиз торбадан чыккандай калын һәм яңгыравыклы аккош тавышы ишетелде. Бу моңлы һәм матур тавыш түгәрәк алан өстеннән тагын яңгырап китте. Аңа икенче аккош тавышы кушылды. Өченче, дүртенче! Инде дүрт аккош берьюлы кычкыра башлады.*

*Без шатлыктан ни әйтергә дә белмәдек. Чөнки бу Олы күлдә гомер-гомергә пар аккош яши иде. Кояшлы халкы аларны бик ярата һәм*

*чит авыллар алдында горурлана, бала-чага шикелле мактанып та куя иде. Ләкин әрәмәне кискәннән соң, алар Олы күлне ташлап китте. Яз көне ничә еллар буе гомер иткән, нәни балалар чыгарган оялары өстеннән моңсу һәм кайгылы тавыш белән кычкыра-кычкыра очып йөргәннәрен күрүчеләр булган. Тик алар суга төшмәгәннәр. Моңланып кычкыра-кычкыра, чит-ят җирләргә очып киткәннәр.*

*Шуннан соң менә ничә ел үтте – күренмәделәр. Олы күл, ятим шикелле, моңсу гына шаулап буш торды.*

*Ә менә хәзер кайтканнар! Әйләнеп кайтканнар! Бер генә дә түгел – ике пар!* (Г.И.)

**2 нче бирем.** Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз, төрләрен билгеләгез. Җөмләләргә билгеләмә бирегез.

*Төньяк кунагы*

*Елның теләсә кайсы фасылында урманны күзәтергә яратам мин. Бер үк вакытта урманның саф һавасын сулап туя алмыйсың. Менә бүген дә килми кала алмадым мин берегә. Челтәрләнгән кардан бераз гына калкып торган сукмак мине урман эченә алып керде.*

*Бара торгач, әкияти дөньяга килеп кергәнемне сизми дә калдым. Ихтыярсыздан, Амур бәрхете куаклыгы янында туктадым. Каяндыр көмеш кыңгырау зыңы ишетелә. Кемдер, күзгә күренмичә генә, вакыт-вакыт кечкенә кыңгырауга чирткәләп куя сыман. Шул зың яңгырап көйгә әверелә дә тирә-якны моңга күмә.*

*Башымны күтәреп карасам, артык биек булмаган шәрә агач ботагында дистәләгән бүрекле кош утыра. Болар – урман чыпчыклары. Алар ерак тайга, урман-тундра якларыннан безгә кыш чыгарга килгәннәр. Урман чыпчыклары язын, тайга урманнарына кайтып, бала чыгаралар, аларны төрле бөҗәкләр белән туендыралар. Көзен яңадан көтү-көтү булып безгә очып киләләр. Урман чыпчыкларының иң яраткан азыклары – миләш һәм гөлҗимеш.*

*Урман чыпчыклары гәүдәгә сыерчык кадәр генә. Башларында, артка тарап җибәрелгән чәч сыман, коңгырт төстәге киң бүрек.*

*Канатларында ачык кызыл төстәге таплар бар – балан сытылган диярсең. Койрыкларындагы сары кайманы гына күр син!*

*Ботактан ботакка куның, сайрашып, кошлар Амур бәрхетенең кара төстәге эре җимешләрен чүплиләр. Мин, аларның бу лирик тамашаларын күзәтеп, бик озак басып тордым.*

*Кайда да булса көмеш кыңгырау авазы ишетәсең икән, тукта да безнең кышкы кунакны – урман чыпчыгын эзләп тап.*

*Озакламый бүрекле себер кошлары, безне калдырып, төньякка очып китәрләр.* (Н.Акулов).

## 9.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар.

1. Гади җөмлә нинди принциплардан чыгып анализлана?
2. Раслау һәм инкяр җөмләләр бер-берсеннән ничек аерыла?
3. Инкяр җөмләләрнең күрсәткечләре нинди?
4. Нинди җөмләләргә хикәя, сорау, боеру җөмләләр диләр?
5. Сорау җөмлә нинди чаралар ярдәмендә белдерелә?
6. Тойгылы җөмлә нинди җөмлә ул?
7. Җыйнак белән җәенке җөмлә бер-берсеннән ничек аерыла?
8. Нинди җөмләгә тулы җөмлә диләр?
9. Нинди җөмләгә ким җөмлә диләр?
10. Ким җөмләне нинди максатлардан чыгып тикшерергә мөмкин?
11. Бер һәм ике составлы җөмләләр нинди җөмләләр алар?
12. Бер составлы җөмлә нинди төрләргә бүленә?
13. Бер составлы фигыль җөмләнең нинди төрләре бар?
14. Исем җөмлә нинди үзенчәлекләргә ия?
15. Сүз җөмлә ничек ясала?
16. Тәмамланган һәм тәмамланмаган җөмләләр бер-берсеннән ничек аерыла?

## 9.4. Мөстәкыйль эш өчен биремнәр.

**1 вариант**

1. Текстны укыгыз, җөмлә кисәкләрен билгеләп чыгыгыз, төрләрен аерыгыз. Җөмләләргә тулы билгеләмә бирегез.

*Каенсарга быел да бардык. Башта барысы да гадәттәгечә: үткән еллардагы кебек иде. Ләкин юк икән. Үзгәргән икән быел урман. Каеннар зифа билләренә ак алъяпкычлар бәйләгәннәр быел. Алъяпкычларын шундый да чиста итеп, пакъ итеп юганнар... Узган ел бу усак яфракчыклары яшел генә иде. Ә быел... Әнә аз гына җил исеп китте. Бөдрә усак ябалдашы күгелҗем, аксыл һәм көмеш төсле яфраклар белән чуарланды. Кара инде, күгелҗем яфраклар, аксыл яфраклар, көмеш төсле яфраклар да була икән ич... Моңарчы хуш исе белән генә үзенә җәлеп итә иде әле безне миләүшә. Исе генә түгел, төсе, буй-сыны да никадәр нәфис, нинди гүзәл икән бу чәчәкнең. Нәп-нәни бер таҗ яфракчыгында гына да никадәр төс, никадәр бизәк. Челтәрле-телле очкайлары шәмәхә-зәңгәр. Аннары күксел-зәңгәр, аксыл-зәңгәр, аксыл-саргылт, сап-сары төрткеләре, кып-кызыл җепселләре дә бар. Бу төсләр барысы да бер нәни таҗчыкка шундый да матур бизәкләр булып сыеп беткәннәр...*

*Урманда кошлар сайрый. Урман шуңа күрә генә матур яңгырап тора иде кебек моңарчы. Юк икән. Урманда кошлар гына сайрамый икән. Урманда һәр агач, яңа шыткан һәр үлән, йокыларыннан уянган һәр бөҗәк җырлый, көйли икән.*

*Болар барысы да күңелне җилкетә. Гел елмаясы һәм нигәдер елыйсы да килә иде* (Р. Төхфәтуллин).

2. Түбәндәге шигъри юлларга үз мөнәсәбәтегезне белдереп, гади җөмләләрдән хикәя төзеп языгыз.

***Биек-биек таулар бар,***

***Тау башында ташлар бар;***

***Өсләренә таш яуса да,***

***Иелмәгән башлар бар*** (Ф.Яруллин).

**2 вариант**

1. Текстны укыгыз, җөмлә кисәкләрен билгеләп чыгыгыз, төрләрен аерыгыз. Җөмләләргә тулы билгеләмә бирегез.

*Өй буенда бөдрәләнеп үскән яшь каенга карап, Мәдинә уйга калды. Нинди нәфис, назлы булып үсеп килә ул! Мәдинә табигатьнең матурлыгына сокланып туя алмый. Тик бүген аның яшь йөрәген ниндидер татлы, ләззәтле сагыш баскан. Ул үзенең авылдагы әнисен, бала чакта бергә үскән дусларын сагына. Аның күңеле авылга, алар янына ашкына.*

*Кайчан гына имтиханнар бетәр икән? Бәлки, бер генә атнага булса да, әнием янына кайтып килер идем. Кочагыма алып, кысып-кысып сөяр идем үзен, иркәләр идем. Куаныр иде дә соң әнием!*

*Нинди ягымлы, сөйкемле ул минем әнием! Ә үзе нинди олы җанлы! Шул кечкенә генә гәүдәле әнием берсеннән-берсе таза, берсеннән-берсе чибәр дүрт егет, бер кыз үстергән. Мин аның төпчек кызы! Шуңамыдыр, мине һаман кечкенә итеп күрәсе килә. Ә үзе хәзер иягемнән генә булып калды.*

*Әнием инде бик картайган. Сугышта үлгән әтием белән олы абыемның сагышы аның йөзендәге алсулыкны гомергә җуйган, чәчләренә чал кергән. Никадәр генә яхшы тәрбиядә яшәсә дә, көннән-көн картайган төсле күренә. Аны сабый баладай иркәлисе, ягымлы сүзләр әйтеп, күңелен юатасы килә.*

*Мәдинә, шундый татлы хыялларга бирелеп, өстәл яныннан сикереп торды да, жакетын киеп, урамга чыкты. Аның әле башыннан кичергән бөтен сагышы, хыялы кулындагы зәңгәр конверт эченә бөленеп салынган иде* (Ә. Бикчәнтәева).

2. Түбәндәге шигъри юлларга үз мөнәсәбәтегезне белдереп, гади җөмләләрдән хикәя төзеп языгыз.

***Бөркетләр***

***Тауда туа,***

***Батырлар***

***Яуда туа!*** (Р. Миңнуллин).

### 9.5. Тест.

**1 вариант**

1. Аерып бирелгән төзелмәнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез:

*Мин, пырхылдап **көлеп җибәрмәс өчен**, авызымны каплады*м (Н. Гыйматдинова).

1) хәбәр

2) максат хәле

3) сәбәп хәле

4) кыек тәмамлык

2. Аерып бирелгән төзелмәләрнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез:

*Өйрәттең **гаделлек, сабырлык, акылга,***

*Гел алга, гел алга барырга* (Ш. Җиһангирова).

1) кыек тәмамлык, кыек тәмамлык, кыек тәмамлык

2) туры тәмамлык, туры тәмамлык, кыек тәмамлык

3) ия, ия, кыек тәмамлык

4) туры тәмамлык, туры тәмамлык, урын хәле

3. Әлеге өзектә ничә җыйнак җөмлә бар?

*Яшел чирәм.*

*Кояш көлә.*

*Яшь балалар чыр-чу килә.*

*Йомгак кебек сары бәбкә*

*Өзмәк була яшел чирәм,*

*Ава-түнә...*

*Хәле җитми.*

*Тагын, тагын тартып карый,*

*Булмый!*

*Сабый көлә.*

*Көлә-көлә*

*Атлап китә, ава-түнә,*

*Чирәм буйлап – киләчәккә!* (Ш. Җиһангирова).

1) 3

2) 4

3) 5

4) 2

4. *Чая, тере Миңҗамал апа аяк очларына карап сүзсез калган иде* (Н. Гыйматдинова). Бу җөмлә:

1) раслау

2) тулы инкяр

3) өлешчә инкяр

5. *Кинәт яңгыр ява башламасынмы?!* (Г. Гыйльманов). Бу җөмлә:

1) раслау

2) тулы инкяр

3) өлешчә инкяр

6. Өзектә бирелгән бер составлы фигыль җөмләнең төрен билгеләгез:

*Бөтенесенә дә шул Язмыш гаепле, ахры. Үзләреннән башка гына кешеләрнең яшәвен, тормышын, бәхетен-бәхетсезлеген хәл итә торган көч бугай ул.* ***Менә шул көч белән дуслашсаң иде дә..****. Гел ярдәм итеп торыр иде ул. Әйбәт укыр иде Зөһрә* (Г. Гыйльманов).

1) билгесез үтәүчеле
2) билгеле үтәүчеле
3) гомум үтәүчеле
4) үтәүчесез

7. Төшеп калган сорау күрсәткечләрен дөрес итеп урнаштырыгыз:

*(...) китте икән соң ул? (...) җиргә төшмәде? (...) бүтәннәр кебек, канатларын җыеп, түбәнгә атылмады? (...) сайрый-сайрый кояш артыннан китте(...)? Кояш артыннан... Әнкәсе артыннан...* (И. Гази).

1) *әллә*

2) *ник*

3) *кая*

4) -*ме*

8. Аерып бирелгән төзелмәнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез:

*Салкынга* ***түзәр әмәле калмагач****, карчык, төн уртасында торып, мичкә ут тергезде дә мич авызына аркасын куеп утырды* (Л. Зөлкарнәй).

1) хәбәр

2) вакыт хәле

3) сәбәп хәле

4) рәвеш хәле

9. Аерып бирелгән төзелмәнең төрен билгеләгез:

***И Язмыш!***

*Зинһар, соңгы тапкыр*

*Олы сөюеңә үсендер!* (Г. Гыйльманов).

1) исем җөмлә

2) эндәш сүз

3) күзаллаулы баш килеш

4) өстәлмә

10. Аерып бирелгән төзелмәнең төрен билгеләгез:

*Их, егетләр, күптән шулай рәхәтләнеп елаганым юк иде минем!..* ***Чын күңелдән, шатлыктан!..*** (Г. Гыйльманов).

1) 1 составлы исем җөмлә

2) 1 составлы хәбәр җөмлә

3) 2 составлы ким җөмлә

4) өстәлмә

11. Аерып бирелгән төзелмәнең төрен билгеләгез:

***Галия Идрисовна...*** *Ул безгә дүрт ел буе рус телен укыткан иде* (Г. Шәрәфи).

1) исем җөмлә

2) эндәш сүз

3) күзаллаулы баш килеш

4) өстәлмә

12. Аерып бирелгән төзелмәнең төрен билгеләгез:

**Ә кайчандыр...**

*Кайчандыр очып менгәндәй менә иде бит ул бу баскычтан!* (Г. Минский)

1) 2 составлы ким җөмлә

2) 1 составлы ким җөмлә

3) күзаллаулы әйләнмә

4) өстәлмә

13. Тәңгәллекне күрсәтегез:

1) *Бәхетнең кардәше – **өмет*** (Г. Гыйльманов). А) кушма исем хәбәр

2) *Мин сезгә ул турыда **сүз бирәм*** (Д. Аппакова). Б) гади исем хәбәр

3) *Моң ул, мәгълүм булганча, яраланган*

***кош кебек*** (Г. Гыйльманов). В) тезмә фигыль хәбәр

4) *Кеше җанын диңгез бик еш*

*Кылга **менгереп куя**!* (Г. Гыйльманов). Г) кушма фигыль хәбәр

14. Сызык ни өчен куелган?

*Керфекләрем бәстән әрни,*

*Күңелем – кара моңнан* (Г. Гыйльманов).

1) баш кисәкләре исем белән белдерелгән

2) баш кисәкләре кискен каршы куела

3) җөмлә кисәге төшеп калган

4) тезмә кушма җөмлә компонентлары кискен каршы куела

15. Тыныш билгеләренең дөрес куелган вариантын билгеләгез:

*Хатын-кыз бала-чага сугышка алынган ирләр барысы да авыл башына Өянке янына җыелдылар* (М. Галиев).

1) *Хатын-кыз, бала-чага, сугышка алынган ирләр, барысы да авыл башына, Өянке янына җыелдылар.*

2) *Хатын-кыз, бала-чага, сугышка алынган ирләр – барысы да авыл башына – Өянке янына – җыелдылар.*

3) *Хатын-кыз, бала-чага, сугышка алынган ирләр – барысы да авыл башына – Өянке янына җыелдылар.*

4) *Хатын-кыз, бала-чага, сугышка алынган ирләр – барысы да авыл башына, Өянке янына җыелдылар.*

16. Текстка нигезләнеп, биремнәрне үтәгез.

(1) *Урман буш.* (2) *Ни гөмбә, ни җиләк, ни чәчәк юк.* (3) *Буп-буш.* (4) *Барысы да кышның аргы ягында калган.* (5) *Агачлар шәрә.* (6) *Алар шулкадәр миһербансыз кыштан соң күтәрелеп килүләренә, яфрак җибәрүләренә ышана алмый торалардыр кебек.* (7) *Кочакка алып җылытасы, иркәлисе иде аларны.*

(8) *– Әминә...*

(9) *Уйларымны аңа җиткерәсем килеп эндәшсәм, Әминә юк.* (10) *Әле генә менә шушында борын төртеп килә торган яшел кыякка карап тора иде бит.* (11) *Кая китте?!* (12) *Әллә саташаммы мин?* (13) *Әллә бу төш кенә идеме?* (14) *Бернинди Әминә дә, яшел кыяк та, шәрә агачлар да юк идеме?* (15) *Бар, барысы да бар!* (16) *Әминә генә юк.* (17) *Агачлар артында күз күреме җитмәслек булып җәелеп агучы кара, шомлы Идел ягына карыйм.* (18) *Юк, ул якта да күренми.* (19) *Күңелгә*

*шик йөгерә, моңа кадәр сихергә, тылсымга ышанмаган йөрәкне нидер тырный* (Р. Вәлиев).

1. Инкяр җөмләләрне билгеләгез:

1) 2, 6, 9, 12, 13

2) 2, 6, 9, 14, 16, 17, 18, 19

3) 2, 6, 9, 14, 16, 18

4) 2, 6, 9, 16

2. Сорау җөмләләрне билгеләгез:

1) 11, 12, 13, 14

2) 8, 11, 12, 13, 14

3) 11, 12, 13, 14, 16

4) 11, 12, 13, 14, 19

3. Тиңдәш кисәкләре булган җөмләләрне билгеләгез:

1) 2, 7, 14, 15, 19

2) 2, 6, 7, 14, 15, 17, 19

3) 2, 6, 7, 9, 14, 15, 17, 19

4) 2, 6, 7, 14, 15, 17, 18, 19

4. Инверсия күренеше чагылыш тапкан җөмләләрне билгеләгез:

1) 3, 6, 7, 12

2) 7, 9, 12

3) 7, 12, 18

4) 7, 12

5. Аерымланган хәлләре булган җөмләләрне билгеләгез:

1) 9, 18, 19

2) 9

3) 2, 6, 7, 9

4) андый җөмлә юк

6. *Әле генә менә шушында борын төртеп килә торган яшел кыякка карап тора иде бит.*

Җөмлә кисәкләре ягыннан дөрес анализланган вариантны табыгыз:

1) *Карап тора иде бит* – кушма фигыль хәбәр, *кыякка* – кыек тәмамлык, *яшел* – аергыч, *килә торган* – аергыч, *борын төртеп* – рәвеш хәле, *шушында* – урын хәле, *әле генә* – вакыт хәле

2) *Карап тора иде бит* – кушма фигыль хәбәр, *кыякка* – урын хәле, *яшел* – аергыч, *килә торган* – аергыч, *төртеп* – рәвеш хәле, *борын* – туры тәмамлык, *шушында* – урын хәле, *әле генә* – вакыт хәле

3) *Карап тора иде бит* – кушма фигыль хәбәр, *кыякка* – кыек тәмамлык, *яшел* – аергыч, *борын төртеп килә торган* – аергыч, *шушында* – урын хәле, *әле генә* – вакыт хәле

4) *Тора иде бит* – кушма фигыль хәбәр, карап – рәвеш хәле, *кыякка* – кыек тәмамлык, *яшел* – аергыч, *килә торган* – аергыч, *төртеп* – рәвеш хәле, *борын* – туры тәмамлык, *шушында* – урын хәле, *әле генә* – вакыт хәле

**2 вариант**

1. Аерып бирелгән төзелмәнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез:

*Иң башта, **су керергә дип**, күл буена алып киттем мин боларны* (М. Вәлиев).

1) хәбәр

2) максат хәле

3) сәбәп хәле

4) кыек тәмамлык

2. Аерып бирелгән төзелмәнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез:

*Аны* ***кызганудан*** *мин куырылып төштем* (Н. Гыйматдинова).

1) хәбәр

2) кыек тәмамлык

3) туры тәмамлык

4) сәбәп хәле

3. Аерып бирелгән төзелмәләрнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез:

*Ә учакта... бөтен* ***пирожныйларыңнан****,* ***морожныйларыңнан*** *да тәмлерәк булып* ***бәрәңге*** *пешә* (Л. Ихсанова).

1) кыек тәмамлык, кыек тәмамлык, ия

2) кыек тәмамлык, кыек тәмамлык, туры тәмамлык

3) туры тәмамлык, туры тәмамлык, туры тәмамлык

4) туры тәмамлык, туры тәмамлык, ия

4. Аерып бирелгән төзелмәнең төрен билгеләгез:

***И Гомер!***

*Барыбер мине*

*Давылдан аралама!* (Г. Гыйльманов).

1) эндәш сүз

2) өстәлмә

3) исем җөмлә

4) күзаллаулы баш килеш

5. Әлеге өзектә ничә җыйнак җөмлә бар?

*Бала тоя.*

*Бәбкә тоя.*

*Әби toймый.*

*Быел никтер чирәмнең дә*

*Хуш исе юк диеп уйлый...*

*Яшел чирәм...*

*Кояш көлә.*

*Язлар килә.*

*Бала көлә.*

*Әби елый... әллә нигә...* (Ш. Җиһангирова).

1) 4

2) 6

3) 7

4) 8

6. *Зариф, артык түзеп тормаска булып, күңелендәгесен ачты да салды* (Г. Минский). Бу җөмлә:

1) раслау

2) тулы инкяр

3) өлешчә инкяр

7. *Туу һәм үлем арасында тирбәлгән бу тормыш гаярьләнеп йөргән күпме ирләрне шулай хатын-кыз алдына кайтарып тезләндерми...* (М. Галиев). Бу җөмлә:

1) раслау

2) тулы инкяр

3) өлешчә инкяр

8. Өзектә бирелгән бер составлы фигыль җөмләнең төрен билгеләгез:

*Күбрәк "бишле" эләксә, әнисе сөенер иде. Әнисе сөенсә, ул үзе дә сөенер иде, бәхетлерәк булыр иде...* ***Их, дуслашырга иде шул Язмыш белән!*** (Г. Гыйльманов).

1) билгесез үтәүчеле

2) билгеле үтәүчеле

3) гомум үтәүчеле

4) үтәүчесез

9. Төшеп калган сорау күрсәткечләрен дөрес итеп урнаштырыгыз:

*Син елыйсың... (...) елыйсың син?*

*(...) кайгы эзен калдырды?*

*(...) китте яшьлек чаялыгың?*

*Тормышыңнан (...) арыдың(...)?* (Р. Вәлиев).

1) *-мы*

2) *кая*

3) *нигә*

4) *нинди*

5) *әллә*

10. Аерып бирелгән төзелмәнең төрен билгеләгез:

***Нигез...*** *Бу сүз теленә килгән саен, кәефе кырыла куя Зөфәрнең* (Җ. Дәрзаман).

1) эндәш сүз

2) өстәлмә

3) исем җөмлә

4) күзаллаулы баш килеш

11. Аерып бирелгән төзелмәнең төрен билгеләгез:

*Беләм, сизәм, кайдадыр бу минутта Булат та рәхәтләнеп елыйдыр.* ***Аулакта гына, сөйгән кошы белән икәүләп...*** (Г. Гыйльманов).

1) 2 составлы ким җөмлә

2) 1 составлы исем җөмлә

3) өстәлмә

4) 1 составлы хәбәр җөмлә

12. Бу өзектә аерып бирелгән төзелмәнең төрен билгеләгез:

*Алар озак утырып, сөйләшә-сөйләшә чәй эчтеләр.* ***Киңәштеләр, аңлаштылар, килештеләр, табыштылар да кебек...*** (Г. Минский).

1) 1 сотавлы ким җөмлә

2) 2 составлы ким җөмлә

3) 1 составлы тулы җөмлә

4) өстәлмә

13. Тәңгәллекне күрсәтегез:

1) *Күзгә* ***йокы керми*** (С. Сабиров). А) кушма фигыль хәбәр

2) *Көтүлек янында гына бер әкәмәт*

*елга* ***бар*** (Г. Нәбиуллин). Б) гади исем хәбәр

3) *Тышта йомшак кына кар* ***ява*** (Н. Дәүли). В) тезмә фигыль хәбәр

4) *Үкенечтән* **сыкрап куяр** *җаннар* (Зөлфәт). Г) гади фигыль хәбәр

14. Сызык ни өчен куелган?

*Күңелемә шатлык җыям,*

*Йөрәккә – якты хисләр* (Г. Гыйльманов).

1) баш кисәкләре исем белән белдерелгән

2) баш кисәкләре кискен каршы куела

3) җөмлә кисәге төшеп калган

4) тезмә кушма җөмлә компонентлары кискен каршы куела

15. Тыныш билгеләренең дөрес куелган вариантын билгеләгез:

*Читтә тапкан бәхет бер атналык тәхет кенә ул бүген бар иртәгә юк* (Р. Вәлиев).

1) *Читтә тапкан бәхет – бер атналык тәхет кенә ул: бүген бар, иртәгә юк.*

2) *Читтә тапкан бәхет бер атналык тәхет кенә ул, бүген бар, иртәгә юк.*

3) *Читтә тапкан бәхет бер атналык тәхет кенә ул, бүген бар – иртәгә юк.*

4) *Читтә тапкан бәхет – бер атналык тәхет кенә ул, бүген бар, иртәгә юк.*

16. Текстка нигезләнеп, биремнәрне үтәгез.

(1) – *Ә-ә-ми-и-нә-ә-ә-әү-ү!*

(2) *Буш урман минем тавыш белән тула.* (3) *Бер секундтан ул тавыш җилдә тирбәлә-тирбәлә кире кайта.* (4) *Кайтаваздан куркам мин, балачактан ук куркам.* (5) *Кайтаваз миңа моңа кадәр үлгән кешеләрнең җир куеныннан биргән тавышы, тарих тавышы кебек тоела.* (6) *Кеше күп җирдә – урамда, базарда, кибеттә кайтаваз булмый бит.* (7) *Ә инде урманда, таулар арасында аз гына кычкырыбрак сөйләшсәң дә, таулар шомлы тавыш белән сиңа җавап кайтаралар.* (8) *"Курыкма, без синең белән", – дип кисәтеп торалар кебек алар.*

(9) *Карт имән артыннан, урманны яңгыратып көлә-көлә, Әминә килеп чыга.* (10) *Мин, үземне дә белештермичә йөгереп килеп, аны күкрәгемә кысам: "Синме бу, югалмадыңмы?" – дип, битләренә, күзләренә йотылып карыйм, ул уңайсызлана, читкә тартыла, каушый, бәләкәйләнеп, йомарланып кала, ә мин сөенәм, сөенәм!* (Р. Вәлиев).

1. Эндәш сүз кулланылган җөмләне табыгыз:

1) 1

2) 1, 8

3) 1, 8, 10

4) эндәш сүз кулланылмаган

2. Инверсия күренеше чагылыш тапкан җөмләләрне билгеләгез:

1) 3, 4, 8

2) 4, 8

3) 4, 8, 10

4) 3, 4, 8, 10

3. Аерымланган хәле булган җөмләләрне билгеләгез:

1) 4, 5, 7, 9, 10

2) 4, 5, 9, 10

3) 9, 10

4) 4, 7

4. Аныклагыч кулланылган җөмләне табыгыз:

1) 6

2) 4, 6

3) 6, 7

4) аныклагыч кулланылмаган

5. Тиңдәш кисәкләре булган җөмләләрне билгеләгез:

1) 4, 5, 6, 7, 10

2) 7, 10

3) 6, 7, 10

4) 4, 5, 7, 10

6. *Карт имән артыннан, урманны яңгыратып көлә-көлә, Әминә килеп чыга.*

Җөмлә кисәкләре ягыннан дөрес анализланган вариантны табыгыз:

1) *Әминә* – гади ия, *килеп чыга* – кушма фигыль хәбәр, *көлә-көлә* – рәвеш хәле, *яңгыратып* – рәвеш хәле, *урманны* – туры тәмамлык, *имән артыннан* – урын хәле, *карт* – аергыч

2) *Әминә* – гади ия, *чыга* – гади фигыль хәбәр, *килеп* – рәвеш хәле, *көлә-көлә* – рәвеш хәле, *яңгыратып* – рәвеш хәле, *урманны* – туры тәмамлык, *имән артыннан* – урын хәле, *карт* – аергыч

3) *Әминә* – гади ия, *килеп чыга* – кушма фигыль хәбәр, *көлә-көлә* – рәвеш хәле, *яңгыратып* – рәвеш хәле, *урманны* – туры тәмамлык, *артыннан* – урын хәле, *имән* – аергыч, *карт* – аергыч

4) *Әминә* – гади ия, *килеп чыга* – кушма фигыль хәбәр, *көлә-көлә* – рәвеш хәле, *яңгыратып* – рәвеш хәле, *урманны* – кыек тәмамлык, *имән артыннан* – урын хәле, *карт* – аергыч

### 9.6. Презентация.

## 10.
## Лекция № 8

- **Кушма җөмлә. Тезмә кушма җөмлә, аның төрләре. Иярченле кушма җөмлә, аның төрләре. Иярченле кушма җөмлә үзенчәлекләре.**

**Аңлатма.** Әлеге тема тезмә һәм иярченле кушма җөмлә төрләре турында аңлатма бирә.

**Иң мөһим төшенчәләр.** Кушма җөмлә, теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә, иярченле кушма җөмлә һәм аның төрләре.

**Методик киңәшләр.**

•Тема теоретик мәгълүматны үз эченә алган лекциядән гыйбарәт;

•Мөстәкыйль эш өчен гамәли биремнәр тәкъдим ителә;

•Теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү максатыннан, теоретик сораулар бирелә.

•Лекция презентацияләр белән үрелеп бара.

## 10.1. Кушма җөмлә. Тезмә кушма җөмлә, аның төрләре. Иярченле кушма җөмлә, аның төрләре. Иярченле кушма җөмлә үзенчәлекләре.

Татар грамматикалары тарихында кушма җөмлә буенча теоретик яктан тикшеренүләрне беренче К. Насыйрида күрергә була. “Әнмүзәҗ”тә кушма җөмлә турында бүлек бирелә. Ул болай яза: “Күп сүзләрдән җөмлә тәркип кылынган шикелле, күп җөмләләрдән дәхи җөмлә тәркип кылынадыр”. Мисаллар китерә: *Син килер дип, мин чыкмый тордым. Без кайтканда, ягъмур яуды* һ.б. Ул шарт, кире, сыйфат (аергыч) җөмләләрне күрсәтә. *Син яза торган каләм яхшырак. Син боерсаң, мин эшләрмен.*

Тезмә кушма җөмләләр турында К. Насыйри бер сүз дә язмаган.

К. Насыйридан соң кушма җөмлә турында мәгълүмат Г. Ибраһимовның “Татар нәхүе”, Г. Сәгъдинең “Үз телемезчә мәкәммәл сарыф-нәхү” исемле мәктәп дәреслекләрендә күренә.

1919 нчы елда басылган М. Корбангалиев һәм Х. Бәдиговның “Ана теле нәхүе” исемле хезмәттә кушма җөмлә төзелешенә шактый күп урын бирелә. Кушма җөмләнең ике тибы – иярченле һәм тезмә төрләре күрсәтелгән. Билгеләмә бирелгән: “Нәхү кануны ягыннан яки мәгънә вә мантыйк ягыннан бер-берсенә мөнәсәбәте булып берничә садә җөмләдән кушылып төзелгән җөмлә кушма җөмлә дип атала”.

1919 нчы елда Җ. Вәлиди “Татар теле грамматикасы” хезмәтендә иярчен җөмләләрнең 16 төрен бирә.

Г. Алпаров “Шәкли нигездә татар грамматикасы” фәнни хезмәтендә кушма җөмләләрне тикшерә (1927). “Кушма җөмлә дип нинди дә булса тышкы бер күренеш белән бер-берсенә бәйләнгән, бергә кушыбрак

әйтелгән, аерым ияле, аерым хәбәрле берничә җөмләдән төзелгән сүз тезмәләренә әйтәләр,” – ди ул.

1945 нче елда басылган “Татар телендә иярчен җөмлә бармы?” дигән мәкаләсендә Г. Алпаров җәенке иярчен кисәкләрне дә иярчен җөмләләргә кертә.

Элегрәк язылган рус грамматикаларында В. Богородицкий иярчен җөмләнең үзенә хас иясе, хәбәре булырга да, булмаска да мөмкин дигән карашын уздырган. Шуннан чыгып, иярчен җөмләләрне тулы иярчен (иясе, хәбәре бар) һәм ким иярчен җөмләләргә аера.

В. Хангилдин “Татар теле грамматикасы” (1959) хезмәтендә кушма җөмләләрне 2 зур типка – бәйләгечле кушма җөмләләр һәм бәйләгечсез кушма җөмләләргә бүлә. Бәйләгечле кушма җөмләләргә гади җөмләләре үзара бәйлек, теркәгеч, кушымча кебек бәйләүче чаралар белән төзелгән кушма җөмләләрне кертә. Бәйләгечсезләргә интонация белән бәйләнгән кушма җөмләләр керә. Алар икесе дә, үз чиратында, тезмә һәм иярченле кушма җөмләләргә бүленәләр => бәйләгечле тезмә кушма җөмлә; бәйләгечсез тезмә кушма җөмлә һ.б. барлыкка килә.

Бер үк кушма җөмләдә гади җөмләләр бәйләгеч белән дә, интонация белән дә бәйләнсәләр катнаш кушма җөмләләр барлыкка китерәләр.

Г. Алпаров кушма җөмләләрне түбәндәгечә бүлә:

- иярт үле кушма җөмлә;
- бәйләнүле кушма җөмлә;
- тезмәле кушма җөмлә.

М.З. Зәкиевнең “Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис” (1958) хезмәтендә, нигездә, кушма җөмләләрнең бүгенге бүленеше бирелгән.

Сөйләм төзелешен тулысынча тикшерү өчен, сүзләр бәйләнешен, җөмлә кисәкләрен, җөмләләрнең төрләрен белү генә җитми, бәлки, җөмләләрнең бәйләнешкә кереп, тулы бер сөйләм (текст) оештыруларын өйрәнергә кирәк. Сөйләм барышында, логик эзлеклелек өчен, мөстәкыйль җөмләләр дә, мөстәкыйль булмаган җөмләләр дә үзара бәйләнгән булырга

тиеш. Текстта мөстәкыйль булмаган җөмләләр, үзара оешып, бер синтаксик бөтен – кушма җөмлә хасил итәләр.

Кушма җөмлә, гади җөмлә кебек үк, бер бөтен тәшкил итәргә тиеш. Бу бөтенлек анда мәгънә буенча бөтенлектән, аерым өлешләрнең структур яктан оешканлыгыннан һәм бер-берсенә грамматик яктан бәйләнгән булуыннан барлыкка килә.

Теләсә нинди җөмләләрнең янәшә килүе генә кушма җөмлә барлыкка китерә алмый. Кушма җөмлә төзүче җөмләләр, барыннан да элек, эчтәлекләре белән үзара бәйләнештә булырга: я берсе икенчесен мәгънә ягыннан ачыклап килергә, яки алар бер үк вакытта, бер үк урында булган күренешләрне белдерергә тиешләр.

Кушма җөмлә составындагы гади җөмләләр яки тулысынча мөстәкыйльлекләрен югалталар, яки өлешчә генә мөстәкыйль була алалар. Мөстәкыйльлекләре төрле җөмләләрдә төрлечәрәк була: Мәсәлән: *Матур яз килде, табигать төрле яшеллекләр белән капланды*. җөмләсендә ике җөмлә дә гади җөмләләргә якын торалар. Мөстәкыйльлекләре чагыштырмача зур. *Матур яз килгәч, табигать яшеллекләр белән белән капланды* булса => беренче җөмләнең мөстәкыйльлеге шактый кими.

*Төне буе зәңгәр йолдыз янды*

*Син утырган тәрәз каршында* дигән мисалдан *Син утырган* дигән җөмләнең мөстәкыйльлеге бөтенләй сизелми. Ләкин ия-хәбәр ситуациясе бар, димәк бу җөмлә.

Димәк, кушма җөмлә составындагы гади җөмләләр тулы мөстәкыйль булмыйлар (алай булганда, алар аерым җөмлә төзерләр иде); мөстәкыйль түгеллекләре төрле дәрәҗәдә була (янәшәлек юлы белән бәйләнгәннәрнең мөстәкыйльлеге бик аз) һәм грамматик яктан җөмләнең кушмалыгын билгеләгәндә, мөстәкыйльлек роль уйнамый, ә хәбәрлекле үзәкнең ничә булуы роль уйный.

Күп очракта, кушма җөмләләрнең кушмалыгы ачык күренеп тора. Бигрәк тә тезмә кушма җөмләләрдә: Мәсәлән: *Атлар да чабышты, малайлар да йөгереште, яулыклар да алынды, сабан туе да бетте* (Г. Тукай).

Кайбер очракларда җөмләнең гадиме, кушмамы икәнлеген аеру авырлык тудыра. Шуңа күрә җөмләнең кушмалыгын күрсәтеп торган кайбер билгеләрне карап китик.

1. Кушма җөмлә төзи торган аерым җөмләләрнең үзләренә генә караган субъектлары (S) һәм предикатлары (P) булырга тиеш.

*Көн болытлады һәм яңгыр яварга керешә.*

*Кояш баегач, колхозчылар эштән туктадылар* дигән конструкцияләр ике җөмләдән торалар, чөнки һәрберсенең аерым субъект (*көн, яңгыр; кояш, колхозчылар*) һәм предикатлары бар (*болытлады, яварга керешә*).

2. Җөмләләрнең субъектлары аерым сүз белән бирелмичә, предикатлары гына бирелеп, субъектлары бер үк булмасалар, җөмлә кушма дип санала. Мәсәлән: *Берничә тапкыр <u>әйттем</u>, <u>тыңламады</u>.* (мин - ул)

3. Кайбер синтаксик төзелмәләрдә субъектлар бер үк сүз белән бирелгән булырга, ләкин һәр җөмләдә кабатланырга мөмкиннәр. Болар шулай ук кушма җөмлә дип карала.

Мәсәлән: *<u>Син</u> ярлы идең, ләкин <u>син</u> яхшы идең* (Һ.Такташ).

*Татар бәхете өчен, <u>мин</u> җан атармын, <u>мин</u> бит үзем дә чын татармын* (Г. Тукай).

4. Предикатлар бер үк булган, ләкин һәр җөмләдә кабатланган очракта да, кушма җөмләләр барлыкка килә.

Мәсәлән: *Әнисе <u>әйтте</u>, әбисе <u>әйтте</u>, әтисе <u>әйтте</u>...*

*Сәлим <u>йөгерә</u>, Әхмәт <u>йөгерә</u>, Фәрхинур <u>йөгерә</u> һ.б.*

Татар грамматикасының III томында мондый мисаллар да кушма җөмләдә карала диелгән:

*Мин кат-кат укыдым, чөнки аңламаган идем.* М.З. Зәкиев болай аңлата: *укыдым* һәм *аңламаган идем* сүзләре бер-берсенә иярү юлы белән бәйләнгәннәр => шуңа күрә тиңдәш булмыйлар.

Кимендә ике җөмләнең, үзара синтаксик бәйләнешкә кереп, структур, семантик һәм интонацион яктан бер бөтенне тәшкил итүе **кушма җөмлә** дип атала.

**Кушма җөмләләрнең төрләре**

Җөмлә составындагы хәбәрлекле үзәкнең саныннан чыгып, кушма җөмләләр икегә бүленә. Ике генә җөмләдән (2 ситуациядән, 2 генә хәбәрлекле үзктән) торган җөмләләрне II компонентлы кушма җөмлә диләр (Мәктәп дәреслекләрендә "кушма җөмлә" дип атала, III томда – "Гади кушма җөмлә" диелгән). Кимендә өч, яки аннан да артыграк җөмләләрдән торган кушма җөмлә - "катлаулы кушма җөмлә" дип атала.

**Тезмә кушма җөмлә**

Аерым җөмләләре үзара тезү юлы белән бәйләнгән кушма җөмлә **тезмә кушма җөмлә** дип атала. Тезмә кушма җөмлә составындагы җөмләләр бер-берсенә буйсынмыйлар, ягъни үзара тигез хокуклы булалар. Берсеннән берсенә сорау куеп булмый. Янәшә торган теләсә нинди ике җөмлә тезмә кушма җөмлә барлыкка китерми. Ике җөмлә үзара билгеле бер мәгънә мөнәсәбәтендә торырга һәм билгеле бер грамматик чара белән бәйләнгән булырга тиешләр. Тезмә кушма җөмләләр, гадәттә, билгеле бер вакытны, урынны, нинди дә булса бер уртак объектны тасвирлаганда; күренешләрне үзара каршы куйганда; нәрсәнең дә булса шартын, сәбәбен һ.б. санаганда ясалалар.

Бер-берсе белән бәйләнеш төренә карап, 2 гә бүленәләр:

- **теркәгечле тезмә кушма җөмлә;**
- **теркәгечсез тезмә кушма җөмлә.**

**Теркәгечле тезмә кушма җөмләгә** мисаллар:

1) Җыючы теркәгечләр белән бәйләнгән тезмә кушма җөмлә:

*Тышта ябалак-ябалак кар ява һәм буран котыра иде* (Р.С.).

[ ], [ ]  □-□

2) Каршы куючы теркәгеч белән бәйләнгән тезмә кушма җөмлә:

*Бар да бар,* ***тик*** *юк туганнар* (Г.Тукай).

*Син адаштың,* ***ләкин*** *син яхшы идең* (Һ.Такташ).

*Җил басылды тышта,* ***ә*** *йөрәктә утлы-җилле буран кузгалды* (М.Җәлил).

3) Бүлүче теркәгеч белән бәйләнгән тезмә кушма җөмлә:

*Әле яңгыр сибәли, әле кар төшкәли.*

*Әллә чия синең иренең төсле,*

*Әллә иренең синең чия төсле* (Ә. Фәйзи).

**Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр:**

1) Санау интонациясе ярдәмендә бәйләнгән кушма җөмлә:

*Чәчәкләр бии болында,*

*Җил курай уйнап тора* (Ф. Яруллин).

2) Каршылык интонациясе белән бәйләнгән тезмә кушма җөмлә:

*Синең өчен мин көзләргә кердем,* -

*Син белмәдең минем кадерне* (И.И.).

**Мәгънә ягыннан төрләре**

Мәгънә ягыннан тезмә кушма җөмләләрнең шулай ук берничә төрен билгелиләр.

Мәктәп дәреслекләрендә бу мәсьәлә бөтенләй каралмый диярлек. Югары уку йортлары өчен чыгарылган дәреслекләрдә, грамматикаларда, башка фәнни хезмәтләрдә тезмә кушма җөмләнең семантикасы теркәгечләр белән үрелеп бара. Мәсәлән, “Татар грамматикасы”нда М.З. Зәкиев, теркәгечләрне анализлау аша, бу төр җөмләләрнең семантикасын билгеләгән. Г.Ә. Нәбиуллина, мәкальләрне өйрәнеп, түбәндәге җиде мәгънәви-структур төрне күрсәтә: *каршы кую, вакыт, шарт-нәтиҗә, сәбәп-нәтиҗә, аныклау, номинатив, сорау*.

### 1. Вакыт мөнәсәбәтендәге тезмә кушма җөмләләр.

Аларның үз эчендә тагы берничә мәгънәви төсмерен билгеләп була.

1) Бер үк вакытта булган, параллель күренешләрне яки эш-хәрәкәтне чагылдыра торган җөмләләр.

Мондый җөмләләрдә, кагыйдә буларак, хәбәрләрнең формалары тулы килеш ярашалар яисә бер үк заманга карыйлар.

*(1) Ир-атлар, киерелеп, чалгы белән печән чабалар, (2) хатын-кызлар хуш исле печәнне әйләндерә-әйләндерә киптерә, гүбәләргә җыя, чүмәләләргә сала* (М. Рәфыйков).

2) Төрле вакытта булган, бер-бер артлы барган күренешләрне яки эш-хәрәкәтне чагылдыра торган җөмләләр.

Бу төр җөмләләрдә *һәм, да-дә...* теркәгечләре кулланыла, ләкин *һәм* теркәгече сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтендәге җөмләләрдә дә урын алырга мөмкин.

*(1) Болытлар таралдылар да, (2) ялтырап кояш чыкты.*

*(1) Рәйсәнең күзләре зур булып ачылдылар, (2) кулындагы сирень яфраклары җиргә төште* (Г. Әпсәләмов).

3) Эш-хәрәкәтнең кинәт алмашынуын чагылдыра торган вакыт җөмләләр.

*(1) Кабинетыма кереп чишенергә дә өлгермәдем – (2) яңадан ишек шыгырдады* (М. Насыйбуллин).

4) Бүлгәләүне чагылдыра торган вакыт җөмләләр.

*(1) Я без, уртак фикердә булып, бергә эшлибез, (2) яисә юлларыбыз аерыла* (М. Маликова).

**2. Каршы кую мөнәсәбәтендәге тезмә кушма җөмләләр.**

Бер ситуация икенчесенә каршы куела. Каршы кую мөнәсәбәтен каршы куючы теркәгечләр, антонимнар, интонация белдерә. Бу мөнәсәбәт үз эчендә берничә төсмерле була ала.

1) Каршы куюны гына белдерә торган җөмләләр.

*(1) Анда сугылды, монда сугылды – (2) файдасы булмады* (Г. Ибраһимов).

2) Чагыштыру төсмере белән каршы куюны белдерә торган җөмләләр.

*(1) Чыршыларның яшеллеге җәй көне беленми, (2) ә менә сентябрь аенда аларның буявы тагын да яктырып китә* (М. Мәһдиев).

3) Чикләү төсмере белән каршы куюны белдерүче җөмләләр.

*(1) Хатын-кызлар авылларына таралдылар, (2) бары чүлмәкләрдәге сөтне кая куярга белмәгән шадра хатын гына нәрсәдер көтә* (К. Нәҗми).

*(1) Харис моңа каршы бер сүз дә әйтмәде, (2) тик аның уйчан ак чыраенда ниндидер сызлану аша боек көлемсерәү чагылып киткәндәй булды* (Ә. Еники).

**3. Сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтендәге тезмә кушма җөмләләр.**

Мондый төзелмәләрдә бер компонент нәрсәнеңдер сәбәбен белдерә, икенчесе шуннан килеп чыккан нәтиҗәне чагылдыра.

*(1) Тик Хәлим генә аның ни әйткәнен ишетмәде, (2) колаклары түзә алмаслык гөҗли иде* (Р. Зәйдулла).

Тезмә кушма җөмләләрдә компонентлар арасындагы мәгънә мөнәсәбәтен билгеләү шактый авыр була. Кайбер очракларда бу мәгънәләр берләшеп китә, шуңа күрә берничә мәгънә мөнәсәбәте табылган, чагылган очракта, аларның һәрберсен күрсәтү дөресрәк булыр. Мәсәлән, түбәндәге мисалда компонентлар арасындагы төп мәгънә мөнәсәбәте – бер-бер артлы барган күренешләрне чагылдырган вакыт мәгънәсе, шуның белән бергә сәбәп-нәтиҗә дә сиземләнә.

*(1) Болытлар таралдылар (2) да, ялтырап, кояш чыкты* (Г. Ибраһимов).

**Тезмә кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре**

Тезмә кушма җөмләләрнең компонентлары арасында тыныш билгеләрен куюның түбәндәге кагыйдәләре бар.

1. Тезү интонациясе (санау һәм каршы кую) һәм тезүче теркәгечләр аша бәйләнешкә кергән компонентлар арасына өтер куела.

*Кичә алар эшләмәделәр, кичә көне буе яңгыр яуды* (Р. Низами). *Бер көймәгә кызлар төялгән, икенче көймәдә егетләр* (Ә. Фәйзи). *Барысы да курка кала, **тик** аю гына курыкмый* (А. Алиш). *Каты җил исә, **һәм** яңгыр үзенең тамчыларын ачу белән тәрәзәгә китереп бәрә* (Ф. Әмирхан).

2. Компонентлар арасында кискен каршылык яки вакыйгаларның кинәт алмашынуы булса, сызык куела.

Сызык билгесе теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрдә генә генә урын алырга мөмкин. Компонентлар арасында кискен каршы кую яки вакыйгаларның кинәт алмашынуы теркәгечле тезмә кушма җөмләләрдә

булса, сызык урынына өтер куелырга тиеш, чөнки теркәгеч – үз алдында өтерне таләп итә торган берәмлек.

*Батыр бер үлә - куркак мең үлә* (Мәкаль). *Көз әле алтынсу биләүдә - Мин инде җәйләрне сагынам* (Р. Вәлиев).

3. Теркәгечсез тезмә кушма җөмлә компонентларның үз эчләрендә өтерләр булса, андый җөмләләр, кагыйдә буларак, үзара нокталы өтер белән аерылалар.

*Инеш буендагы вак таллар, күпер төбендәге кар өемнәре аста кала; җиң очларыңнан, изүләреңнән, бишмәт итәгеңнән җил бәреп керә* (Г. Бәширов).

4. *Да/дә, та/тә* теркәгечле тезмә кушма җөмләләрдә өтер шул бәйләүче чарадан соң куела.

*Болытлар таралдылар **да**, ялтырап, кояш чыкты* (Г. Ибраһимов).

**Бер ярым хәбәрлекле җөмләләр**

(Искә төшерергә: җөмләнең төп үзенчәлеге – хәбәрлек һәм модальлек. Хәбәрлек – сөйләмнең яңалык хәбәр итәргә сәләтле булуы – предикативность, модальлек - сөйләмнең чынбарлыкка сөйләүче мөнәсәбәтен белдерергә сәләтле булуы).

Һәрбер мөстәкыйль җөмлә хәбәрлекнең (предикативностьның) тулы булуы белән характерлана.

Хәбәрлекнең эчтәлеге һәм фомасы бар. Аның эчтәлеге – берәр хәл, эш турында хәбәр итү (гомуми лингвистикада моны **пропозиция** сүзе белән атыйлар), формасы – шул хәбәр итүне җөмләнең бер калыбына салып тиешле интонация белән әйтү. Мондый хәбәрлек **тулы хәбәрлек** дип йөртелә, һәм ул мөстәкыйль гади җөмләләрдә була.

Тезмә кушма җөмләдә ике яки икедән артык тулы хәбәрлек була, ләкин аның бөтен яктан да тулысы соңгы җөмләдә күзәтелә. Мәсәлән:

*1) Кипкән печән исенә алма исе килеп кушыла да, 2) баш әйләнеп китә.*




Беренче җөмләдә интонацион тулылык җитеп бетми, шулай да ике җөмләдә дә тулы хәбәрлек бар дип санала.

Тулы хәбәрлектән тыш тагын **иярчен хәбәрлек** тә күзәтелә, ул иярчен җөмләләрдә була. Аналитик иярчен җөмләләрдә иярчен хәбәрлек тулы хәбәрлеккә якын тора, синтетик иярчен җөмләләрдә ул ярым хәбәрлеккә якын тора.

**Ярым хәбәрлек** иярчен җөмлә төзи алмый, ул билгеле бер хәлне хәбәр итми, аны атау белән чикләнә һәм бу хәлне атап күрсәтү җөмлә калыбына төренми, я җөмлә кисәге белән, я морфологик-синтаксик чара белән, я конситуация белән (ягъни имплицит юл белән уйланылган, подразумеваемый, невыраженный) бирелә. Ярым хәбәрлек тулы хәбәрлеге булган җөмләдә генә килә ала. Шуңа күрә ярым хәбәрлеге булган җөмләне бер ярым хәбәрлекле җөмлә дип атыйлар.

Мәсәлән: *Кар ява* – бер хәбәрлекле үзәк, карның явуы хәбәр ителә, башка мәгънәләре юк.

*Марат Наилгә утын ташышты* җөмләсендә *Марат ташый* - хәбәрлекле үзәк, ләкин бу җөмләдә, мәгънәсенә карасак, тагын бер эш хәл турында сүз бара => *Наил ташый* – бу өстәмә хәбәрлек, ягъни ярым хәбәрлек була һәм бу җөмлә => *Марат Наилгә утын ташышты* – бер ярым хәбәрлекле җөмлә була.

Кайбер телче галимнәр (җөмләләрне семантик планда өйрәнүчеләр) төрле тел чаралары белән бирелмичә, уйлап чыгарылган хәбәрлекләрне генә кушып, ярым хәбәрлекле җөмләләргә мондыө җөмләләрне кертәләр.

Мәсәлән: *Мин энемә китап бирдем* җөмләсендә төп ситуация – *мин бирдем*. Бирелгә хәбәрлек, эчтәлеге буенча, яңалык хәбәр итә, формасы буенча, ул татар теленә хас җөмлә моделе белән бирелгән (тулы хәбәрлек).

*Мин энемә китап бирдем* дип әйткәч, без тагын ниндидер ситуацияләр булганын уйлый алабыз: *Китап миннән энемә күчте* һәм *Энем китап алды*.

Ләкин шунысы бар: *Мин энемә китап бирдем* җөмләсендә югарыда әйтелгән ике ситуация (*Энем китап алды* һәм *Китап миннән энемә күчте* ситуацияләре) бернинди тел чарасы белән дә бирелмәгән, алар уйлап чыгарылган гына. Шуңа күрә аларны төп хәбәрлек янында өстәмә яисә ярым хәбәрлек дип танып булмый, ул гадәти бер хәбәрлекле гади җөмлә рәтенә керә.

**Бер ярым хәбәрлекле җөмләләрнең бирелүе:**

**а) Тиңдәш кисәкләр ярдәмендә бирелә**. Ярым хәбәрлекнең тиңдәш кисәкләрдә бирелүенә безнең галимнәр XX йөз башында ук игътибар иткәннәр (Г. Ибраһимов, Г. Алпаров). Җөмләдә тиңдәш кисәкләр берничә җөмләнең бергә оешуы нәтиҗәсендә барлыкка киләләр дип уйлаганнар. Мәсәлән, *Илдус һәм Марат килде* җөмләсе *Илдус килде, Марат килде* дигән ике җөмләдән оешкан. Шуңа күрә тиңдәш кисәкле җөмләне Г. Ибраһимов **оешкан җөмлә** дип атый. *Марат укыды һәм язып куйды* җөмләсендә мәгънә ягыннан *Марат укыды* һәм *Марат язып куйды* дигән ике хәбәрлек бар, аларның икесендә дә хәбәр итү һәм модальлек бирелгән, ләкин бердән, анда икесенә бер генә субъект бар, икенчедән, анда бирелү формасы ягыннан җөмләнең бер генә моделе күзәтелә. Шуңа күрә ул бер ярым хәбәрлекле гади җөмлә эчендә карала.

**б) Исем фигыль һәм инфинитив белән бирелгән кисәкләр ярдәмендә белдерелә.** Бу төр җөмләләрдә исем фигыль һәм инфинитив төп җөмләнең хәбәре булып килми, иясе яисә кайсы да булса бер иярчен кисәк булып килә: *Синең килү миңа дәрт өстәде* җөмләсендә төп хәбәрлектән тыш тагын бер эш-хәл үтәлүе аңлашыла: *килү*. Бу кисәк эш-хәлне хәбәр итми, бары аны атый гына, һәм ул үз янындагы кисәк (*синең*) белән җөмлә моделе төземи, шуңа күрә ярым хәбәрлек белдерә торган кисәк булып кала.

Ярым хәбәрлекле кисәк инфинитив белән бирелгәндә дә шундый ук хәл күзәтелә: *Ул кайтырга уйлаган иде*. Бу гади җөмләдә төп хәбәрлек – *ул*

*уйлаган иде*, ярым хәбәрлек – *кайтырга*. Соңгысы җөмлә моделе төземәгән, шуңа күрә ярым хәбәрлек кенә белдерә дип санала.

Әгәр дә исем фигыль һәм инфинитив үз янындагы сүз белән җөмлә моделе төзесә, алар ярым хәбәрлек түгел, ә бөтен хәбәрлек, ягъни синтетик иярчен җөмлә төзүчеләр буларак өйрәнеләләр: *Син килү миңа дәрт өстәде. Әти кайтырга биш көн калды*.

**в) Ярым хәбәрлек сыйфат фигыльләр һәм хәл фигыльләр белән бирелгән кисәкләр ярдәмендә белдерелә**. Бу төр кисәкләр, үзләренә караган ияләре булса, җөмлә эчендә җөмлә моделе барлыкка китерәләр һәм синтетик иярчен җөмлә хәбәре дип танылалар, иярчен хәбәрлек дип санала. Мәсәлән, *Син терелгәнне түземсезлек белән көттек*. Җөмләне үзгәртсәк, *Синең терелгәнне* формасында бирелсә, *терелгәнне* кисәге иярчен хәбәрлек белдерми, бары ярым хәбәрлек белдерә торган кисәк булып таныла. *Син киләсе юлдан күзем алмыйм* җөмләсендә *киләсе* кисәге – иярчен җөмлә хәбәре – *Синең киләсеңне белмәдем* җөмләсендә *киләсеңне* кисәге бары ярым хәбәрлекне генә белдерә.

Хәл фигыльләр белән дә шул ук хәл. *Әти* *кайткач килермен* (*кайткач* – хәбәрлек). *Кайткач килермен* булса – *кайткач* – ярым хәбәрлек. (*Мин кайтам, мин киләм*).

**г) Аныклагычлар белән бирелә**. Аныклагычлар үзе ияргән сүздән соң киләләр, шул сүзне аныклыйлар, аның турында үтеп барышлый гына хәбәр иткән кебек тә булалар. Мәсәлән, *Умырзаялар – кар гөлләре күренде* дигән җөмләдә төп хәбәрлек – *умырзаялар күренде*, ләкин шул ук вакытта төп фикердән тыш *Умырзаялар – кар гөлләре* дигән ярдәмче хәбәрлек тә бар. Шуңа күрә бу җөмлә шулай ук ярым хәбәрлекле җөмлә дип карала.

**д) Төшем юнәлеше кушымчасы аша бирелә**. *Йорт студентлар тарафыннан төзелде*. Төп хәбәрлек – *йорт төзелде*. Төшем юнәлеше кушымчасы -*л* семантик яктан тагын бер хәбәрлекнең булуын белдерә (*Студентлар төзегән*).

*Соңгы җырым палач балтасына,*

*Башны тоткан килеш язылa* (М. Җәлил). Хәбәрлек – *җырым языла,* ярым хәбәрлек җөмләдә бирелми, ләкин аңлашыла, процесны үтәүче субъект үзе (*Мин язам*).

**е) Уртаклык юнәлеше кушымчасы аша бирелә**. Бу кушымча белән белдерелгән ярым хәбәрлектәге үтәүче гадәттә тәмамлык белән бирелә яисә үтәүчеләр тиңдәш ияләр белән биреләләр. *Марат Илдарга утын ташышты* җөмләсендә төп тулы хәбәрлек – *Марат ташышты*, ярым хәбәрлек – *Илдар ташыды.*

**ж) Йөкләтү юнәлеше кушымчасы аша бирелә.** *Әтисе улыннан яздырды.* Биредә *әтисе яздырды* – тулы хәбәрлек, ә *улы язды* – ярым хәбәрлек, чөнки ул җөмлә калыбы белән бирелмәгән, *улыннан яздырды* тезмәсе белән генә бирелгән.

Йөкләү башка бер зат аркылы башкарылганда, җөмләдә тулы хәбәрлек берәү, ә ярым хәбәрлек ике (хәтта өч) була: *Әтисе хатны әнисе аша улыннан яздыртты* җөмләсендә тулы хәбәрлек - *әтисе яздыртты,* ярым хәбәрлекләр: *әнисе яздырды, улы язды.*

**з) Чагыштыру кушымчасы яки бәйлекләре аша бирелә**. *Марат Рөстәмнән акыллырак* җөмләсендә тулы хәбәрлек – *Марат акыллырак,* ярым хәбәрлек - *Рөстәм дә акыллы.*

*Роман кебек күңелле син, юл*! (Х. Туфан) җөмләсендә тулы хәбәрлек – *син күңелле*, ярым хәбәрлек – *роман да күңелле.*

### Иярченле кушма җөмләләр

Компонентлары үзара ияртүле бәйләнештә торган җөмләне **иярченле кушма җөмлә** дип атыйлар. Иярченле кушма җөмләдә бер компонент икенчесенә буйсынып, ияреп килә. Ияреп килгән компонент иярчен җөмлә дип, ә үзенә ияртүче компонент баш җөмлә дип атала.

Иярченле кушма җөмләләрнең күп санлы төрләре бар.

1. Мәгънә ягыннан ягъни функциональ яктан төрләргә бүленәләр. Өйрәнелү тарихына караганда, төрле заманнарда җөмләләр төрлечә билгеләнгән. Кайбер телчеләребез хезмәтләрендә хәзер билгеләнми торган нәтиҗә (В. Хангилдин), чагыштыру (Г. Алпаров, В. Хангилдин), чит (Г. Алпаров) дигән төрләр очрый.

Җ. Вәлиди 39 төрен күрсәткән. 50-70 нче елларда тотрыклана = 12 төре бирелә башлый. 70 нче елларда М.З. Зәкиев, В. Хангилдин иярчен аныклагыч җөмләне, 80 нче елларда М.З. Зәкиев иярчен кереш җөмләне өсти. Академик грамматикада 14 төре бар. (Гади җөмләдә нинди кисәкләр булса, шуларга туры килгән иярчен җөмләләр күрсәтелгән. Эндәш сүзгә туры килгән җөмлә генә юк).

Димәк: иярчен ия, иярчен хәбәр, иярчен тәмамлык, иярчен аергыч, иярчен вакыт, иярчен урын, иярчен сәбәп, иярчен максат, иярчен шарт, иярчен кире, иярчен күләм, иярчен рәвеш, иярчен аныклагыч, иярчен кереш җөмләләр.

Соңгы елларда – 15е төрен табучы галимнәр бар – иярчен өстәлмә җөмлә.

2. Төзелешләре буенча 2 төркемгә бүленәләр:

- **синтетик** (сложносочиненные);

- **аналитик** (сложноподчиненные).

Мондый төзелмәләрнең бер-берсеннән нәрсәләр белән аерылуларын ачыклау өчен, аларны чагыштырып карага кирәк.

1. Һәр төзелешнең үзенә генә хас бәйләүче чаралары бар.

**Синтетик җөмләне баш җөмләгә ияртә торган чаралар:**

а) кушымчалар (килеш, тартым; сыйфат, хәл, шарт, боерык, инфинитив фигыль формалары; охшату-чагыштыру мәгънәсен бирә торган *-дай-дәй, -рак-рәк* һ.б.)

*Аның белән урамга чыксаң, борылып карамаган кеше калмый иде* (Ф.Яруллин).

*Атлар килеп җиткәч, халык көрәш мәйданына ашыкты* (Г.Гобәй).

б) бәйлек һәм бәйлек сүзләр:

*Бер-ике минут үтү белән, арадагы пәрдә югалды* (Г. Ибраһимов).

*Алмалар җыелып бетүгә карамастан, бакча әле матур* (И. Гази).

в) мәҗбүри янәшә тору һәм ияртүче сүздән пауза белән аерылмау:

*Акчасы бар кеше ни эшләргә белә.*

*Әтисе бай малайлар мондый эшкә бармыйлар.*

Бу чаралар ияртүче җөмләнең составында торып аның формасын тәшкил итүләре һәм тыгыз бәйләнеш булдырулары белән аерылып торалар.

**Аналитик җөмләне баш җөмләгә ияртә торган чаралар:**

а) ияртүче теркәгечләр:

*Урал буендагы булган хәлләрне хәзергә мин сиңа язмыйм, чөнки хат бик озакка китәчәк* (Ш. Камал).

*Күрше-күлән бер-берсенә кермәде, әйтерсең лә тереклек туктап калды* (М. Мәһдиев).

б) мөнәсәбәтле сүзләр:

*Агачы нинди, җимеше шундый.*

*Тагын шул да бар: Зыя бит – хәзер мөдәррис инде* (Г. Ибраһимов).

в) көттерү интонациясе:

*Гадәтем: ялгыз кешеләрне кытыклап үтерәм* (Г. Тукай).

*Кайчакта уйлыйм: яшь кенә гомереңдә син күпме моң-гамь күргәнсең* (Р. Гаташ).

Кереш интонациясе (иярчен кереш җөмләләрне бәйли):

*Аның миңа сузган кулына (йомшак һәм бик җылы иде ул кул) тотынып, аякка бастым* (Ф. Хөсни).

*Быелгы язлар, мин әйтәм, соңарак кала бугай.*

Аныклау интонациясе (аныклагыч җөмләләрдә):

*Сәгать уникеләрдә, кешеләр йоклап беткәч, ул тагын эшкә утырды.* (аңлатырга)

*Мөнирә бик озак, машина күздән югалганчы, ак кульяулыгын болгады* (Г. Әпсәләмов).

Өстәлмә интонация (өстәлмә иярчен җөмлә дип каралган очракта):

*Барысын да кичер, елап-көлеп.*

*Мин кичергән, гафу иткән кебек* (Зөлфәт).

*Балалар да әниләренең күзләренә генә карап үстеләр. Айсылу студентка булганчы* (Б. Камал).

Бу чаралар иярүче җөмлә составында тормыйлар. Шуңа күрә ике җөмлә арасында бәйләнеш тә тыгыз булмый.

Димәк, төп үзенчәлек – иярүче җөмләнең нинди форма алуында.

Синтетик чаралар белән бәйләнсә, иярчен җөмләнең хәбәре тәмамланган тулы формада булмый, ул ияртүче сүзгә буйсына, мөстәкыйльлеген югалта. Аерым гына алып караганда, ул төгәлләнми кала, үзеннән соң тулыландырыла торган җөмләнең һичшиксез килергә тиешлеген нык сиздереп тора.

*Болыннар кипкәч, кырга чыгарбыз* (Н. Дәүли).

Бу җөмләдә *Болыннар кипкәч* җөмләсенең хәбәре булып килгән хәл фигыль җөмләне тәмамламый, үзеннән соң нинди дә булса сүзнең килүен сорый; ягъни төгәлләнми кала.

Аналитик чаралар аша бәйләнешкә кергән сүзләрнең (җөмләләрнең) һәр икесе тулы, төгәлләнгән формада килә. Мондый бәйләнештәге җөмләләрнең хәбәрләре тулы формада була.

*Коеп-коеп яңгыр яварга тотынды, шуның белән ... йөзгә, күзгә яшәү өмете күтәрелде* (Г. Ибраһимов).

Иярчен җөмләнең хәбәре тулы, төгәлләнгән, ул җөмлә бернинди үзгәрешсез гади җөмлә булып китә ала => *Коеп-коеп яңгыр яварга тотынды*. Шушы ук җөмләләрне синтетик чара белән бәйләсәк, ике җөмлә арасында бәйләнеш ныграк булыр иде. *Коеп-коеп яңгыр яварга*

*тотынгач, йөзгә, күзгә яшәү өмете күтәрелде* (Г. Ибраһимов) һәм иярчен җөмләнең хәбәре җөмләне тәмамлый алмый.

2. Синтетик чаралар белән бәйләнешкә кергән иярчен җөмләнең иясе белән хәбәре арасында, нигездә, ярашу булмый. Мәсәлән: *Гафури кушкач, мин уңайсыз хәлдә калдым. Мин кушкач, ул килде. Без кушкач, эшләрсез* һ.б. Бу мисалларда ия кайсы затта, нинди санда килүенә карамастан, хәбәр бер формада кала бирә, үзгәрми.

Аналитик чаралар ярдәмендә бәйләнешкә кергән иярчен җөмләләрнең иясе белән хәбәре арасында ярашу була.

Мәсәлән: *Мин ышанам: сез укырсыз.*

*Хакыйкать шул: Мостафин □ кунакка йөрешеп китүдән аеруча саклана □. Шикләнмә: мин килермен* һ.б.

3. Синтетик бәйләнешкә кергән сүзләр татар язма әдәби телендә урнашу ягыннан ирекле түгелләр. Бу иярчен җөмләләргә дә карый. Синтетик иярчен җөмләләр баш җөмләдән алда килә: *Ул палатага керү белән, авыруларың онытыла. Баш сау булса, бүрек табылыр. Туй беткәч, сүз күбәер. Белеме күп меңне егар* һ.б.

Аналитик чаралар белән бәйләнешкә кергән төзелмәләрдә, аналитик иярчен җөмләләр баш җөмләдән алда да, ахырда да килә алалар.

*Агачны кем утырта, җимеше шуныкы.*

*Шуны әйтергә килгән идем: сабан туеннан соң безгә килеп чыгыгыз* (М.Ш.).

Ияртүче теркәгечләр һәм шул рольдә йөри торган сүзләр белән бәйләнгән иярчен җөмләләр, гомумән, баш җөмләдән ахырда киләләр. Мөнәсәбәтле сүзләр белән бәйләнгән иярчен җөмләләр алда да, ахырда да килә алалар. Кайбер мөнәсәбәтле сүзләр белән бәйләнгән җөмләнең урыннарын алыштырып кую да кыен булмый: *Сабан туеннан соң безгә чыгыгыз, шуны әйтергә килгән идем.*

Синтетик чаралар белән бәйләнешкә кергән иярчен җөмләләрдә мондый алмаштырулар табигый түгел.

4. Синтетик бәйләнештәге төзелмәләрдә ияруче җөмлә белән ияртүче җөмлә бер-берсеннән пауза белән аерылмаска мөмкин. Бу янәшәлек очрагы булганда: *Эше бар кешедә мең кешенең эше бар, эше юк кешедә кемнең ни эше бар* (Мәкаль).

Аналитик төзелмәләрдә пауза һәрвакыт ясала.

5. Башка телләр белән чагыштырганда:

- Аналитик төзелмәләрне барлыкка китерүдә катнаша торган чаралар рус телендәге шундый җөмлә төзүдә катнашкан чаралар белән туры киләләр. Мәсәлән: *Кто не работает, тот не ест.*

*Кем эшләми, шул ашамый* (Мәкаль).

- Җөмләләрне синтетик бәйли торган чаралар татар, гомумән, төрки телләр үзенчәлеге. Һинд-европа, рус телендә мондый бәйләнешләр җөмлә төзүдә катнашмыйлар.

6. Синтетик иярчен җөмләләр, гади җөмләдә аерымланган иярчен кисәкләргә бик нык охшаганнар (шул ук бәйләүче чаралар, килү тәртибе, тыныш билгеләре һ.б.). Шуңа күрә буталчык туа.

Шулай итеп, татар телендә төзелмәләр 2 төргә - аналитик һәм синтетикка бүленәләр. Ләкин тел шундый күренеш: андагы фактларны кырт кисеп икегә аерырга мөмкин түгел. Чыгарылма, искәрмәләр була. Аналитик-синтетик мәсьәләсендә дә шулай. Бер үк җөмләдә бәйләнешне белдерә торган чараларның икесе дә катнашырга мөмкин. Мондый төзелмәләрне аналитик-синтетик төзелмәләр дип тә атыйлар.

Мондый конструкцияләрнең бер төре ияртүче теркәгечләрнең шарт фигыль формасы белән бергә килү нәтиҗәсендә төзелә.

Мәсәлән: *Әгәр дә Тукай башта яза башлаган тел белән калса, бүгенге Тукай булмас иде.*

*Әгәр Яһүдә абзый солдатка китә калса, мин өйдә төп эшче кул булып калырга тиеш идем* (С.К.).

Ләкин бу җөмләләрне теркәгечсез дә кулланырга мөмкин: *Яһүдә абзый солдатка китә калса, мин өйдә төп эшче кул булып калырга тиеш идем.* Бу төзелмәләрдә бәйләнешне белдерүче төп чара булып – шарт фигыль формасы (*-са*) тора. *Гомумән, әгәр, гәрчә* кебек теркәгечләр, татар телендә факультатив урын тоталар. Алар кулланылган төзелмәләрдә шарт фигыль формасы хәлиткеч роль уйный. Шул үзенчәлекне истә тотып, мондый җөмләләрне синтетик иярчен җөмләләр рәтендә карыйлар.

2. Аналитик-синтетик төзелмәләрнең икенче төре шарт фигыль формасы һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә ясала.

*Утны кем тотса, шул көяр* (Мәкаль).

*Кемнең итәгенә ут төшсә, шул яна* (Мәкаль).

Мондый җөмләләрдә бәйләүче чара буларак мөнәсәбәтле сүзләр актив роль уйныйлар. Шарт фигыль формасы өстәмә чара буларак кына килә. Шарт фигыль формасын хикәя фигыль формасына да алыштырырга мөмкин. Ул очракта да җөмләләр арасында мәгънә мөнәсәбәте үзгәрми.

*Утны кем тота, шул көяр.*

*Кемнең итәгенә ут төшә, шул яна.*

Шушы үзенчәлекләрне искә алып, мондый җөмләләрне аналитик иярчен җөмләләр рәтендә карыйлар.

Ләкин кайбер җөмләләрдә синтетик һәм аналитик чаралар бердәй вазифаны үтиләр. Ул җөмләләрне аналитик һәм синтетикка бүлеп булмый => Аналитик-синтетик дип атала.

Мәсәлән: Аналитик чара булган күтәрү интонациясе һәм синтетик бәйләүче чара *дип, дигән, ди* сүзләре килә:

*Мин аңа әйттем* : *ни күрсәк совет белән бергә күрербез, бергә илтим, дидем*. һ.б.

**Аналитик та, тезмә дә булган кушма җөмләләр**

Тезмә кушма җөмлә белән аналитик кушма җөмлә арасында торучы төзелмәләр сөйләм төзелешендә шактый урын алып торалар.

Кайбер төр кушма җөмләләр аерым җөмләләре арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләре буенча тезмә кушма җөмләгә дә, аналитик кушма җөмләгә дә тартымлык күрсәтәләр. Мәсәлән: *Минем күзләрем бик җете түгел – күрәм* дигән төзелмәдә ике җөмлә арасында каршылык мөнәсәбәте дә, кирелек мөнәсәбәте дә бар. *Минем күзләрем бик җете түгел, шулай да күрәм* дип әйтелсә, җөмләләр арасындагы кирелек мөнәсәбәтен *шулай да* мөнәсәбәтле сүзе белдерә. *Шулай да* сүзе, күрсәтү алмашлыгы белән бирелгән мөнәсәбәтле сүз буларак, баш җөмлә составында килә, ул анда – кире хәл, димәк, *шулай да* мөнәсәбәтле сүзенең төгәл мәгънәсен бирүче беренче җөмлә - иярчен кире аналитик җөмлә була. Шулай итеп, без бу җөмләне, бер дә шикләнмичә, аналитик җөмлә дип танырга тиеш булабыз.

Шушы ук җөмлә, шул ук мәгънәдә тезмә кушма җөмлә төзи торган *ләкин* теркәгече ярдәмендә дә төзелә ала: *Минем күзләрем бик җете түгел, л ә к и н күрәм.* Аерым җөмләләре тезүче чара ярдәмендә бәйләнгәнлектән, бу җөмләне, бер дә шикләнмичә, тезмә кушма җөмләгә каратабыз.

Шушы ук җөмләдә *ләкин* теркәгече дә, *шулай да* мөнәсәбәтле сүзе дә килергә мөмкин. *Минем күзләрем бик җете түгел, л ә к и н ш у л а й д а күрәм.* Бу синтаксик төзелмәне турыдан-туры тезмә кушма җөмләгә дә, аналитик иярченле кушма җөмләгә дә каратып булмый, бу төзелмә аналитик иярчен дә, тезмә дә булган кушма җөмлә дип танылырга тиеш була. Аларны тезмә һәм аналитик кушма җөмлә арасында торучы төзелмәләр дип тә атыйлар.

Татар сөйләмендә тезмә кушма җөмлә ясауда катнаша торган җыючы теркәгечләр һәм каршылык теркәгечләре бер үк җөмләдә ияртүче аналитик чаралар белән бергә дә кулланыла алалар һәм алар белән бергәләп аналитик та, тезмә дә булган кушма җөмлә төзиләр.

1. Җыючы теркәгечләр төрле ияртүче чара белән бергә кулланылып ясалган кушма җөмләләрне карыйк. Алар арасында аерым җөмләләр арасында төрле мөнәсәбәтләр урнаша.

1) Сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәте: *Сугыш башланып китте, һ ә м ш у л с ә б ә п л е ул корган планнарын ахырына кадәр тормышка ашыра алмады* (Г. Әпсәләмов).

2) Вакыт яки урын мөнәсәбәте: *Шулай бик соңга калып кына капкадан килеп керде, һ ә м н ә к ъ ш у л в а к ы т т а төнлеккә бәйдән ычкындырып куелган Актырнак күтәрелеп чыкты* (Г. Ибраһимов). *Монда кар бик иртә ята, һ ә м ш у н д а ел саен чаңгы ярышлары үткәрелә.*

3) Рәвеш, күләм-чама мөнәсәбәтләре: *Атларга өйрәнә башлаган яшь бала н и ч е к йөри, таякларга баскан малайлар да ш у л р ә в е ш л е бер-ике атлыйлар да таяктан сикереп төшәргә мәҗбүр булалар* (А. Шамов).

4) Атрибутлык мөнәсәбәте: *Сүз арасында Хәйдәров исеме телгә алынды, һ ә м м о н ы ң бер сәбәбе дә бар иде* (Ф. Хөсни).

5) Объектлык мөнәсәбәте: *Алар кичә берничә кеше белән көне буе Казанда булдылар, һ ә м ул ш у н ы үзенең бу эштә катнашмавына сәбәп итеп күрсәтте* (М. Хәсәнов). Бередә мөнәсәбәтле сүз белән бергә -*са* кушымчасы килә алуын да искә төшерик: *Хәлим нәрсә табып к а й т с а, өйдәгеләр ш у ң а риза булып тордылар*. Ләкин биредә -*са* – стилистик чара гына.

6) Хәбәрлекле мөнәсәбәт: *Бергә җырлыйбыз, бергә чәй эчәбез, сугыш башлангач, бер-беребезгә атабыз, һ ә м минә иң гаҗәбе дә ш у л* (К. Тинчурин).

2. Каршылык теркәгечләре төрле ияртүче чара белән бергә кулланылып ясалган кушма җөмләләрне аерым җөмләләр арасында шулай ук берничә төр мөнәсәбәт урнаша.

1) Кире-каршылык мөнәсәбәте: *Алар бары да үзе кебек гади кешеләр, л ә к и н ш у л а й д а алардан кемнең дә булса газета битенә калкып чыгуы да ихтимал бит* (Ә. Еники). *Бик мавыктыргыч иде бу хыял, ә м м а ш у л а й д а Мостафинны нидер тота, күңеле ул эшкә бик тартмый* (Ә. Еники).

2) Каршылык-сәбәп мөнәсәбәте: *Бу бишкөнлектә өченче бригада беренче урынга менеп утырды, ә Хәйдәр бригадасы ш у н ы ң а р к а с ы н*

*д а исемлеккә икенче булып язылып куелды* (Ф. Хөсни). *Сине миңа ярдәмгә җибәрделәр, ә мин ш у л с ә б ә п ле кеше көченнән файдаланучы булып күрендем.*

3) Каршылык-чикләү мөнәсәбәте төрле ияртү мөнәсәбәтләре белән кушыла: *Кем намус белән хезмәт итә, б а р ы ш у л зур хөрмәткә ия була; Ат ш у л д ә р ә җ ә д ә атлыгып тора, т и к дилбегәне генә тотып өлгер* (Г. Ибраһимов).

Бер үк вакытта аналитик та, тезмә дә булган кушма җөмләләр татар синтаксисында махсус өйрәнүне көтәләр.

**Синтетик иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре**

Бу төр кушма җөмләләрнең компонентлары арасында тыныш билгеләре кую кагыйдәләре тулысы белән диярлек җөмлә кисәкләренең аерымлану теориясенә нигезләнә. Монда берничә кагыйдә белән чикләнергә була.

1. Синтентик иярчен җөмлә үзен иярткән сүздән ераклашса, өтерләр белән аерылып куела.

*Ул үзе дә, **нәкъ Рәхим эшләгәнчә**, ару-талуларны белмичә эшләде бит* (А. Расих). ***Соңгы яңалыкларны тыңлаганда**, йокы бүлмәсеннән хатынының тавышы ишетелде* (Р. Зәйдулла).

2. Синтетик иярчен ия, аергыч, тәмамлык һәм урын җөмләләр ияртүче сүздән ераклашканда да, тыныш билгесе белән аерылмыйлар.

*Ул **кояш чыгуны** тереклек дөньясына хәбәр итә* (М. Мәһдиев). ***Ат аунаган җирдә** төк кала* (Мәкаль).

3. *Дип* бәйлек сүзе ярдәмендә бәйләнгән иярчен тәмамлык җөмлә ияртүче сүз белән янәшә тормаса аерымлана.

***Шундый йомшак күңелле ата булырсың дип**, һич тә уйламыйдыр идем* (Г. Әпсәләмов). ***Син шулай ачык һәм матур язасың дип**, һич тә уйламыйдыр идем* (Х. Сарьян).

**Аналитик иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре**

Бу төр төзелмәләрдә баш һәм иярчен җөмләләр арасына тыныш билгеләреннән **нокта, өтер, ике нокта** һәм **җәяләр** куела ала. Монда түбәндәге кагыйдәләр бар.

1. Мөнәсәбәтле сүзе булган баш җөмлә алдан килсә, шул җөмләдән соң ике нокта куела.

*Иң гаҗәбе* ***шунда****: без моңа барыбыз да күнегеп барабыз* (М. Хәбибуллин). *Искәрмә*: Әгәр мөнәсәбәтле сүздән соң *ки* теркәгече килсә өтер куела. *Әкият аңа* ***шулчаклы*** *нык тәэсир итте ки, ул гел шул хакта гына уйлап йөри башлады* (Г. Кутуй).

2. Иярчен җөмлә алдан килеп, аннан соң урын алган баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз булса, ике арага өтер куела.

*Эш зурга китмәде,* ***шулай да*** *кыз бер җәйне кинәт кенә сулды, боекты, тартылды* (М. Мәһдиев). *Ул укырга тиеш, әтисенең васыяте* ***шундый иде*** (А. Расих).

3. Кушма җөмләнең компонентлары парлы мөнәсәбәтле сүзләр яки ияртүче теркәгечләр аша бәйләнешкә керәләр икән, алар арасына өтер куела.

*Үзең* ***нинди****, күзгә шундый* (Мәкаль). *Мин аны шуның өчен яратам,* ***чөнки*** *ул һәрвакыт дөресен сөйли* (Ш. Камал).

4. Компонентлар көттерү яисә аныклау интонациясе аша бәйләнеп, баш җөмлә алдан килсә, алар арасына ике нокта куела.

*Сез беләсез инде: беренче тапкыр ерак шәһәргә якын туганнарыңа кунакка килеп төшү бик күңелле була бит ул* (Ә. Еники). *Күренеп тора: әлеге хәл, Мөхәммәтнең үзеннән бигрәк, бу матур ханымны хафага салган иде* (З. Хөснияр).

5. Нинди дә булса бер сүзне аныклап, җөмлә эчендә килгән иярчен аныклагыч җөмлә, ике яктан өтерләр белән алына.

*Кичкә таба, **кояш баер алдыннан**, печәнчеләр кайтты* (Н. Фәттах). *Моннан ун ел элек, **карты үлгәннән соң**, балалары карчыкны калага тартып караганнар иде каравын* <…> (Ә. Еники).

6. Кереш җөмләләр җәяләр эченә алына, өтер, сызык куелырга мөмкин.

*Бер минуттан соң, бәлки, бер сәгатьтән соңдыр – вакыт йөрәкне әрнетеп үтә иде – Мечик партизаннарның артканын сизде.*

**10.2. Гамәли биремнәр.**

**1 нче бирем.** Аерымланган хәлләр белән килгән гади җөмләләрне һәм кушма җөмләләрне аерып языгыз.

1. *Күктә, бозлы миләшләрне хәтерләтеп, тәлгәш-тәлгәш йолдызлар кабынды* (Р. Низамиев).

2. *Сабан туйлары җитә башласа, йокысы, ялы онытыла иде* (А. Гыйләҗев).

3. *Энә белән кое казыган шикелле байтак тырышты ул* (Р. Низамиев).

4. *Алда озын кыш булса да, авыл инде яз турында уйлый башлады* (А. Гыйләҗев).

5. *Ул, һәрвакыттагыча, олы тыйнаклык һәм сабырлык белән ашыкмыйча гына атлап, Айсылу янына килеп басты* (Ә. Сәлах).

6. *Безнең базарга, сатарга дип, бер чиләк май алып киләләр иде* (З. Зәйнуллин).

7. *Мәктәпне тәмамлагач, Алабуга педучилищесына имтихан тота* (М. Галиев).

8. *Бакча якта түземсезлек белән батырлык кылыр минутны көтеп торган малайлар, "урра" кычкырып, бер-берсен төрткәләшеп, дәррәү кәҗәгә таба йөгерделәр* (Р. Мөхәммәдиев).

9. *Илдар йокыга киткәч, Әнисә, бүген булган хәлләрне башыннан уздырып, йокыга китә алмыйча интекте* (Т. Галиуллин).

10. *Ә менә Кларaның әтисе, шул авылда туып-үскән булса да, Каракошны сагынып бер дә телгә алмый иде* (Ә. Еники).

11. *Хәйрулла абзый үзе хикмәтлерәк итеп сөйләшсә дә, Бибиҗамал икенчерәк итеп сөйләшә иде* (М. Мәһдиев).

12. *Дөнья үз кануньна тотрыклы шул: бер кергән суга яңадан кереп булмый* (М. Галиев).

| | |
|---|---|
| *Аерымланган хәлләр белән килгән гади җөмләләр* | |

| | |
|---|---|
| *Кушма җөмләләр* | |

**2 нче бирем.** Тиңдәш хәбәрле, аерымланган иярчен кисәкле гади җөмләләрне һәм кушма җөмләләрне аерым-аерым шакмакларга тутырыгыз.

| *Тиңдәш хәбәрле гади җөмлә* | *Аерымланган иярчен кисәкле гади җөмлә* | *Кушма җөмлә* |
|---|---|---|
| | | |

1. *Кырга чыксаң, пәрәвез җепләренә ураласың* (С. Поварисов).

2. *Вакыт белән уйнама, ул бер була дөньяда* (Мәкаль).

3. *Туган йортта һәр тупылга кардәш,*

*Һәрбер өянкегә таныш мин,*

*Әнкәемә кайтып сыенам да*

*Туган йортта кабат туам мин* (Г. Морат).

4. *Нократларның киң канатлары астына ышыкланып, тынгысыз кошлар йокыга талды* (Г. Бәширов).

5. *Үлән башларын, чәчәкләрне селкетеп, йомшак кына җил исә, имеш* (Ә. Еники).

6. *Күк йөзе ерак, сыек зәңгәр* (Ә. Еники).

7. *Кояш алтын бишегендә яткан килеш уянып күзен ачуга, җиһанга алсу нур иңә* (Ф. Садриев).

8. *Монда дөнья гап-гади һәм шул ук вакытта бик катлаулы да* (А. Хәсәнов).

9. *Агачлар, үзләрендә гаҗәеп көч тоеп, талгын гына шыбырдашып алалар* (А. Хәсәнов).

10. *Зифа ак каеннар йөгереп чыкканнар, яшел шәлләрен ян тәрәзәгә җилфердәтәләр* (Г. Хәсәнов).

**3 нче бирем.** Җөмләләрнең кайсы төркемгә каравын билгеләгез, тиешле графаларга җөмләнең номерларын куегыз.

| *Гади җөмлә* | *Кушма җөмлә* | |
|---|---|---|
| | *Тезмә кушма җөмлә* | *Иярченле кушма җөмлә* |
| | | |

1. *Шул мине әсир итте, шул миңа сөю тылсымы бирде* (Г. Гыйльман).

2. *Менә зәңгәр күктә сарык бәтиләре төсле, ике ак болыт бер-берсен сөзделәр дә акрын гына бергә кушылып эределәр һәм кояшка таба шуыштылар* (Ф. Садриев).

3. *Менә кич булды, вальс кичәсенә төшәр вакыт җитте* (Ә. Салах).

4. *Чәчәкләрнең нигә кирәге бар, өзеп бирер кешең булмаса?!* (Н. Измайлова).

5. *Уңган җиңгәчәсе егет белән кызның яратышып йөргәнен күрергә тиеш иде* (Ә. Еники).

6. *Шау-гөр килеп су коенып ятканда, кинәт өстебездән кара шәүлә очып узды* (М. Галиев).

7. *Зәңгәр күк астында әле дә сугыш һәм тынычлык дигән ике төшенчә янәшә тора* (Р. Мөхәммәдиев).

8. *Битләрем янып чыга, маңгаема бөрчек-бөрчек тир бәрә* (Ә. Галиев).

9. *Аның инде кул һәм аяклары сизми, кузгалмый, салкын һәм авыр ташлар шикелле түбән тарталар...* (Ш. Камал).

10. *Фәһим яңадан урамга чыкканда, тулган ай үзенең көянтә-чиләкле кызы белән мәчет кыегына ук якынлашып килә иде инде* (Г. Бәширов).

**4 нче бирем.** Текстны укыгыз, баш кисәкләрнең асларына сызыгыз. Җөмлә номерларын тиешле баганаларга урнаштырыгыз.

1. *Әрәмәдә зифа буйлы таллар үскән, аланында <...> җиләк пешкән.*

2. *Болынында, бер-берләрен куыша-куыша, чәчәкләр йөгерешкән.*

3. *Җилнең шаян малайлары, тал ботакларын атынгыч итеп, арыганчы тирбәлгәннәр.*

4. *Кошлары сайраган, әрәмәдә тормыш кайнаган.*

5. *Монда чыпчыкка да, песнәккә дә, каргага да, саесканга да урын җитәрлек булган.*

6. *Саесканнар чит оядан күкәй урламаган, тилгәннәр кош балаларын чәлмәгән...*

7. *Шуңа күрә әрәмәне кошлар, сандугачлар үз иткән.*

8. *Язын кайтканнар, көзен киткәннәр.*

9. *Талларда тирбәнгәннәр, сайрарга өйрәнгәннәр.*

10. *Шатланганнар, куанганнар* (Ф. Яруллин).

| *Тиңдәш кисәкле җөмлә* | *Аерымланган кисәкле җөмлә* | *Тезмә кушма җөмлә* |
|---|---|---|
| | | |

**5 нче бирем.** Тезмә кушма җөмләләрдәге компонентларның баш кисәкләрен билгеләгез. Бәйләүче чараларга бәйле рәвештә, җөмләләрне төркемләгез.

Т – Тезүче теркәгечләр

И – Санау яки каршы кую интонациясе

1. *Торып басты ат, атлап та китте, нинди генә җылы сүзләр әйтмәгәндер аңа Саяф* (Р. Газиз) _______ .

2. *Ул үз тавышын ишетмәде, әмма Эльвира аны аңлады* (М. Маликова) ___ .

3. *Тинтәкнең йә кулы тынмас, йә теле тынмас* (Мәкаль) ______ .

4. *Башын күтәрә төшеп, сагаеп тыңларга итте – баш идәннән күтәрелмәде* (Р. Мөхәммәдиев) ______ .

5. *Шулай итеп, Акбүре иленә дә җәй килде, җылы килде* (Н. Фәттах) _____ .

6. *Читтән карап кешене аңлап булмый, ә күңеленә ул теләсә кемне кертми дә* (Ш. Галиев) ______ .

7. *Үзем елмаям, үзем әле әтиеңә, әле, кызым, сиңа карап-карап алам да самавырга чәй ясарга үреләм* (Ә. Галиев) _______ .

**6 нче бирем.** Нинди теркәгеч кулланылуына карап, җөмләләр ахырына тиешле хәрефләрне куегыз.

Җ – җыючы теркәгеч

К – каршы куючы теркәгеч

Б – бүлүче теркәкеч

1. *Үзе күңеленнән шулай дип кабатлады, ә үзенең кымшанырлык та әмәле юк иде* (Р. Мөхәммәдиев) ___ .

2. *Чәйнең дә тәме булмады, әти, әни берлә дә сүз көйләнмәде* (Г. Исхакый)___.

3. *Хәер, мәчет катындагы кечкенә мәдрәсә булган, әмма ләкин электр да, клуб та булмаган* (Ә. Еники) ____ .

4. *Әллә гайбәт, әллә чын* (Мәкаль) ____ .

5. *Яңа заман яңа байлыклар тудыра, ләкин искенең дә яхшысын саклый белергә кирәк* (Ә. Еники) ______.

6. *Равиль – малай кеше, әбисе тирәсендә күп чуалырга яратмый, керсә дә, тизрәк чыгып китү ягын карый, әмма Гүзәле, кыз бала булганга*

*ахры, авыру әбисеннән бер дә ятсынмый, аңа гел сырпаланып кына тора* (Ә. Еники) _____.

7. *Ярый әле уен бетте, һәм без озакламый таралыштык* (Ш. Маннур) _____ .

8. *Укучылар әллә шуның өчен яраталар иде аны, әллә бу сөйләшүләр чыннан да кызык була* (Л. Ихсанова) ____ .

**7 нче бирем.** Җөмләләрне укыгыз. Теркәгечле тезмә кушма җөмләләрне һәм тезүче теркәгечләр аша бәйләнгән тиңдәш кисәкле җөмләләрнең номерларын аерым-аерым баганаларга урнаштырыгыз.

1. *Бераздан Алпамша үзенең зур гәүдәсеннән уңайсызланган шикелле сузылып ята **һәм** песи аның куенына керә* (М. Галиев).

2. *Бер үк тормышны яшь **һәм** карт күзләр төрлечә күрәләр...* (Ш. Галиев).

3. *Икенче көнне Мастер миңа ачкычын калдырмады, **ә** сувенир турында берни дә әйтмәде...* (М. Галиев).

4. *Капка саен атлар туктала, **ә** җыр тынмый* (М. Галиев).

5. *Җил юк, **әмма** шыбырдап яфрак коела: оеган һаваны кузгатып җибәрмәкче...* (Ш. Галиев).

6. *Арыйсың, **әмма** түземсезләнеп, кабаланып һаман кыймылдыйсың...* (Ш. Галиев).

7. *Түбән төшкән, тулышып салынган авыр болытларны күтәреп тора алмыйча, күк чатлап ертыла **да**, яңгыр коела башлый* (Ш. Галиев).

8. *Борынгы тынлык уяна **да**, уфтанып, тирән бер сулыш ала шикелле* (М. Галиев).

9. *Шатлыкта **да** тоясың, кайгыда **да** тоясың йөрәгең барын* (Ш. Галиев).

10. *Күпер* ***дә*** *артта калды, инешнең чылтыравы* ***да*** *ишетелмәс булды* (Г. Бәширов).

| *Тиңдәш кисәкле җөмлә* |
|---|
| |

| *Теркәгечле тезмә кушма җөмлә* |
|---|
| |

**8 нче бирем.** Теркәгечсез тезмә кушма җөмлә компонентларының нинди интонация ярдәмендә теркәлүенә карап, җөмлә номерларын тиешле шакмакларга урнаштырыгыз.

1. *Тәбрик кулларын юмакчы булып иелгән иде, бабасы рөхсәт итмәде* (Ә. Баянов).

2. *Очраган кешеләрнең бүрекләренә, шәлләренә, кашларына, пәлтә якаларына бәс сарган, борыннарыннан аксыл пар бөркелә* (М. Әмирханов).

3. *Сәкинәгә көч кергәндәй булды, ул адымнарын кызулата төште* (Р. Хафизова).

4. *Ярты көннән артык урманда тулганды Җик Мәргән – ник бер җан иясе очрасын* (М. Хәбибуллин).

5. *Заһидәнең оеклары лычма су, бөтен җире пычранып беткән* (М. Әмирханов).

6. *Хәтерләргә тырышып карыйм, юк, зиһен мондый исемне өстерәп чыгара алмый* (Ә. Баянов).

7. *Әни тамак кырды, әллә нәрсәләр миңа ымлады, мин көлә-көлә егеткә сөйли бирдем* (Г. Исхакый).

8. *Ел артыннан ел узган, малай егет булып җиткән* (Әкият).

9. *Гомер узмый,*

*Без узабыз*

*Шул гомер буйлап* (Р. Миңнуллин).

| *Санау интонациясе* |
| --- |
| |

| *Каршы кую интонациясе* |
| --- |
| |

**9 нчы бирем.** Җөмләләрне укыгыз, тиешле тыныш билгеләрен куегыз. Җөмләләрнең номерларын тиешле баганага урнаштырыгыз.

1. *Бар көчкә йөгерәм тын кысыла* (А. Хәсәнов).

2. *Гәүдәсе сары түше алгы аяклары ап-ак* (Г. Сабитов).

3. *Аларның һәркайсы я улын я онытын озата* (А. Шамов).

4. *Аяклары төп-төз колаклары һәрчак үрә баскан* (Г. Сабитов).

5. *Кара күзләрдә дә якты кышларда да гел шулай* (Р. Низамиев).

6. *Коймалар биек капкалар зур шәп итеп эшләнгәннәр* (М. Латыйфуллин).

7. *Кырпак карлар өшеткеч суыклар* (Г. Хәсәнов).

8. *Мин аны кыш буена тәрбия кылдым кунак иттем* (М. Гафури).

| *Тиңдәш кисәкле гади җөмлә* |
|---|
| |

| *Тезмә кушма җөмлә* |
|---|
| |

**10 нчы бирем.** Бирелгән схемаларга туры килгән тезмә кушма җөмләләрне сайлап алыгыз.

санау

1. 


2. 


3. 


каршы кую

4. 

5.




6.




А. *Шуннан Сатый нык кына төчкереп җибәрде һәм акча аның учына сикереп төште* (А. Гыйләҗев).

Ә. *Тикшерүчеләр бу билгесез Мусаны эзләп табарга тиешләр иде, алар бу эшне ул вакыттагы атаклы Шубин исемле сыщик шымчыга тапшырдылар* (З. Бигиев).

Б. *Кояш та баеды, йолдызлар да калыкты* (Г. Бәширов).

В. *Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә, ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта* (Һ. Такташ).

Г. *Кешене эш өйрәтми, дөнья өйрәтә* (Мәкаль).

Д. *Әллә кояш чыкмаган әле, әллә инде күкне кара болыт каплаган* (С. Зыялы).

1 – , 2 – , 3 – , 4 – , 5 – , 6 – .

**11 нче бирем.** Тәкъдим ителгән җөмләләр арасыннан “артык” җөмләне табыгыз.

1. *Бакча башларында әллә ниткән басмалар, таллыклар, тугайлар* ... (М. Мәһдиев).

2. *Әллә урман, әллә тау өстеннән моң гына булып тулган ай карый* (А. Шамов).

3. *Һавада ачы төтен исе, дары исе һәм саз исе аңкый* (А. Шамов).

4. *Ул да түгел, эре-эре яңгыр тамгалый башлады, ә берничә минуттан чиләкләп коярга тотынды* (М. Хәбибуллин).

**12 нче бирем.** Тәкъдим ителгән җөмләләр арасыннан “артык” җөмләне табыгыз.

1. *Беренче курку үтәргә дә өлгермәде, таш юлдан тәгәрәгән мичкә тавышлары чыгарып, күк йөзе тагын дөбердәде* (М. Хәбибуллин).

2. *Ул да гел алсу, тик кара таплар гына кара булып калган* (А. Хәсәнов).

3. *Язга кадәр әле салкыннар да, бураннар да булачак* (Г. Рәхим).

4. *Сыерчыкларның канатлары да нәфис, сайраулары да гүзәл* (Г. Рәхим).

**13 нче бирем.** Мисаллардан гади җөмләләрне, тезмә кушма җөмләләрне һәм иярченле кушма җөмләләрне аерып, тиешле графаларга аларның номерларын языгыз.

| *Гади җөмлә* | *Тезмә кушма җөмлә* | *Иярченле кушма җөмлә* |
|---|---|---|
| | | |

1. *Үткәннәрне хәтерләтеп, күңелләрне дәртләндереп сайрасын гармун!* (М. Абдуллин).

2. *Кәрим үз күзләренә үзе ышанмады: бәрәңге бакчасы бер төн эчендә тәмам үзгәргән, яктырып, нурланып киткән иде* (Р. Низамиев).

3. *Тукай – шагыйрь генә түгел, ул – публицист һәм журналист, тәнкыйтьче, фольклорчы, тәрҗемәче, сәясәтче, педагог та* (Х. Миңнегулов).

4. *Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, күзләреннән кайнар яшь бәреп чыкты* (Г. Бәширов).

5. *Ә давыл артыннан килгән бәрәкәтле яңгыр тәүлек буена бер әкренәеп, бер шәбәеп туры гына яуды да яуды* (Ә. Еники).

6. *Мин ул күрсәткән өйгә керергә дип селтәнеп ишекне тарткан идем – уянып киттем* (Ш. Камал).

7. *Су өстенә төшкән агач күләгәләре озыная башлагач, Рәхим, рюкзакны тотып, аягына басты* (Р. Бәшәр).

8. *Чабылган печәнне таратып бетергәч, юкәлек күләгәсенә кереп ялга, көндезге ашка туктыйбыз* (Р. Мөхәммәдиев).

9. *Әмма яшьлек ярсуыннан тау чишмәседәй ургып торучы йөрәккә ана назы гына аз, ана кайгыртуы гына җитми* (Ф. Яруллин).

10. *Җил кайдан исә, болыт та шуннан килә* (Мәкаль).

11. *Берәм-сәрәм очраган усакларның көмеш яфраклары, таң сулышыннан уянышып, сөенә-сөенә уйнаган шикелле, җилфердәшәләр...* (Ә. Еники).

12. *Ачык урыннарда, җиргә сыгыла төшеп, хәрәкәтсез ак томан ята* (Ә. Еники).

13. *Дәртле кояш кытыклап уяткандай, табигать тирләп, көлеп күзен ачты* (Ә. Еники).

**10.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар.**

1. Нинди җөмләгә кушма җөмлә диләр?
2. Гади белән кушма җөмләнең аермасы нидә?
3. Тиңдәш хәбәрле гади җөмлә кушма җөмләдән нәрсә белән аерыла?

4. Кушма җөмлә компонентларының баш кисәкләре нинди формаларда белдерелә ала?

5. Аерымланган иярчен кисәкле гади җөмлә кушма җөмләдән нәрсә белән аерыла?

6. Компонентларның санына карап, кушма җөмләләр нинди төрләргә бүленә?

7. Компонентларның үзара бәйләнеш төренә карап, кушма җөмләләрнең төрләрен әйтегез

8. Тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрнең нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

9. Нинди җөмлә тезмә кушма җөмлә дип атала?

10. Тезмә кушма җөмлә компонентлары арасында нинди мәгънә мөнәсәбәтләре урнаша ала?

11. Тезмә кушма җөмлә нинди төрләргә бүленә?

12. Теркәгечле тезмә кушма җөмлә дип нинди җөмләгә әйтәләр?

13. Теркәгечсез тезмә кушма җөмлә дип нинди җөмләгә әйтәләр?

14. Нинди җөмләгә теркәгечле тезмә кушма җөмлә диләр?

15. Теркәгечле тезмә кушма җөмләдә, гади җөмләләрне үзара бәйләп, нинди теркәгечләр килә?

16. Гади җөмләләрне үзара бәйләүче теркәгечләрне алып ташласаң, бәйләүче чара булып нәрсә кала?

17. Теркәгечле тезмә кушма җөмләләр арасында нинди тыныш билгеләре куела?

18. Теркәгечле тезмә кушма җөмләләр арасында нинди очракта тыныш билгесе куелмый?

19. Нинди җөмләгә теркәгечсез тезмә кушма җөмлә диләр?

20. Теркәгечсез тезмә кушма җөмләнең компонентларын бәйләп, нинди чаралар килә?

21. Санау интонациясе ярдәмендә нинди җөмләләр теркәлә?

22. Каршы кую интонациясе ярдәмендә нинди җөмләләр теркәлә?

23. Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрдә, гади җөмләләрне бер-берсеннән аеру өчен, нинди тыныш билгеләре кулланыла?

24. Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрдәге гади җөмләләр арасына кайсы очракта сызык куела?

25. Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрдәге гади җөмләләр арасына кайсы очракта өтер куела?

26. Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрдәге гади җөмләләр арасына кайсы очракта нокталы өтер куела?

27. Иярченле кушма җөмләгә билгеләмә бирегез. Аның үзенчәлеге нидән гыйбарәт?

28. Тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрнең нинди уртак һәм аермалы якларын саный аласыз?

29. Кушма җөмләнең сөйләм оештырудагы роле нидән гыйбарәт?

30. Җанлы һәм язма әдәби телдә кушма җөмлә ничек файдаланыла?

**10.4. Презентация № 1.**

**10.5. Презентация № 2.**

## 11. Лекция № 9

- **Иярчен җөмләләрнең төзелеш һәм мәгънә ягыннан төрләре, аларның синонимлыгы.**

**Аңлатма.** Әлеге тема иярчен җөмләләрнең төзелеш һәм мәгънә ягыннан төрләре, аларның синонимлыгы турында аңлатма бирә.

**Иң мөһим төшенчәләр.** Аналитик, синтетик, иярчен җөмлә төрләре, синонимлык.

**Методик киңәшләр.**

- Тема теоретик мәгълүматны үз эченә алган лекциядән гыйбарәт;
- Мөстәкыйль эш өчен гамәли биремнәр тәкъдим ителә;
- Теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү максатыннан, теоретик сораулар, контроль эш биремнәре һәм тестлар бирелә.
- Лекция презентацияләр белән үрелеп бара.

### 11.1. Иярчен җөмләләрнең төзелеш һәм мәгънә ягыннан төрләре, аларның синонимлыгы.

Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре гади җөмлә кисәкләрен белүгә нигезләнә. Гади җөмлә кисәкләре белән иярчен җөмләләр арасында кайбер аермалар булса да, аларны билгеләгән вакытта, бер үк принцип кулланылыш таба: 1) бәйләнешкә кергән сүзләрнең морфологик төренә, 2) нинди чара ярдәмендә бәйләнүенә һәм 3) компонентлар арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләренә карап эш итәбез. Менә шул өч нигезгә таянып, иярчен җөмләнең функциясе, икенче төрле мәгънә ягыннан төре билгеләнә.

**Иярчен ия җөмлә** баш җөмләнең иясе урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән иянең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

Аналитик төре баш җөмләгә түбәндәге чаралар ярдәмендә бәйләнә:

1) Ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр: *Шунысы куанычлы : аны бизәүгә бездә кулыбыздан килгәнчә катнашачакбыз* (Г. Тавлин).

2) Көттерү интонациясе: *Билгеле: ул моны ирләргә карата әйткән*.

3) *Ки* теркәгече ярдәмендә

Иярчен ия җөмләнең аналитик һәм синтетик төрләр арасында тора торганнары бар. Мәсәлән: *Ул әйткәннәр безгә закон иде. Беләге юан берне егар. Гаиләсе юклар бардыр*.

**Иярчен хәбәр җөмлә** баш җөмләнең хәбәре урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән хәбәрнең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

Иярчен хәбәр җөмләләрнең аналитик төре генә бар: *Иң гаҗәбе шунда: без моңа барыбыз да күнегеп барабыз* (М. Хәбибуллин).

Бәйлүче чаралары: мөнәсәбәтле сүзләр, күтәрү интонациясе, *ки* теркәгече.

**Иярчен аергыч** җөмләнең аналитик төре мөнәсәбәтле сүзләр, күтәрү интонациясе ярдәмендә белдерелә: *Була шундый вакытлар: үз-үзеңне кая куярга белмисең.*

Синтетик төре исем һәм сыйфат фигыль формалары, иялек килеше кушымчасы, сыйфат ясагыч кушымчалар һәм янәшә тору чарасы аша белдерелә: *Без барасы юлларның ике чите гөлчәчәк.*

**Иярчен тәмамлык** җөмләнең аналитик төре мөнәсәбәтле сүзләр, күтәрү интонациясе ярдәмендә белдерелә:

*Мин шуны беләм: ел елга охшамый* (Г.Т.)

*Яулык шаһит: сине һәм илемне йөрәк каным белән сакладым.(*М.Җ.)

Синтетик төре килеш кушымчалары, инфинитив, *дип* бәйлек сүзе ярдәмендә белдерелә: *Син җырлаганны яратабыз. Кулың җитмәгәнгә үремлә.*

**Иярчен вакыт җөмлә** баш җөмләдәге эш яки хәлнең вакытын белдерә.

Иярчен вакыт җөмлә баш җөмләнең вакыт хәле урынына килә яисә андагы мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән вакыт хәлен ачыклый, аның конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

Аналитик төрләре:

1. Ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр:

*Соңыннан бик үкенерләр дә бит, ул чагында инде мин булмам.* (Г.Б.)

2. Парлы мөнәсәбәтле сүзләр:

*Кайчан таш өскә калка, шул чакта ошбу солых бозылыр.* (М.Н.)

Синтетик төрләре:

1. Кушымчалар:

*Җирдә вакыт туктап калсын иде.*

*Очрашканда безнең карашлар*. (Ил.Ихсанова)

*Ишек ябылуга, күз алдына узган көннең вакыйгалары килде.*

2. Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр:

*Башта тыныч кына торган җир асты, эшчеләр эшләргә керешү белән, үзенең мәңгелек тынычлыгын югалтты.*

*Чишмәләр исән чагында*

*Иделләр кибәмени?* һ.б.

**Иярчен урын җөмлә** баш җөмләнең урын хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән урын хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә. Баш җөмләгә бәйләнә торган чаралары чикле. Аналитик төре мөнәсәбәтле сүзләр, ә синтетик төре бәйлек һәм бәйлек сүзләр белән белдерелә:

*Җил кайдан иссә, болыт та шуннан килә* (Мәкаль). *Ат аунаган җирдә төк кала* (Мәкаль).

**Иярчен сәбәп җөмлә** баш җөмләнең сәбәп хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән сәбәп хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә. Аналитик иярчен сәбәп җөмләне баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр, теркәгечләр һәм күтәрү интонациясе бәйли: *Ул елны көз бик коры килде, шуңа күрә кыр эшләре дә тиз бетте* (Г. Галиев).

Синтетик чараларына исем, сыйфат һәм хәл фигыль формалары, килеш кушымчалары, *-лык/-лек* кушымчасы һәм бәйлек, бәйлек сүзләр керә: *Сугыш башлану аркасында, Карлыгач укырга китә алмый калды* (Г. Бәширов).

**Иярчен макст җөмлә** баш җөмләнең максат хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән максат хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә. Аналитик иярчен максат җөмләне баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр бәйли: *Өй яхшы һәм җылы булырга тиеш, моның өчен аны бөтен гигиена таләпләренә җавап бирерлек итеп төзиләр* (Д. Аппакова).

Синтетик чараларына исем, сыйфат, боерык һәм хәл фигыль формалары, юнәлеш килеше кушымчасы, *өчен, дип, диген* бәйлек, бәйлек сүзләре кирә: *Кыз уянмасын өчен, һәркем аяк очы белән генә басып йөри иде* (Г. Кутуй).

**Иярчен рәвеш җөмлә** баш җөмләнең рәвеш хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән рәвеш хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә. Аналитик иярчен рәвеш җөмләне баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр, теркәгечләр бәйли: *Кигән кием ничек туза, яшь гомер шулай уза* (Мәкаль).

Синтетик чараларына сыйфат һәм хәл фигыль формалары, *-дагы/-дәге, -дай/-дәй, -ча/-чә* кушымчалары, *кебек, дип, сыман, шикелле, итеп, төсле, килеш, хәлдә, борын* бәйлек, бәйлек сүзләре кирә: *Тау өсте, пыяла сибелгәндәй, ялтырап ята* (Ә. Еники).

**Иярчен күләм җөмлә** баш җөмләнең күләм хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән күләм хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә. Аналитик иярчен күләм җөмләне баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр, теркәгечләр бәйли: *Кояшлы көннәр никадәр күбрәк булса, бодай өчен шулкадәр яхшырак* (Г. Бәширов).

Синтетик чараларына сыйфат фигыль формалары, *-лык/-лек* кушымчасы, *саен, кадәр, хәтле, дәрәҗәдә, күләмендә* бәйлек, бәйлек сүзләре кирә: *Зәңгәр чишмәнең бакчаларында чәчәкләр, адәм күзе карап туя алмас дәрәҗәдә, чибәр булып җитешәләр* (Г. Ибраһимов).

**Иярчен шарт җөмлә** баш җөмләнең шарт хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән шарт хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә. Аналитик иярчен шарт җөмләне баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр бәйли: *Кояш баеп килә бугай, алайса шалашка кире кайтырбыз* (М. Әмир).

Синтетик чараларына шарт, сыйфат, боерык, теләк, хәл һәм хикәя фигыль формалары, урын-вакыт килеше кушымчасы, *-мы/-ме* кушымчасы, *икән, исә* бәйлек, бәйлек сүзләре керә: *Ярдәм кирәк булса, мин әзер* (М. Юныс).

**Иярчен кире җөмлә** баш җөмләнең кире хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән кире хәлнең конкрет эчтәлеген тәшкил итә. Аналитик иярчен кире җөмләне баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр бәйли: *Көннәр бик начар торды, шулай да язгы эшләр вакытында тәмамланды* (М. Галиев).

Синтетик чараларына шарт, сыйфат, боерык һәм исем фигыль формалары, юнәлеш килеше кушымчасы, *да/дә, та/тә* кисәкчәсе, *белән, карамастан* бәйлек, бәйлек сүзләре керә: *Көн уртасы булуга карамастан, томан таралырга ашыкмады* (Ф. Шәфигуллин).

Баш җөмләне тулысы белән яисә аның берәр кисәген аныклап килгән җөмлә **иярчен аныклагыч җөмлә** дип атала.

Иярчен аныклагыч җөмлә һәрвакыт аналитик була, ул ике төрле чара белән генә иярә.

**1) Аныклаучы теркәгечләр.**

Монда түбәндәге теркәгечләр кулланыш таба: *аеруча, аерым алганда, аннан да бигрәк, ачыграк итеп әйткәндә, башкача әйткәндә, бигрәк тә, дөресрәге, икенче сүз белән әйткәндә, икенче төрле әйткәндә, киңрәк алсак, тулырак әйткәндә, хәтта, һәрхәлдә, шул җөмләдән, шул исәптән, ягъни, ягъни мәсәлән* һ.б.

*(1) Мостафин бу урыннан очып төште, (2)* ***башкача әйткәндә*** *аны яңадан сайламадылар*. (Ә.Еники). *(1) Ул тиле көчкә ия, (2)* ***ягъни*** *бирәү дә аны җиңә алмый*. (Т.Галиуллин). (1) *Аңа бернинди дару үләне тәэсир итмәде, (2)* ***хәтта*** *ашаудан калды*. (М.Хәбибуллин).

**2) Аныклау интонациясе**

*(1) Тугызынчы йортны утка бирмәделәр: (2) кырдан кайтып өлгергән трактор аны аударып, җимереп ташлады*. (А.Гыйләҗев). (*1) Хәер, башка эшләрне дә ят күрмәгән ул: (2) ике өйнең берендә итек басканнар*. (Ф.Яруллин). *(1) Соңыннан, (2) байтак еллар узгач, (1) минем үземә дә дошманның зуррагы, мәкәрлерәге белән алышырга туры килгәне бар*. (Р.Низами).

Интонация ярдәмендә бәйләнгән иярчен аныклагыч җөмлә алдыннан, мәгънәгә зыян китермичә, *ягъни* яки *башкача әйткәндә* теркәгечләрен куеп карау мөмкин.

Баш җөмләнең гомуми эчтәлегенә яисә аның берәр кисәгенә аңлатма рәвешендә килгән җөмлә **иярчен кереш җөмлә** дип атала.

*(1) Аннан соң минем* кызым *(2) (****Язиләне әйтәм****) (1) сине бик ошаткан*. (К Кәримов). *(1) Шушы кыска гына вакыт эчендә балага узган (2) (****вәт заманасы!****) (1) сөйкемсез Гөлнурга, яратмаса да, туачак сабые хакына кадер-хөрмәт күрсәтергә тиеш иде ул*. (Н.Гыйматдинова).

Кереш җөмләләр татар телендә әз өйрәнелгән, аларның атамасы мәсьәләсендә дә бердәм фикер юк. В.Н. Хангилдин һәм М.З. Зәкиев бу берәмлекне *кереш җөмлә* дип йөртәләр. Ф.С. Сафиуллина аларны *керешмә җөмләләр* яки *керешмә конструкцияләр* исеме белән бирә, һәм бу керешмәләргә тулы бер җөмләләрне генә түгел, аерым сүзләрне дә, сүзтезмәләрне дә кертә. С.М. Ибраһимов фикеренчә, татар телендә кереш җөмләләр дә, керешмә җөмләләр дә бар, һәм аларның икесен аерым берәмлек итеп карарга кирәк.

Иярчен кереш җөмләнең аналитик төре генә бар, ул баш җөмләгә *кереш интонациясе* ярдәмендә бәйләнә. Өстәмә бәйләүче чаралар булып, төрле формаль күрсәткечләр килергә мөмкин.

Кереш җөмләләр үзләре икегә бүленә.

**1. Аерым кисәккә аңлатма рәвешендә килгән иярчен кереш җөмлә.**

*(1) Садыйк абзый (2) (хуҗаның исеме шулай иде) (1) шәһәрдәге ниндидер бер учреждениядә эшли икән*. (А.Шамов).

**2. Җөмләнең гомуми эчтәлегенә аңлатма рәвешендә килгән иярчен кереш җөмлә.**

*(1) Тактачалык (2) (**үзегез беләсез**) (1) бездән унсигез чакрымда, (3) кайчандыр зур базарлы, биш мәхәлләле бер авыл иде*. (Ә.Еники). *(1) Авылда (2) (**карап йөрим**) (1) яхшы тальян гармун юк*. (Г.Ахунов).

Баш җөмләгә өстәмә хәбәр рәвешендә килгән һәм аның читенә чыгарылган җөмлә **иярчен өстәлмә җөмлә** дип атала.

(*1) Балалар да әниләренең күзенә генә карап үстеләр. (2) **Айсылу студентка булганчы***. (Б.Камал). (*1) Барысын да кичер ... Елап-көлеп... (2) **Мин кичергән, гафу иткән кебек***. (Зөлфәт).

Татар телендә мондый җөмләләр бөтенләй өйрәнелмәгән диярлек. 1910 нчы елда Әхмәт Һади Максуди өстәлмә күренешкә игътибар итә һәм “гыйлавә җөмлә” (“өстәлмә җөмлә”) дигән термин куллана. Беренчеләрдән булып, бу типтагы берәмлекләр турында К. Сабиров мәгълүмат бирә. Шуннан соң Ф.С. Сафиуллина өстәлмә конструкцияләр исеме белән мондый җөмләләрне дә өйрәнә башлый, аларның үзенчәлекләрен билгели, ләкин *өстәлмә җөмлә* терминын кулланмый.

Егерменче гасырның туксанынчы елларында гына *өстәлмә җөмлә* термины ныклап урнаша, һәм иярчен җөмләләрнең мондый төрен дә өйрәнергә кирәк дигән фикерләр ишетелә башлый. Мәктәп һәм югары уку йортлары дәреслекләренә кертелмәсәләр дә, кайбер фәнни хезмәтләрдә өстәлмә җөмләләр телгә алына башлады.

Иярчен өстәлмә җөмләнең аналитик төре генә бар, ул баш җөмләгә өстәлмә интонациясе ярдәмендә бәйләнә. Өстәмә бәйләүче чаралар булып, төрле формаль күрсәткечләр килергә мөмкин.

*(1) Инде син табылдың,*

*Йөрәктә кабындың.*

*(2) Күктә яңа йолдыз янгандай.*

*Бер аңларсыңмы икән?*

*(1) Сабыр гына көтәм.*

***(2) Җир язларны көтеп алгандай*** (Г. Зәйнәшева).

**Иярчен җөмләләрне үзгәртеп төзү**

Тел белән практик эш иткәндә: текстны редакцияләгәндә, тәрҗемә иткәндә, стиль матур булсын, эчтәлек тизрәк, җиңелрәк аңлашылсын өчен, төп мәгънәгә зыян китермичә, бер төр синтетик җөмләне икенче төр синтетик җөмләгә, бер төр аналитик җөмләне икенче төр аналитик җөмләгә, яисә аналитикны синтетикка һәм киресенчә үзгәртеп төзергә мөмкин.

Иярчен кушма җөмләләрне үзгәртеп төзү белән трансформацион синтаксис шөгыльләнә (вариатив синтаксис).

Үзгәртеп төзүнең билгеле бер таләпләре бар:

1. Җөмләнең төре (функциясе) үзгәрмәскә тиеш.

*Мин шуны беләм: ел елга охшамый.* Иярчен компоненты аналитик тәмамлык җөмлә. Үзгәртәбез: *Мин ел елга охшамаганны гына беләм.* – синтетик тәмамлык җөмлә.

2. Бер төр төзелештән икенче төр төзелешкә үзгәрткәндә кушма җөмлә сакланырга тиеш. Алдагы мисалда сакланган. Кайбер очракларда моңа ирешеп булмый.

Мәсәлән*: Кем эшләми, шул ашамый* җөмләсен синтетикка әйләндергәндә гади җөмлә барлыкка килә *Эшләмәгән ашамый.*

Иярчен хәбәр, аныклагыч, кереш, өстәлмә җөмләләр аналитиктан синтетикка үзгәртелә алмыйлар.

3. Үзгәртеп төзегәндә, нигездә мөстәкыйль мәгънәле сүзләрне өстәргә яки төшереп калдырыга ярамый.

Аналитик кушма җөмләне синтетик төргә әйләндергәндә берничә очрак кулланыла.

- Ялгызак мөнәсәбәтле сүз белән бәйләнгән кушма җөмләләрне үзгәрткәндә, мөнәсәбәтле сүз урынына иярчен җөмлә үзе куела.

Мәсәлән: *Бик каты ишек ябылды, **шуннан соң** бүлмә эче тып-тын булып калды => Бик каты ишек ябылганнан соң бүлмә тып-тын булып калды.*

- Парлы мөнәсәбәтле сүзләр белән бәйләнгән кушма җөмләне синтетикка үзгәрткәндә, сорау алмашлыгыннан торган мөнәсәбәтле сүз төшеп кала, ә күрсәтү алмашлыгы иярчен җөмлә белән алыштырыла.

Мәсәлән: *Җил кайдан иссә, болыт шуннан килә => Болытта җил искән яктан килә.*

Аналитик җөмләдә ялгыз яки парлы мөнәсәбәтле сүзләр булмаса, ул синтетик төргә, мәгънәгә карап, турыдан-туры үзгәртелә яки башта аналитик җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр куеп карала.

Мәсәлән: *Без аның белән бик озак көрешә алмадык, чөнки кызу эш өсте иде => Кызу эш өсте иде, шунлыктан без аның белән озак көрешә алмадык => Кызу эш өсте булганлыктан, без аның белән озак көрешә алмадык.*

Синтетик җөмләләрне аналитик төргә әйләндергәндә шулай ук мөнәсәбәтле сүзләр кулланырга туры килә.

Кушма җөмләнең синтетик өлеше мөстәкыйль гади җөмлә итеп үзгәртелә, һәм шул җөмләне алмаштырырлык мөнәсәбәтле сүз баш җөмләгә куела.

Мәсәлән: *Сугыш башлану аркасында Карлыгач укырга китә алмый калды.*

*Сугыш башланды, шуның аркасында Карлыгач укырга китә алмый калды.*

Бер төр аналитикны икенче төр аналитикка яки синтетикны икенче төр синтетикка үзгәрткәндә бәйләүче чаралар гына үзгәртелсә, мәгънә мөнәсәбәте саклана.

Мәсәлән: *Монда эш кайный, шуңа күрә (шул сәбәпле, шунлыктан, шуның аркасында) күңелле.*

## 11.2. Гамәли биремнәр.

**1 нче бирем.** Иярченле кушма җөмләләрне синтетик һәм аналитик төрләргә аерып, тиешле графаларга җөмләләрнең номерларын куегыз.

| *Синтетик иярченле кушма җөмлә* | *Аналитик иярченле кушма җөмлә* |
|---|---|
| | |

1. *Өлкән буын телне салмак олыгайтып яшәтсә, яшь буын телне санлап яшәртә* (М.Галиев).

2. *Шушы табыгый бизмәннең ике яссылыгы да тигез тибрәнештә булганда гына телнең тере сулышы бөтен мөмкинлегенә киерелеп ачыла* (М. Галиев).

3. *Җан кадерле, дуслар, сугышта,*

*Сугышырга чөнки җан кирәк* (Ф. Кәрим).

4. *Ничек миңа бирделәр, сезгә дә шул килеш тапшырам* (Р. Газизуллин).

5. *Ае юк төннең йолдызлары болытларга күмелгән* (Һ. Такташ).

6. *Корт анасы кайда кунса, күче шунда сарыр* (Мәкаль).

7. *Әнисе әйтеп өлгергәнче, Хәлим чыгып та китте* (А. Гыйләҗев).

8. *Ул елны көз бик коры килде, шуңа күрә кыр эшләре дә тиз бетте* (Г. Галиев).

9. *Күккә карап алгач, ул шаккатты: болытлар гадәттә булмый торган куе яшел иде* (Э. Касыймов).

10. *Ярдәм кирәк булса, мин әзер* (М. Юныс).

**2 нче бирем.** Синтетик иярчен җөмләнең баш җөмләгә нинди чара аша ияргәненә игътибар итеп, тиешле графаларга җөмләнең номерларын куегыз.

| *Кушымча* | *Фигыль формасы* | *Бәйлек һәм бәйлек сүз* | *Янәшә тору* |
|---|---|---|---|
| | | | |

1. *Сивашны кичү озакка сузылу сәбәпле, бүген отряд бөтенләй арыган иде* (Г. Бәширов).

2. *Башкалар ду килеп шаулашып, шатланышып барганда, мин моңаеп барам* (Г. Исхакый).

3. *Мин шуларны укыган саен, үз йортым җимерелгән кеби кайгырдым, хәсрәтләндем* (Г. Исхакый).

4. *Карты бар өйнең хаты бар* (Мәкаль).

5. *Казларны юып келәт киштәсенә менгереп элгәннән соң, кызлар эре көмеш чәчәкләр төшерелгән яшел, зәңгәр чиләкләр белән чишмәгә су алырга төшәләр* (Г. Бәширов).

6. *Бер атна үтүгә, капитан Вильданов госпитальдә ята иде инде* (Ф. Сафин).

7. *Кунак килсә, ишеккә йөгереп чыгып каршы ал* (Мәкаль).

8. *Башта тыныч кына торган җир асты, эшчеләр эшләргә керешү белән, үзенең мәңгелек тынлыгын югалтты* (М. Гафури).

9. *Йөргәге барның дәрте бар* (Мәкаль).

10. *Дуслыкта син сабыр булсаң, һичшиксез,*

*Тамчыдай дуслык та булыр нәкъ диңгез* (Мөхәммәдьяр).

**3 нче бирем.** Аерымланган иярчен кисәкле гади җөмләләрнең һәм синтетик иярчеле кушма җөмләләрнең номерларын тиешле графаларга куегыз.

| *Аерымланган иярчен кисәкле гади җөмлә* | *Синтетик иярченле кушма җөмлә* |
|---|---|
| | |

1. *Гайрәтләнүләре бушка китүен сизгән дулкыннар, күбекле итәкләрен җыя-җыя, диңгезгә шылалар.* (Ш.Рәкыйпов).

2. *Юлдагы алсу тузаннарны туздырып, алсу көчек үз-үзе белән уйный...* (А. Хәсәнов).

3. *Агачлар, үзләрендә гаҗәеп көч тоеп, талгын гына шыбырдашып алалар* (А. Хәсәнов).

4. *Ул ишегалды тулы терлекләрне эчерә, сыерларны сава, бозауларны ябып куя һәм кичке аш урынын әзерли* (А. Шамов).

5. *Ә кояш төшкән урыннарда агачлар ачык яшел төстә* (Г. Сабитов).

6. *Карлар эреп, сулар ага башлады* (М. Гафури).

7. *Авылыбыз өстеннән, канатчыкларын кызу-кызу җилфердәтеп, һавада тирбәлә-тирбәлә, бер пар тургай сайрап үтте* (И. Туктар).

8. *Ул һәр көнне кояш чыкканчы уянырга гадәтләнеп китте* (М. Хәбибуллин).

9. *Очкындай ялтырап, бихисап кар бөртекләре күзне чагылдыра* (Р. Низамиев).

10. *Җилсез, болытсыз көннәрдә, ашыгып, кояш кыздырды* (Н. Фәттах).

**4 нче бирем.** Мәкальләрдәге синтетик иярчен җөмләнең баш җөмләгә нинди чара аша бәйләнгәнлектән чыгып, тиешле графаларга җөмләләрнең номерларын куегыз.

| | Җөмлә | Бәйләүче чара | | .ч. № |
|---|---|---|---|---|
| . | *Дөядәй буең булганчы, төймәдәй акылың булсын.* | шарт фигыль | 1. | |
| . | *Карга кычкыру белән яңгыр килмәс.* | кире шарт фигыль | 2. | |
| . | *Эшкә теләк булса, беләк чыдар.* | хәл фигыль | 3. | |
| . | *Бер ишек ачылсын өчен, җиде ишекне кагалар.* | сыйфат фигыль | 4. | |
| . | *Гыйлемнең тамыры ачы булса да, җимеше татлы.* | исем фигыль + бәйлек | 5. | |
| . | *Җыр булган йортта бәрәкәт бар.* | боерык фигыль + бәйлек | 6. | |

**5 нче бирем.** Иярченле кушма җөмләләрне укыгыз, баш кисәкләрнең асларына сызып, җөмлә чикләрен билгеләгез. Җәяләр эчендә баш һәм иярчен җөмләләрне билгеләп барыгыз.

1. *Картлар дөнья куйганнан соң* [...], *әлеге ике гаилә үз көнен үзе күрергә тиеш иде* [...] (Г. Бәширов).

2. *Роза ничек кинәт кенә кергән булса* [...], *ул шулай кинәт кенә чыгып та китте* [...] (Г. Минский).

3. *Фәһим килеп җиткәндә* [...], *халык ярыйсы ук җыелган иде инде* [...] (Г. Бәширов).

4. *Кем җиңүче була* [...], *кулъяулык шуңа* [...]! (Э. Касыймов).

5. *Телең ни әйтсә* [...], *колагың шуны ишетер* [...] (Мәкаль).

6. *Офык читендә каралҗым болыт куера башладымы* [...], *өйнең берәр почмагына кереп качам* [...] (А. Гыйләҗев).

7. *Балалар кайтуга дип* [...], <...> *тәмле әйберләр өстәлдә урын алды* [...] (Г. Гобәй).

**6 нчы бирем.** Тезмә кушма җөмләләр, иярченле кушма җөмләләр кулланып, хикәя төзеп языгыз.

**7 нче бирем.** Җөмләләрне укыгыз, баш кисәкләрнең асларына сызыгыз. Кушма җөмлә компонентларының чикләрен билгеләгез. Иярчен җөмләнең баш җөмләгә нинди чаралар аша бәйләнгәнен күзәтегез.

1. *Көн кояшлы булса да, ноябрь салкыны үзен сиздерә башлады* (М. Галиев).

2. *Шәһәрнең кеше тулы урамнары, урам буйлап тезелеп киткән кибетләре белән саташып чыга иде ул* (Р. Бәшәр).

3. *Сарык көтүләре утлап йөргән болын башыннан, ялан аякларын яшел чирәмнәргә баса-баса, көдрә чәчләрен тузгытып, зәңгәр күзле Зәлия йөгереп килә күк* (Н. Хәсәнов).

4. *Ул, көн гаять салкын булуга карамастан, бу юлы да ишекне зур итеп ачты* (А. Шамов).

5. *Киек казлар очкан чакта,*

*Үзем генә санадым* (Н. Йосыпова).

6. *Әбием кайчандыр сөйләгәннәрне китапларда очратып, тагын бер кат сөенә идем* (Р. Батулла).

**8 нче бирем.** Мисалларны укыгыз, баш кисәкләрнең асларына сызыгыз, компонентларның чикләрен билгеләгез. Җәяләр эченә баш һәм синтетик иярчен җөмләне билгеләп барыгыз.

*Үрнәк: Бәла килсә [...], кош үз оясына, кеше үз туганнары янына ашыгыр [...]* (Мәкаль). *– (1) Бәла килсә [с.и.җ.], (2) кош үз оясына, кеше үз туганнары янына ашыгыр [б.җ.].*

1. *Данилов яралану аркасында* [...], *отрядны җитәкләү Вәлитовка тапшырылган иде* [...] (Г. Бәширов).

2. *Бу – соңгы көрешү дип* [...] *кем уйлаган* [...] (М. Галиев).

3. *Ходай кушылдырганны* [...] *кеше аера алмас* [...] (Мәкаль).

4. *Теплоход йөрәкләрне дәртләндереп гудок биргәч* [...], *ыгы-зыгы тукталды* [...] (Р. Хәбибуллина).

5. *Үзең тапмаган* [...] *малның кадере булмас* [...] (Мәкаль).

6. *Ярсу елга ташып чыкса* [...],

*Эзе кала ярларда* [...] (Р. Мөхияр).

7. *Ышанып киләчәк тормышка,*

*Сокланып кешеләр гыйшкына, –*

*Җыр тулы* [...] *тынгысыз күңелем*

*Яшәргә, яшәргә ашкына* [...] (Р. Фәйзуллин).

**9 нчы бирем.** Күпнокталар урынына тиешле бәйләүче чараларны куегыз.

1. *Аның белән урамга чык..., борылып карамаган кеше калмый иде* (Ф. Яруллин).

2. *Тау өсте пыяла вагы сибелгән... ялтырап ята* (Ә. Еники).

3. *Кырмыск йөргән... ишетә торган сизгер колакларына бернинди кыштырдаган тавыш та ишетелмәде* (Ф. Кәрим).

4. *Ул самавары белән кайнаш..., Таҗи өй эчен күздән үткәреп алырга өлгерде* (Г. Ахунов).

5. *Кыз уянма..., һәркем аяк очы белән генә басып йөри иде* (Г. Кутуй).

6. *Ул, күзләре еракка текәл..., туган ил табигатенә сокланып торды* (М. Әмир).

7. *Кулың җитмә... үрелмә* (Мәкаль).

8. *Бал татлы ..., бармакны йотмыйлар* (Мәкаль).

9. *Кызыл каймалы дугага эленгән кыңгырау, ат башын чайкап куй..., көмеш тавыш чыгарып зеңгелди* (М. Галиев).

10. *Син үзең кара..., мин берни дә күрмәгән бит* (К. Тинчурин).

Файдалану өчен бәйләүче чаралар: *-кан арада, -дәй, дип, -сын өчен, -сак, -ган саен, -гәнгә, -гач та, -не, -гән килеш.*

**11.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар.**

1. Нинди җөмләгә иярченле кушма җөмлә диләр?
2. Иярченле кушма җөмләдә баш һәм иярчен җөмләне ничек билгеләп була?
3. Мәгънәсе буенча иярчен җөмләләр нинди төрләргә бүленә?
4. Төзелеше буенча иярчен җөмләләр нинди төрләргә бүленә?
5. Синтетик иярчен җөмлә белән аналитик иярчен җөмләнең аермасы нидә?
6. Синтетик иярчен җөмлә дип нинди җөмләгә әйтәләр?
7. Синтетик иярчен җөмләгә нинди үзенчәлекләр хас?
8. Синтетик иярчен җөмләләр баш җөмләгә нинди грамматик чаралар аша бәйләнә?
9. Синтетик иярчен җөмлә аерымланган иярчен кисәктән нәрсә белән аерыла?
10. Синтетик иярчен җөмлә янында нинди тыныш билгесе куела?
11. Синтетик иярчен җөмләләр кайсы очракта баш җөмләдән өтер белән аерыла?
12. Синтетик иярчен җөмлә нинди очракта баш җөмләдән бернинди билге белән дә аерылмый?
13. Өтер белән аерылган синтетик иярчен җөмләне өтер куелмый торган итеп һәм киресенчә үзгәртеп буламы? Булса, ничек итеп?
14. Аналитик иярчен җөмлә дип нинди җөмләгә әйтәләр?
15. Аналитик иярчен җөмләгә нинди үзенчәлекләр хас?
16. Аналитик иярчен җөмләләр баш җөмләгә нинди грамматик чаралар аша бәйләнә?
17. Аналитик иярчен җөмлә янында нинди тыныш билгесе куела?
18. Аналитик иярчен җөмләләр кайсы очракта баш җөмләдән ике нокта белән аерыла?
19. Аналитик иярчен җөмлә нинди очракта баш җөмләдән өтер белән аерыла?

20. Аналитик иярчен җөмлә нинди очракта баш җөмләдән сызык белән аерыла?
21. Аналитик кереш һәм өстәлмә җөмләләр баш җөмләдән нинди тыныш билгесе ярдәмендә аерымланалар?
22. Төзелеше ягыннан җөмләне бер төрдән икенче төргә үзгәрткән вакытта нинди кагыйдәләр искә алынырга тиеш?
23. Нинди җөмлә иярчен ия җөмлә дип атала?
24. Нинди җөмлә иярчен хәбәр җөмлә дип атала?
25. Нинди җөмлә иярчен аергыч җөмлә дип атала?
26. Нинди җөмлә иярчен тәмамлык җөмлә дип атала?
27. Нинди җөмлә иярчен рәвеш җөмлә дип атала?
28. Нинди җөмлә иярчен күләм җөмлә дип атала?
29. Нинди җөмлә иярчен вакыт җөмлә дип атала?
30. Нинди җөмлә иярчен урын җөмлә дип атала?
31. Нинди җөмлә иярчен сәбәп җөмлә дип атала?
32. Нинди җөмлә иярчен максат җөмлә дип атала?
33. Нинди җөмлә иярчен шарт җөмлә дип атала?
34. Нинди җөмлә иярчен кире җөмлә дип атала?
35. Нинди җөмлә иярчен аныклагыч җөмлә дип атала?
36. Нинди җөмлә иярчен кереш җөмлә дип атала?
37. Нинди җөмлә иярчен өстәлмә җөмлә дип атала?

### 11.4. Мөстәкыйль эш өчен биремнәр.

**1 вариант**

1. Һәр җөмләнең баш кисәкләрен табыгыз, компонентларның чикләрен билгеләгез, схемаларын сызып, тулы билгеләмә бирегез:

1) *Күктә болыт парлы булып*

*Йөзеп барган җиреннән*

*Ике якка аерылса,*

*Яшем тама күземнән* (Ш. Җиһангирова).

2) *Көн салкынчарак булса да, күктәге нурлы кояш күңелләрне җылытып, дәртләндереп тора* (Г. Гыйльманов).

3) *Ләкин кешелек тормышы шулай корылган инде: бер борчу артыннан икенчесе, өченчесе килә дә җитә...* (Г. Гыйльманов).

4) *Алмагачта ничә яфрак булса,*

*Шулкадәрле йөрәк бар миндә* (Г. Гыйльманов).

5) *Кеше үзе теләгән кадәр генә бәхетле була!* (Г. Гыйльманов).

6) *Алар киткән якта тузан болыты гына бөтерелеп калды* (Ф. Шәфигуллин).

*7) Җил ялгыз йөрми: озакламый кар ява башлады* (И. Гази).
*8) Туплар тынсын өчен утка керде,*
*Яуга керде Фәрит Яруллин* (Р. Вәлиев).

*9) Сыгылма такталар арасында күп вакыт чабата кысылып калучан була, шуңа күрә ташучылар күпердән бик сакланып, туры барырга тырышалар* (Ф. Сәйфи-Казанлы).

10) *Истә тот: былбыллар*

*Сайрамый гел генә* (Ф. Яруллин).

2. Түбәндәге шигъри юлларга үз мөнәсәбәтегезне белдереп, гади һәм ике компонентлы кушма җөмләләрдән хикәя төзеп языгыз.

***Авырлыкны үлчәр өчен***

***Үлчәү бар,***

***Сабырлыкны үлчәр өчен***

***Үлчәү юк*** (Ф. Яруллин).

**2 вариант**

1. Һәр җөмләнең баш кисәкләрен табыгыз, компонентларның чикләрен билгеләгез, схемаларын сызып, тулы билгеләмә бирегез:

1) *Ал яулыгын болгап китеп бара*

*Ал болытлар кояш батышка* (Ф. Яруллин).

2) *Хәтереңдәме: тышта коеп-коеп*

*Яңгыр ява иде* (Ш. Җиһангирова).

3) *Җил-давыллар каршы тора алмас,*

*Тотынышып барсак кулга-кул* (Ш. Җиһангирова).

4) *Иң гаҗәбе шул: бүген аның бер җире дә авыртмый* (Г. Гыйльманов).

5) *Басуларның саф һавасы белән*

*Чистарганда каннар, үпкәләр,*

*Онытыла тормыш ваклыклары,*

*Күңелдәге рәнҗү, үпкәләр...* (Ш. Галиев).

6) *Кайчак сөю давыллары*

*Алсалар да бөтереп,*

*Дөньяның бар матурларын*

*Булмый сөеп бетереп* (Р. Миңнуллин).

7) *Мең эшемне ташлап, кабат-кабат*

*Авылыма кайткан саен мине*

*Мәңге шулай капка төбебездә*

*Әткәм-әнкәм каршы алса иде* (Ш. Җиһангирова).

8) *Ата-ана кадерен аңлар-белер өчен,*

*Аллаһы Тәгалә адәм баласына балалар биргән* (Ш. Җиһангирова).

9) *Әллә нинди ялтыравык челтәр белән бизәлгән сары капканың уң ягында – әлеге карт әйткән матур ишек...* (К. Нәҗми).

10) *Сине кемдер һаман сагынып яши,*

*Син кемнедер сагынып яшисең* (Г. Гыйльманов).

2. Әлеге шигъри юлларга үз мөнәсәбәтегезне белдереп, гади һәм ике компонентлы кушма җөмләләрдән хикәя төзеп языгыз.

***Мәрхәмәтне үлчәргә дә***

***Бизмән юк,***

***Мәхәббәтне үлчәргә дә***

***Бизмән юк*** (Ф. Яруллин).

## 11.5. Тест (контроль эш).

**Текстны укыгыз һәм биремнәрне үтәгез**

(1) *Әнисе белән әтисен ну кызык итте бүген Фәрит.* (2) *Иртәнге чәйне эчкәч тә, беркемнән дә сорамыйча, беркемгә дә әйтмичә генә өйдән чыгып китте.* (3) *Билгеле инде: матур сеңлесен дә үзеннән калдырмады.* (4) *Алар капканы бер дә шыгырдатмыйча гына ачып чыктылар.* (5) *Менә инде хәзер үз авылларыннан ике чакрымдагы Дуслар авылына баралар.* (6) *Маһирә әбиләренә, кунакка.* (7) *Ә беләсезме: әбиләре әйбәт аларның, матур да.* (8) *Анысы, ул барында да тузанга болай рәхәтләнеп, лап-лоп итеп баса алмыйсың, өстәл янында аягыңны селкетеп тә утыра алмыйсың.* (9) *Утырып кара: әбиләре әни белән әтидән дә усал!* (10) *Тик, ул ачуланса да, болай гына, тышыннан гына ачулана.* (11) *Ә эченнән һаман да шул әйбәт әби булып кала.* (12) *Аның су шикелле үтә күренмәле зәңгәр күзләре дә, битендәге күп-күп җыерчыклары да һаман сөйкемле булып кала.* (13) *Шул сөйкемле булганы өчен аны ачуландырасы да килми...* (14) *И, әйбәт әбиләре озак, бер ай кунак итәр әле.* (15) *Ә бәлки, дәү үскәнче дә шунда торып калырлар.* (16) *Әбисе картаеп китә икән, абыйсы Фәридәне үзе дә бага ала ич.* (17) *Ә әнисе белән әтисе әнә үзләре генә торып карасыннар.* (18) *Аларга шулай күңелле булыр...* (Р.Фәизов).

1. 3 нче җөмлә ул –

1) аналитик иярчен тәмамлык җөмләле кушма җөмлә

2) аналитик иярчен ия җөмләле кушма җөмлә

3) аналитик иярчен хәбәр җөмләле кушма җөмлә

4) аналитик иярчен аныклагыч җөмләле кушма җөмлә

2. 6 төзелмә ул –

1) урын хәле, максат хәле

2) урын хәле, кыек тәмамлык

3) өстәлмәләр

4) 1 составлы, ким җөмлә

3. Иярченле кушма җөмләләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез:

1) 3, 7, 8, 9, 16

2) 3, 7, 8, 9, 13, 16

3) 2, 3, 7, 8, 9, 10, 13, 15, 16

4) 3, 7

4. Тиңдәш кисәкләре булган җөмләләрдән генә торган рәтне билгеләгез:

1) 1, 2, 6, 7, 8, 9, 10, 12, 17

2) 1, 2, 7, 8, 9, 10, 12, 17

3) 1, 2, 8, 9, 12, 17

4) 1, 2, 8, 9, 12

5. Инкяр җөмләләрдән генә торган рәтне билгеләгез:

1) 2, 3. 4, 8, 13

2) 2, 3, 8, 13

3) 2, 3, 4, 8, 9, 13

4) 3, 8, 13

6. 15 нче җөмлә ул –

1) билгесез үтәүчеле бер составлы фигыль, ким

2) билгеле үтәүчеле бер составлы фигыль, ким

3) ике составлы, тулы

4) ике составлы, ким

7. Инверсия кайсы җөмләләрдә чагылыш тапкан?

1) 1, 7

2) 1, 7, 8

3) 7, 8

4) 1. 7, 8, 18

**11.6. Тест (контроль эш).**

**Текстны укыгыз һәм биремнәрне үтәгез.**

(1) *...Дәү кеше бик кадерләп, кулын тидерер-тидермәс кенә йөртеп, сеңлесенең битеннән, чәчләреннән сыйпап алды.* (2) *Аны уятмас өчен, сак кыймылдап, куллары белән җиргә таянды.* (3) *Башын артка салып, уңайлы итеп утырды.* (4) *Наратлар да аның сеңлесенең йокысын саклыйлар, аны кояш нурларыннан ышыкларга тырышалар, ә кояш барыбер аларның кайда икәнен белеп тора, яшел ылыслар арасыннан күзен кысып, кызыклы итеп карый иде.* (5) *Инде күбәләкләр дә уянып, үз өйләреннән торып чыкканнар, анда-санда елмаеп утырган чәчәкләр өстендә канатларын җилпеп тибрәнәләр иде.* (6) *Туктале, берсен-берсе*

*куышып уйныйлар, әйлән-бәйлән уйныйлар икән бит алар!* (7) *Әнә берсе ничек хәйләле итеп, әле туктап, әле бик кызу оча...* (8) *Беләсе иде: күбәләкләр барысы да бала гына микән алар?* (9) *Әллә аларның да әти-әниләре бар микән?..* (10) *Туктале, алар өйдән чыгып киткәнгә күп булды бит инде.* (11) *Әнә кояш та Күшәр өстенә җитте.* (12) *Ә әтисе белән әнисе инде аларны сагына башласалар?* (13) *Аларны эзләсәләр, таба алмагач, югалганнар, дип, кайгырсалар?* (14) *Әниләре, "канәфер" бөртекләрем кайда икән минем, дип еласа?* (Р. Фәизов).

1. 8 нче җөмлә ул –

1) аналитик иярчен тәмамлык җөмләле кушма җөмлә

2) аналитик иярчен ия җөмләле кушма җөмлә

3) аналитик иярчен хәбәр җөмләле кушма җөмлә

4) аналитик иярчен аныклагыч җөмләле кушма җөмлә

2. 5 җөмләдәге тиңдәш кисәкләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез:

1) *уянып, торып чыкканнар, елмаеп, җилпеп, тибрәнәләр иде*

2) *торып чыкканнар, тибрәнәләр иде*

3) *уянып, елмаеп, җилпеп*

4) *уянып торып чыкканнар, җилпеп тибрәнәләр иде*

3. Иярченле кушма җөмләләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез:

1) 4, 8, 13, 14

2) 8, 13, 14

3) 6, 8, 10, 13, 14

4) 8, 10, 13, 14

4. 1 нче җөмләдә ***битеннән, чәчләреннән*** нинди җөмлә кисәкләре?

1) туры тәмамлык, туры тәмамлык

2) кыек тәмамлык, кыек тәмамлык

3) урын хәле, урын хәле

4) туры тәмамлык, кыек тәмамлык

5. 3 нче җөмлә ул –

1) билгеле үтәүчеле бер составлы фигыль, ким

2) билгесез үтәүчеле бер составлы фигыль, ким

3) ике составлы, ким

4) ике составлы, тулы

6. 2 нче җөмләдәге ***уятмас өчен*** нинди җөмлә кисәге?

1) максат хәле

2) сәбәп хәле

3) гади фигыль хәбәр

4) кушма фигыль хәбәр

7. Инверсия кайсы җөмләләрдә чагылыш тапкан?

1) 6, 8.

2) 6, 8, 14.

3) 6, 8, 10, 14.

4) 10, 14.

**11.7. Тест.**

**Ике компонентлы кушма җөмлә синтаксисы**

**1 вариант**

1. Хәбәрлектән чыгып, җөмләнең төрен билгеләгез:

*Күңелеңдә нинди сагыш,*

*Моң барын беләм әле!* (Ш. Җиһангирова).

1) гади җөмлә

2) кушма җөмлә

2. Хәбәрлектән чыгып, җөмләнең төрен билгеләгез:

*Без, анда барып, кармак салып арыганнан соң, балыкчы бабай янына барып, балык пешереп, чәй эчеп көнне үткәреп, кояш баер алдыннан гына кайта торган идек* (М. Гафури).

1) гади җөмлә

2) кушма җөмлә

3. Хәбәрлектән чыгып, җөмләнең төрен билгеләгез:

*Бара идек таңда урманнарга,*

*Кошлар моңын бергә тыңларга* (Р. Вәлиев).

1) гади җөмлә
2) кушма җөмлә

4. Җөмләнең структур төрен билгеләгез:

*Чәчебезгә чаллар кунса кунсын,*

*Мәхәббәткә керләр кунмасын* (Ш. Җиһангирова).

1) тезмә кушма җөмлә

2) иярченле кушма җөмлә

5. Җөмләнең структур төрен билгеләгез:

*Бал татлы дип, бармакны йотмыйлар* (Мәкаль).

1) синтетик иярченле кушма җөмлә

2) аналитик иярченле кушма җөмлә

6. Җөмләнең структур төрен билгеләгез:

*Ярату өчен матур йөрәк кирәк, бәхетле булу өчен батыр йөрәк кирәк* (Г. Гыйльманов).

1) теркәгечле тезмә кушма җөмлә
2) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә
3) синтетик иярченле кушма җөмлә
4) аналитик иярченле кушма җөмлә

7. Кушма җөмләне табыгыз:

1) *Һәркем үзенең бәхете турында үзе кайгыртырга тиеш* (Р. Вәлиев).

2) *Ул – чәчәк исләреннән оеп яткан җәйге бер болын* (Ф. Бәйрәмова).

3) *Көзгә авышса да, бүген кич җылы, хәтта якты, нурлы* (Г. Гыйльманов).

4) *Без бит синең белән бер-беребезгә*

*Каш астында ике күз төсле* (Ш. Җиһангирова).

8. Җөмләдә бәйләүче чараны билгеләгез:

*Барып җиткәч, балык сикерүдән җәелгән су алкаларына карап, төрле уйлар уйлап, чирәмдә бик озак утырдым* (И. Гази).

1) *–кәч*

2) *–дән*
3) *–п*
4) *–гән*

9. Иярчен җөмләнең функциональ-семантик төрен билгеләгез:

*Сөенәмен, сине сөйгән җилләр*

*Сыйпап китсә минем яңакны* (Ф. Яруллин).

1) иярчен тәмамлык җөмлә

2) иярчен аергыч җөмлә

3) иярчен шарт җөмлә

4) иярчен сәбәп җөмлә

10. Иярчен җөмләнең функциональ-семантик төрен билгеләгез:

*Син булмаган җирдә яшәү күңелсездер* (Ш. Җиһангирова).

1) иярчен урын җөмлә

2) иярчен аергыч җөмлә

3) иярчен сәбәп җөмлә

4) иярчен ия җөмлә

11. Иярчен җөмләнең функциональ-семантик төрен билгеләгез:

*Син белеп тор: икебезнең*

*Мәхәббәттән башка*

*Әйләнермен мин тимергә*

*Йә булмаса ташка* (Р. Миңнуллин).

1) иярчен шарт җөмлә

2) иярчен тәмамлык җөмлә

3) иярчен хәбәр җөмлә

4) иярчен кире җөмлә

12. Иярчен җөмләнең функциональ-семантик төрен билгеләгез:

*Идел койган диңгез саега бара,*

*Кешеләрнең хәтере шикелле* (Р. Вәлиев).

1) иярчен күләм җөмлә

2) иярчен рәвеш җөмлә

3) иярчен аергыч җөмлә

4) иярчен аныклагыч җөмлә

13. Мисаллар арасыннан “артык” җөмләне табыгыз:

1) *Күкрәктә йөрәк бар чакта,*

*Сөюгә бетмәс урын* (Ф. Яруллин).

2) *Нигә, әнкәй, нигә картаясың,*

*Дөнья шундый матур чагында?* (Р. Вәлиев).

3) *Кипшергән иреннәрен ялаштырып карап торды да кеше юграк вакытта су сатучы янына килде* (А. Гыйләҗев).

4) *Беркөн, без уйнаган вакытта, яныбызга бер кечкенә генә кыз килеп карап торды* (Ш. Усманов).

14. Тыныш билгеләренең дөрес куелган вариантын табыгыз:

*Күкләр күкри*

*Әйтерсең лә ул мин*

*Яңагына сугам ялганның* (Р. Вәлиев).

1) *Күкләр күкри:*

*Әйтерсең лә ул мин,*

*Яңагына сугам ялганның.*

2) *Күкләр күкри,*

*Әйтерсең лә ул мин*

*Яңагына сугам ялганның.*

3) *Күкләр күкри,*

*Әйтерсең лә ул – мин*

*Яңагына сугам ялганның.*

4) *Күкләр күкри,*

*Әйтерсең лә ул – мин,*

*Яңагына сугам ялганның.*

15. Тәңгәллекне күрсәтегез:

| | |
|---|---|
| 1) *Ә көн шундый матур* **(?)** *ә көн шундый кояшлы* (М. Галиев). | А) – |
| 2) *Дөнья тулы* **(?)** *кеше арасында Япа-ялгыз иңрәп йөрисең* (Ш. Җиһангирова). | Б) : |
| 3) *Шундый тойгы күңелемдә һаман-һаман* **(?)** *Дөнья миңа мәңгелеккә бирелгән күк* (Г. Гыйльманов). | В) тыныш билгесе куелмый |
| 4) *Ничек яши ул, ни хисабына яши* **(?)** *бераү дә рәтләп белми* (С. Шәмси). | Г) , |

16. Тәңгәллекне күрсәтегез:

1) *Яңгыр Зөфәр белән Гөлүсә дуслашсын* А) иярчен хәбәр җөмлә

*өчен генә яуган икән* (Җ. Дәрзаман)

2) *Сирәк кайтылганга күрә, үзгәрешләр* Б) иярчен аергыч җөмлә

*бигрәк тә нык сизелә* (М. Галиев).

3) *Һәр көз шулай: яфраклар*

*Бер өелә, бер туза...* (Ш. Җиһангирова). В) иярчен максат җөмлә

4) *Мин эзләрмен йолдызлардан*

*Үзем ачкан Җир кызын* (Ф. Яруллин). Г) иярчен сәбәп җөмлә

17. Текстны укыгыз һәм биремнәрне үтәгез:

(1) *... Гомер яшәвең белән түгел, яшәвеңне тоюың белән кызык. (2) Сәүбән яшәде, әмма яшәвен тоймады.*

(3) *... Яшәү – үзгәрү генә түгел, үз-үзең булып калу да.* (4) *Сәүбән үзен югалта язды, ахры.*

(5) *... Гомернең озынлыгы еллар белән түгел, кылган изгелекләр белән үлчәнә.* (6) *Сәүбән начарлыклар кылып яшәмәде, әмма ул изгелекләр дә кылмады!*

(7) *... Син яшәгән гомерне синнән башка беркем дә яши алмый.*

(8) *... Һәр гомер үз язмышын иҗат итә.* (9) *Бу иҗатның төп шарты – көрәш.* (10) *Көрәш тукталдымы – гомер үлә башлый...*

(11) *... Чынлыкта, бәхет көрәш аша килә.* (12) *Башкалар белән көрәшмәсәң, үз-үзең белән көрәшәсең.* (13) *Сәүбәннең сагыштан, борчулардан, авырулардан арыган күңелендә әнә шул көрәш бара иде* (Г. Гыйльманов).

1. Инкяр җөмләләрдән генә торган рәтне билгеләгез:

1) 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 10, 12

2) 2, 6, 7

3) 1, 2, 3, 5, 6, 7

4) 1, 2, 3, 5, 6, 7, 12

2. Тезмә кушма җөмләләрдән генә торган рәтне билгеләгез:

1) 1, 2, 5, 6, 10

2) 6, 7, 10

3) 6, 10

4) 6

3. 10 җөмлә ул –

1) иярченле кушма җөмлә

2) теркәгечле тезмә кушма җөмлә

3) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә

4) гади җөмлә

4. Кереш сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез:

1) *әмма, ахры, чынлыкта*

2) *ахры, чынлыкта*

3) *ахры*

4) *ахры, чынлыкта, әнә*

5. 12 җөмлә ул –

1) гомум үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә

2) билгеле үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә

3) ике составлы, ким җөмлә

4) иярченле кушма җөмлә

6. Иярченле кушма җөмләләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез:

1) 2, 6

2) 7, 10

3) 7, 10, 12

4) 2, 6, 7, 10, 12

**2 вариант**

1. Хәбәрлектән чыгып, җөмләнең төрен билгеләгез:

*Гомерендә алтын күрмәгән ул,*

*Янчык тулы көмеш йөртмәгән,*

*Алтын төсен күргән игеннәрдә,*

*Көмеш сулар эчкән чишмәдән* (Р. Вәлиев).

1) гади җөмлә

2) кушма җөмлә

2. Хәбәрлектән чыгып, җөмләнең төрен билгеләгез:

*Мең шатлык койса да күңелгә,*

*Бәхетем елгасы саега* (Р. Вәлиев).

1) гади җөмлә

2) кушма җөмлә

3. Хәбәрлектән чыгып, җөмләнең төрен билгеләгез:

*Бары Галиулла абзый гына, әледән-әле пристань түбәсенә чыгып, пароход килгәнен караштыргалап йөри иде* (Ф. Сәйфи-Казанлы).

1) гади җөмлә

2) кушма җөмлә

4. Җөмләнең структур төрен билгеләгез:

*Тәрәзәдә ут бар икән, димәк, анда тормыш, тереклек бар* (А. Гыйләҗев).

1) тезмә кушма җөмлә
2) иярченле кушма җөмлә

5. Җөмләнең структур төрен билгеләгез:

*Табакны тәрәзә каршына, кояш төшә торган урынга куйдылар* (Г. Гыйльманов).

1) синтетик иярченле кушма җөмлә

2) аналитик иярченле кушма җөмлә

6. Җөмләнең структур төрен билгеләгез:

*Кул сузарлык кына ара –*

*Шундый ерак арабыз!* (Г.Гыйльманов).

1) теркәгечле тезмә кушма җөмлә

2) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә
3) синтетик иярченле кушма җөмлә
4) аналитик иярченле кушма җөмлә

7. Кушма җөмләне табыгыз:

1) *Нечкә билле ак самовар, бөтен тишекләреннән пар бөркеп, сызгыра-сызгыра сәке йөзлегенә килеп утырды* (М. Әмир).

2) *Ай нуры агач яфракларында ялтырый, киоск түбәләрендә балкып ята, аллеяларда, агач араларында күлдәй җәелеп тора иде* (И. Гази).

3) *Офыкларга карап, һәр көн саен*

*Сине уйлыйм, сиңа табынам* (Р. Вәлиев).

4) *Я дөньяны үзгәртәм мин бүген,*

*Я булмаса үзем үзгәрәм* (Р. Вәлиев).

8. Җөмләдә бәйләүче чараны билгеләгез:

*Күз ясармын, зәңгәр буяу*

*Табалсам әгәр,*

*Чөнки синең күзләрең бит*

*Сагыштай зәңгәр* (Р. Вәлиев).

1) *чөнки*

2) -*са*

3) -*тай*

4) *әгәр*

9. Иярчен җөмләнең функциональ-семантик төрен билгеләгез:

*Көн саен шулай: Зөһрә мәктәптән йөгереп кайта да стенада эленеп торган календарь каршына килә* (Г. Гыйльманов).

1) иярчен ия җөмлә

2) иярчен хәбәр җөмлә

3) иярчен кире җөмлә

4) иярчен рәвеш җөмлә

10. Иярчен җөмләнең функциональ-семантик төрен билгеләгез:

*Хат аны шундый дулкынландырды: ул ишек дөбердәткәнне дә ишетми калды* (И. Гази).

1) иярчен тәмамлык җөмлә

2) иярчен рәвеш җөмлә

3) иярчен хәбәр җөмлә

4) иярчен күләм җөмлә

11. Иярчен җөмләнең функциональ-семантик төрен билгеләгез:

*Мәхәббәт сагышы булып*

*Соңгы карлар яуса да,*

*Язгы җыр булып исемең*

*Күңелемдә саклана* (Ш. Җиһангирова).

1) иярчен кире җөмлә

2) иярчен рәвеш җөмлә

3) иярчен тәмамлык җөмлә

4) иярчен шарт җөмлә

12. Иярчен җөмләнең функциональ-семантик төрен билгеләгез:

*Җәй бик эссе торгачтын, үзләре дә коенырга дип атлыгып килгәннәр бит инде* (М. Вәлиев).

1) иярчен вакыт җөмлә

2) иярчен максат җөмлә

3) иярчен сәбәп җөмлә

4) иярчен кире җөмлә

13. Мисаллар арасыннан “артык” җөмләне табыгыз:

1) *Аннары, онытырлык булсам, бүген, кырык ел вакыт узуга да карамастан, мин аларны китерә алыр идеммени?* (Г. Минский).

2) *Төн якынлашуга карамастан, әтәчләрнең тавышлары ишетелми* (Ф. Әсгать).

3) *Нәкъ син кочкан кебек,*
*Таң җилләре килеп кочаклый...* (Г. Гыйльманов).

4) *Минем сөю – бер тау куенында*
*Хәлсез эреп яткан кар кебек,*
*Ә шулай да, ул кар астында да*
*Гайрәтле бер ташкын бар кебек...* (Г. Гыйльманов).

14. Тыныш билгеләренең дөрес куелган вариантын табыгыз:

*Әгәр туган җирнең җаны булса*
*Туган җирнең җаны әнкәй ул* (Г. Гыйльманов).

1) *Әгәр туган җирнең җаны булса,*
*Туган җирнең җаны әнкәй – ул!*

2) *Әгәр туган җирнең җаны булса,*

*Туган җирнең җаны – әнкәй ул!*

3) *Әгәр туган җирнең җаны булса,*

*Туган җирнең җаны әнкәй ул!*

4) *Әгәр туган җирнең җаны булса,*

*Туган җирнең җаны, әнкәй, ул!*

15. Тәңгәллекне күрсәтегез:

1) *Көндез балан пешкән* **(?)** А) :

*Чуен кебек кара*

*Чуен өйләр тора* (Г. Гыйльманов).

2) *Тау ягына кояш кунган саен* **(?)** Б) тыныш билгесе

*Хыял канатымны кагынам* (Г. Гыйльманов). куелмый

3) *Кеше шулай* **(?)** *үзенең бар гомерен* В) ,

*Булмаганны юрап уздыра* (Ш. Җиһангирова).

4) *Ялыннан урап тотар идем* **(?)** *ялы юк* (Әкият). Г) –

16. Тәңгәллекне күрсәтегез:

1) *Кич җиттеме, өй каршында*

*Бер яшь егет сызгыра* (Ф. Яруллин). А) иярчен рәвеш җөмлә

2) *Минем сөю язгы таллар кебек:*

*Һәрбер хисем бөре шикелле* (Г. Гыйльманов). Б) иярчен ия җөмлә

3) *Тагын шунысы бар: тау эчендә авыл*

*булалмый* (Г. Гыйльманов). В) иярчен шарт җөмлә

4) *Әтәчләр, гомердә йоклатмыйбыз без*

*сине дигәндәй, узыша-узыша кычкыралар*

(Г. Нәбиуллин). Г) иярчен аныклагыч җөмлә

17. Текстны укыгыз һәм биремнәрне үтәгез:

(1) ... *Гомерне ярты-йорты яшәп була, әмма аны ике мәртәбә яшәп булмый.*

(2) ... *Кешегә гомер бүләк итеп түгел, бурыч итеп бирелә.* (3) *Сәүбәнгә дә бурычын түләргә күптән вакыт, ә ул һаман бурыч җыеп йөри...*

(4) ... *Гомер газап та түгел, ләззәт тә түгел.* (5) *Гомер – олы эш; Сәүбән аны намус белән башкарырга һәм ахырына җиткерергә тиеш!..*

(6) ... *Гомер үткән көннәр түгел, гомер ул – истә калган көннәр...* (7) *Сәүбән гомере – үткән көннәр генә, ахры...*

(8) *Гомер, бер бөртек тә чәчелмичә, җыелып бара.* (9) *Сәүбән, үз хәтереннән ни дә булса алып атырга теләсә дә, булдыра алмас иде...*

(10) *Кеше үзгәрмәскә мөмкин, әмма ул яхшырак була ала.* (11) *Кеше үзен күпмегә бәяли, ул шулкадәр тора.* (12) *Кеше үзен яратырга мәҗбүр итә алмый, әмма хөрмәтләргә мәҗбүр итә ала* (Г. Гыйльманов).

1. Инкяр җөмләләрдән генә торган рәтне билгеләгез:
   1) 1, 2, 3, 4, 9

   2) 1, 4, 9

   3) 1, 2, 4, 6, 9, 10, 12

   4) 1, 2, 4, 6, 8, 9, 10, 12

2. Тезмә кушма җөмләләрдән генә торган рәтне билгеләгез:
1) 3, 5, 6, 10

2) 1, 3, 5, 6, 10

3) 3, 5, 6, 9, 10

4) 3, 5, 6, 10, 11, 12

3. Иярченле кушма җөмләләрдән генә торган рәтне билгеләгез:
1) 5, 6, 9, 11

2) 5, 6, 9, 10, 11

3) 5, 6, 9, 10, 11, 12

4) 11

4. Кереш сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез:
1) *әмма*

2) *ахры*

3) *әмма, тиеш, ахры*

4) *ахры, күпмегә – шулкадәр*

5. Исем хәбәрләрдән генә торган рәтне билгеләгез:
1) *газап түгел, ләззәт түгел, эш, көннәр түгел, көннәр, көннәр генә*

2) *газап түгел, ләззәт түгел, эш, үткән көннәр түгел, истә калган көннәр, көннәр генә*

3) *газап түгел, ләззәт түгел, олы эш, көннәр түгел, көннәр, көннәр генә*

4) *газап түгел, ләззәт түгел, эш, көннәр түгел, көннәр, көннәр генә, яхшырак була ала*

6. 9 җөмлә ул –
   1) раслау, хикәя, җәенке, ике составлы, тулы
   2) раслау, хикәя, җәенке, бер составлы, тулы
   3) инкяр, хикәя, җәенке, ике составлы, тулы
   4) иярченле кушма җөмлә

**11.8. Презентация № 1.**

**11.9. Презентация № 2.**

**12.**
**Лекция № 10**

- **Катлаулы кушма җөмлә төрләре: күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә, күп иярченле катлаулы кушма җөмлә, катнаш кушма җөмлә.**

**Аңлатма.** Әлеге тема катлаулы кушма җөмләләрнең төрләре турында аңлатма бирә.

- **Иң мөһим төшенчәләр.** Катлаулы кушма җөмлә, күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә, күп иярченле катлаулы кушма җөмлә, катнаш кушма җөмлә.

**Методик киңәшләр.**

•Тема теоретик мәгълүматны үз эченә алган лекциядән гыйбарәт;

•Мөстәкыйль эш өчен гамәли биремнәр тәкъдим ителә;

•Теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү максатыннан, теоретик сораулар бирелә.

•Лекция презентация белән үрелеп бара.

## 12.1. Катлаулы кушма җөмлә төрләре: күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә, күп иярченле катлаулы кушма җөмлә, катнаш кушма җөмлә.

Икедән артык җөмләдән торган кушма җөмлә **катлаулы кушма җөмлә** дип атала.

Катлаулы кушма җөмлә төзелеше буенча өч төргә бүленә: күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә, күп иярченле катлаулы кушма җөмлә, катнаш кушма җөмлә.

Күп тезмәле һәм катнаш кушма җөмләләрне яңадан эре төркемнәргә аермыйлар, ә күп иярченле катлаулы кушма җөмлә тагын дүрт төргә бүленә: 1) тиңдәш түгел иярүле, 2) тиңдәш иярүле, 3) бер-бер артлы иярүле, 4) берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләләр.



### Күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә

Өч яки аннан артык җөмлә үзара тезүле бәйләнешкә керә икән, мондый төзелмә **күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә** дип атала.

*(1) Тиздән кичке тынлык иңәр, (2) көн сүнәр, (3) артыннан ук төн килер* ... (Ә. Еники). *(1) Бу минутта аның йөрәген гүя ялкын ялмап алган, (2) күңелен яшьлек хәтирәләре әсир иткән, (3) хәтере үзен беренче тапкыр озата килгән Хәмитне терелткән иде* (Н. Хәсәнов).

Бу төр катлаулы кушма җөмләне берничәгә бүлеп карарга мөмкин.

**1. Барлык компонентлары тезү интонациясе ярдәмендә генә бәйләнешкә керә.**

*(1) Каршыдан ачы җил исә, (2) өстән юеш кар ява, (3) аяк асты – бозлавык* (Ш. Хөсәенов). *(1) Авыл янында гына инеш бар, (2) ай яктысы астында инеш суы елкылдап-елкылдап китә; (3) бөтен җир, тын гына яшәп, тавышсыз җырлап тора* (Ф. Хөсни). *(1) Кояш баеп килә, (2) аның соңгы кызгылт шәүләләре диңгез өстенә төшкән, (3) диңгез өсте тыныч иде* (Ф. Кәрими).

**2. Компонентлары үзара теркәгечләр белән генә бәйләнешкә керә.**

*(1) Төшендә Хәлимне әнисе чакыра, (2)* ***ә*** *Хәлим аннан кача, (3)* ***ләкин*** *аны тотып китерәләр* (И. Гази). *(1) Яңгыр явып үтә (2)* ***дә****, ялтырап, кояш чыга, (3)* ***ләкин*** *салкын җил һаман туктамый* (И. Гази).

**3. Компонентларны бәйләүдә тезү интонациясе дә, тезүче теркәгечләр дә катнаша.**

*(1) Аның әле чәчләре дә кибеп өлгермәгән, (2) ике бите уттай яна, күз төпләре сөремләнеп уелган, (3)* ***ә*** *тыгыз сылу гәүдәсеннән дымлы хуш ис аңкып тора.*

### Күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

Аерым җөмләләре бары ияртү юлы белән генә бәйләнгән җөмләләрнең үзләрен дүрт төргә бүләргә мөмкин.

**1. Тиңдәш ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә**. Ике яки икедән артык иярчен җөмлә бер баш җөмләгә ияреп килеп, ул җөмләләр үзара тиңдәш булсалар, мондый җөмләләр **тиңдәш ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә** дип атала. Мәсәлән:

*(1) Таң җилләре искәндә,*

*(2) Үләнгә чык төшкәндә,*

*(3) Чулпан кызым, таң йолдызым,*

*Чабып сиңа кайтыр идем,*

*(4) Гөлләр хуш ис сипкәндә* (М. Җәлил).




*(1) Тимергалиев синоптиклардан сорашып белде: (2) ел яңгырлы киләчәк, (3) кояшлы көннәр аз булыр* (Г. А.).




**2. Тиңдәш түгел ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә**.

Ике яки икедән артык иярчен җөмлә бер баш җөмләгә ияреп килә, һәм ул иярчен җөмләләр үзара тиңдәш булмый.

*(1) Быел игеннәр бик уңган булса да, (2) көннәр коры булу сәбәпле, (3) ялан эше үз вакытында тәмам булды* (Г. Ибраһимов).




*(1) <u>Каләме</u> <u>үткен</u> (2) <u>кеше</u> (3) <u>кылычы</u> <u>үткенне</u> (2) <u>җиңә</u>* (Мәкаль).




**3. Бер-бер артлы ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә**. Күп иярченле кушма җөмләдә иярчен җөмләләр турыдан-туры бер баш җөмләгә түгел, бәлки үзара берсе икенчесенә (мәсәлән, икенчесе беренчесенә, өченчесе икенчесенә, дүртенчесе өченчесенә һ.б.) ияреп килсәләр, андый ияргүне **дәрәҗәле** яки **бер-бер артлы ияргү** диләр. Шулай итеп, бу төр күп иярченле кушма җөмләдә баш җөмлә дә, иярчен җөмлә дә берничә була, шулай ук бер үк җөмлә берсенә карата баш булса, икенчесенә карата иярчен була. Мәсәлән:

*(1) Беренче кар төшәр алдыннан, (2) бер ир бала дөньяга килгәч, (3) икесенең дә башлары күккә тиде* (И. Гази).




*(1) Тик үзенең начар бер гадәте бар: (2) кайчан тәмле әйбер пешәр икән дип, (3) сагалап кына йөри* (Г. Ибраһимов).




*(1) Һава шундый эссе, шундый бөркү, (2) әйтерсең, (3) яңа гына ипи пешеп чыккан (2) мич авызында торасың* (Р. М.).



**4. Берничә төр ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.** Билгеле, күп иярченле кушма җөмләләр бу өч төргә генә сыеп бетә алмыйлар, аларның берничә төре бергә кулланылу очраклары да бар. Мәсәлән, *(1) Бу трагедия үткәнгә, (2) хәзер инде байтак еллар кичте, (3) шулай да эзе һаман тирән иде әле: (4) дошманнар, (5) һәр сүз чыккан саен, (4) мыскыл итеп телгә алалар* (Г. Ибраһимов). дигән мисалда дәрәҗәле ияргү дә, тиңдәш түгел ияргү дә бар. Шулай итеп, бу җөмләдә тиңдәш ияргү дә, бер-бер артлы (дәрәҗәле) ияргү дә бар, шуңа күрә мондый җөмләләрне **берничә төр ияргүле күп иярченле кушма җөмлә** дип атыйлар




*(1) Шундый тәртип монда: (2) акылы барның*

*(3) Балта белән башын чабалар,*

*(4) Ишекләре бикле килеш (5) яна*

*Карт аналар, бала-чагалар* (М. Җәлил).




**Катнаш кушма җөмлә**

**Бу төр кушма җөмләләрнең төп үзенчәлекләре**. Катлаулы кушма җөмләдәге аерым җөмләләрнең бер төрләре үзара ияртүле юл белән бәйләнеп, икенче төрләре тезүле юл белән бәйләнсәләр, андый җөмлә **катнаш кушма җөмлә** дип атала. Катнаш кушма җөмләдә, кагыйдә буларак, баш җөмләләр үзара тезүле юл белән бәйләнәләр. Әгәр бер баш җөмләгә ияргән тиңдәш иярчен җөмләләр булса, ягъни иярчен җөмләләр тезүле юл белән бәйләнсәләр, андый җөмлә катнаш кушма җөмлә булмый, бәлки күп иярченле кушма җөмләгә керә.

Катнаш кушма җөмләләр төрлечә төзелергә мөмкин.

1. Берничә җөмлә үзара тезүле юл белән бәйләнеп, аларның берсенә ияргән бер яки берничә иярчен җөмлә була. Мәсәлән: *(1) Малай бик комачаулый башласа, (2) Галиулла аңа зур яшел чикерткә тотып бирә, (3) чикерткәне икәүләп камылга арканлап куялар* (Г. Ибраһимов).




2. Үзара тезүле юл белән бәйләнгән җөмләләрнең һәрберсенә караган иярчен җөмләләре булырга мөмкин. Мәсәлән:

*(1) Килсә дә үлем, (2) галим үлми һаман,*

*(3) Үлеме килгәнче ук, (4) үлә надан.*




3. Үзара тезүле юл белән бәйләнгән җөмләләрнең барысына да берьюлы караган иярчен җөмлә була: *(1) Таң алды шундый ягымлы, (2) таң нурлары шундый нәфис һәм куанычлы тирбәнәләр иде ки, (3) күңел иң кадерле, иң татлы уйларга тартыла* (Г. Бәширов).




**12.2. Гамәли биремнәр.**

**1 бирем.** Җөмләләрне укыгыз һәм схемасын сызыгыз.

1. *Йөри-йөри күңеле тупасланса,*
*Тузан кунса яшьлек хисенә,*

*Бер сафланып алыр өчен тагын*

*Туган ягы кирәк кешегә* (Фәнис Яруллин).

2. *Йөрәкләре бергә типмәсә дә,*
*Парлашалар күпме ялгызлар,*

*Шуңа арабызда меңәрләгән*

*Парлы булып йөргән парсыз бар* (Зөһрә Шакирова).

3. *Иртән чыксам, күзләр камаша:*
*Мамык карлар җирне каплаган* (Шәүкәт Галиев).

4. *Җилләр йошак, таңнар якты, офыклар киң,*

*Чөнки бит сез сөясез һәм сөеләсез* (Фәнис Яруллин).

5. *Үкенмәмен җирдән китүемә,*

*Үземнән соң миннән әйбәтрәк*

*Балаларым калса,*

*Җан дусларым килеп каберемә*

*Бер уч туфрак салса...* (Шәмсия Җиһангирова).

6. *Дөньялыкта усал җилләр уйный, һавада кара болытлар йөзә, йолдызлар тоныклана, кошлар кыяга бәрелеп үлә, сулар агулана, язмышлар иясез кала, кешеләр адаша...* (Галимҗан Гыйльманов).

**2 бирем.** Җөмләләрне укыгыз һәм схемасын сызыгыз.

1. *Син киләсе юлдан*
*Кара мәче – кара төн уза,*

*Ә мин һаман күктән кояш көтәм,*

*Ә мин һаман көтәм могҗиза* (Рәзил Вәлиев).

2. *Күтәрелә барган саен сулышы ешаеп, адымнары әкренәйделәр аның* (Габдрахман Минский).

3. *Иң аянычлысы шунда: явыз җаннар белән бергә әйбәт кешеләр дә, изге җаннар да һәлакәткә очрыйлар, хөрмәткә, ихтирамга лаек ил агалары да, бер гөнаһсыз сабый балалар да үлемгә дучар ителәләр...* (Галимҗан Гыйльманов).

4. *Йөрәк теләсә кемгә ачылмый, йөрәккә ярату ачкычы яратып булмый, йөрәккә ярату ачкычы кирәк: йөрәкне яратып кына ачып була* (Марсель Галиев).

5. *Дуслар белән күрешкәндә,*

*Егыла-егыла көлешкәндә,*

*Шатлыкларны бүлешкәндә,*

*Әгәр кинәт күңелем тулса,*

*Күзләремдә яшьләр булса,*

*Тиргәмәгез,*

*Кичерегез!* (Фәнис Яруллин).

6. *Алда таулар очраганда,*

*Янда терәк булмаганда,*

*Эшләрем дә уңмаганда,*

*Әгәр кинәт җебеп төшсәм,*

*Чылансалар күзләр яшьтән –*

*Бер тиргәгез,*

*Кичермәгез!* (Фәнис Яруллин).

## 12.3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар.

1. Катлаулы кушма җөмлә нинди җөмлә ул?
2. Ике компонентлы кушма җөмлә белән катлаулы кушма җөмлә бер-берсеннән ничек аерыла?
3. Катлаулы кушма җөмлә нинди төрләргә бүленә?
4. Күп тезмәле катлаулы кушма җөмләнең төп үзенчәлекләре нидән гыйбарәт?
5. Күп иярченле катлаулы кушма җөмләнең үзенчәлеге нидә?
6. Күп иярченле катлаулы кушма җөмлә нинди төрләргә аерыла?
7. Тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләгә билгеләмә бирегез һәм мисал китерегез.
8. Тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләгә билгеләмә бирегез һәм мисал китерегез.

9. Бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләгә билгеләмә бирегез һәм мисал китерегез.

10. Берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләгә билгеләмә бирегез һәм мисал китерегез.

11. Нинди җөмләне катнаш кушма җөмлә дип атыйлар, мисал китерегез.

**12.4. Презентация.**

**13.**
**Лекция № 11**

- **Текст. Пунктуация.**

**Аңлатма.** Әлеге тема текст һәм тыныш билгеләрен дөрес кую кагыйдәләре турында аңлатма бирә.

- **Иң мөһим төшенчәләр.** Текст, диалог, туры һәм кыек сөйләм, уртак, чит сөйләм, автор сөйләме, өтер, нокта, сызык, ике нокта.

**Методик киңәшләр.**

- Тема теоретик мәгълүматны үз эченә алган лекциядән гыйбарәт;
- Мөстәкыйль эш өчен гамәли биремнәр тәкъдим ителә;
- Теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү максатыннан, теоретик сораулар, мөстәкыйль эш биремнәре һәм тест бирелә.

**13.1. Текст. Пунктуация.**

Тоташ сөйләмне, ягъни текстны синтаксик өйрәнү рус һәм чит ил лингвистикаларында 60 нчы, 70 нче елларда бик нык киңәеп һәм тирәнәеп китә. Өйрәнү өчен алынган, күп яктан бөтен тоташ сөйләм **текст** дип атала.

Татар синтаксисында текст турында төп мәгълүматларны М.З. Зәкиевнең 1974 нче елда чыккан «Хәзерге татар әдәби теле (синтаксис) дигән китабыннан алырга мөмкин. Анда «Синтаксик бөтеннәр» исеме белән текстта мөстәкыйль җөмләләрнең мәгънә һәм төзелеш ягыннан бәйләнеше, грамматик бәйләнеше өйрәнелә (257-263 б.). 1984 нче елда чыккан «Хәзерге татар әдәби теле синтаксисы һәм пунктуациясе» китабында М.З. Зәкиев татар текстының төрләрен һәм аның бөтенлеге проблемаларын тикшерә (199-211 б.). Текст синтаксисы эчендә автор тезем, чит сөйләм мәсьәләләрен дә ачыклый (212-226 б.).

1993 нче елда Ф.С. Сафиуллина «Текст төзелеше» дигән махсус китап чыгара һәм текстның күп проблемаларын бик бай мисаллар ярдәмендә аңлата.

1992 нче, 1995 нче елларда татар теленең академик синтаксисында да текст синтаксисы турында мәгълүмат бирелә.

Текстны өйрәнгәндә, аның чикләрен билгеләү мөһим. Зур әсәрләрнең аерым бүлекләре, кыскарак хикәя, нәсерләр, аерым мәкаләләр, гариза, белешмә, беркетмә һ.б. алына һәм текст дип йөртелә. Зур күләмле текст **макротекст** була, ә кечкенә күләмлесе **микротекст**.

Текст эчтәлек ягыннан бербөтен төзергә тиеш, ягъни андагы мөстәкыйль җөмләләр бер уртак теманы ачуга ярдәм итәләр. Бу уртак тема текстның **мәгънәви үзәге** була. Аралашканда, сөйләүченең фикере тыңлаучыга җиңелрәк, тулырак аңлашылсын өчен, тексттагы җөмләләр арасында мәгънәви яктан логик эзлеклелек булырга тиеш. Ул текстның **коммуникатив бөтенлеге** дип атала.

Текст мәгънәви һәм коммуникатив бөтен тәшкил итә, ягъни текст эчендәге мөстәкыйль җөмләләр мәгънәви яктан бер теманы ачалар, ләкин логик яктан эзлекле итеп. Текстның шундый бөтенлеге андагы мөстәкыйль җөмләләр структурасында чагылыш таба. Бер тоташ текст тәшкил итә торган мөстәкыйль җөмләләрнең һәрберсенә дә карый торган уртак кисәк була. Әлеге уртак кисәк гел кабатланып, беренче һәм соңгы җөмләдә кабатланып, беренче җөмләдә килеп, калганнарында алмашлыклар белән алмашынып бара ала.

Текстның **грамматик бөтенлеге** ул тексттагы мөстәкыйль җөмләләрнең, абзацларның грамматик чаралар белән бәйләнүе (тезүче теркәгечләр, иярүче теркәгечләр, ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр, көттерү паузасы).

Текстның билгеле бер эзлеклелектәге план белән оештырылуы **текстның композициясе** дип атала.

**Тезем**

Тиңдәш кисәкләре яки тиңдәш җөмләләре күп булу аркасында, бик нык җәенкеләнгән гади яки кушма җөмлә **тезем** дип атала. Теземдә санау бүлеге һәм төп бүлек була. **Төшмә теземдә** иң элек санау бүлеге, аннан соң төп бүлек килә. **Күтәрелмә теземдә** иң элек төп бүлек, аннан соң күтәрелә бара торган интонация белән санау бүлеге әйтелә.

Санау бүлеге ияләрдән яки ия җөмләләрдән торса, тезем **ия тезем** дип атала. **Хәбәр, шарт, кире, вакыт, урын, рәвеш, сәбәп, максат, тәмамлык, аергыч, аныклагыч теземнәр** була. Санау бүлеге төп бүлеккә тезү юлы белән бәйләнгән булса, тезем **тезүле тезем** дип атала. Санау бүлеге эндәш сүзләрдән торса, **эндәш тезем** була.

Мисалларга күз салыйк:

*Кеше бит ул бер учак:*

*Утынын сала торсаң,*

*Көлләрен ала торсаң,*

*Бераз кузгатып куйсаң,*

*Утын уятып куйсаң,*

*Давылдан саклый алсаң,*

*Явымнан каплый алсаң,*

*Сүнгәндә өргәләсәң,*

*Яңа көч биргәләсәң,*

*Күмерен таратмасаң,*

*Урынын яңартмасаң,*

*Таш белән бастырмасаң,*

*Боз белән катырмасаң,*

*Ялкыннарын үрләтсәң,*

*Күмерләрен дөрләтсәң –*

*Бу учак*

*Озак-озак яначак* (Ф. Яруллин “озак-озак яначак”).

*Күк күкрәүләр,*

*Җир тетрәүләр,*

*Су ташулар,*

*Су басулар,*

*Батулар һәм*

*Атулар...*

*Тик фактлар:*

*Терактлар,*

*Норд-Остлар,*

*Блокпостлар,*

*Триллерлар,*

*Киллерлар,*

*Бандитлар һәм*

*Вампирлар...*

*Афәтләр,*

*Ураганнар,*

*Талаганнар,*

*Урлаганнар...*

*Түзәбез әле*

*Әле дә ...*

*Әлегә!* (Р. Миңнуллин “Телевизор караганда”).

**Чит сөйләмле текст**

Текст эченә кергән башка кеше сүзләре **чит сөйләм** дип атала. Чит сөйләмле текст ике өлешкә бүленә: чит сөйләм һәм автор сөйләме. Чит сөйләм өч төрле формада – туры сөйләм, кыек сөйләм һәм уртак сөйләм формаларында бирелә.

Үзгәртелмичә кулланылган чит сөйләм **туры сөйләм** дип атала. Туры сөйләм диалог, монолог, цитата дигән төрләргә бүленә. Ике яки берничә кешенең үзара сөйләшүе формасында бирелгән туры сөйләм **диалог** дип исемләнә. Диалог эчендә аерым кеше сүзләре **реплика** була, алар мөмкин кадәр ким булалар. Персонажның үз-үзенә, башка берәүгә яисә халыкка мөрәҗәгать ителгән сөйләме **монолог** дип атала. Язма әсәрләрдән алынган туры сөйләм **цитата** дип атла.

Үзгәртелеп кулланылган чит сөйләм **кыек сөйләм** дип атала.

Уртак сөйләм автор һәм персонаж өчен уртак, ягъни уртак сөйләмне автор да, персонаж да әйтә булып чыга.

**Пунктуация**

Тыныш билгеләрен кую турындагы кагыйдәләр җыелмасы **пунктуация** дип атала.

XX йөзнең 10 нчы елларына кадәр татар язма әдәби телендә тыныш билгеләрен кую кагыйдәләре эшләнмәгән була. Язма телне системалы рәвештә яшь буынга укыту барлыкка килгәч, әкренләп тыныш билгеләрен дә тәртипкә китерә башлыйлар. Татар язуында тыныш билгеләрен кую кагыйдәләре рус теле пунктуациясе йогынтысында эшләнә.

1905-1907 нче елгы рус революциясеннән соң татар мәктәпләре арта, ана теле аерым предмет буларак укытыла башлый, дәреслекләр бастырыла. Шул чорда тыныш билгеләре куюның кайбер кагыйдәләре эшләнә. Монда Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди, Ф. Сәйфи-Казанлы һ.б. ның өлешләре күп керә.

Октябрь революциясеннән соң дәүләт хисабына эшли торган мәктәпләрдә яшь буынга ана телендә белем бирү гомуми төс ала, яңа грамматикалар кирәк була. Дөрес язу, тыныш билгеләрен дөрес кую, ягъни язма тел культурасы иҗтимагый күренешкә әйләнә. Беренче кагыйдәләр күренә. М. Корбангалиев, Х. Бәдигый «Ана теле нәхүе» (1919) дәреслеген бастыра, тыныш билгеләре күрсәтелә. 1956 нчы елда К. Сабиров тыныш билгеләрен кую юлларын махсус тикшереп, монография бастыра. М.З. Зәкиев үз хезмәтләрендә әлеге мәсьәләне гел яктыртып бара. 1985 нче, 1995 нче елларда Ф.С. Сафиуллина, С.М. Ибраһимов, Э.Х. Вафина «Татар телендә тыныш билгеләре. Белешмә» дигән китап-брошюра чыгаралар.

Тыныш билгеләренә түбәндәгеләр керә:

1. Кызыл юл
2. Нокта
3. Өндәү билгесе
4. Сорау билгесе
5. Өтер
6. Нокталы өтер
7. Күп нокталар
8. Ике нокта
9. Сызык
10. Җәяләр
11. Куштырнаклар

### 13.2. Гамәли биремнәр.

**1 нче бирем.** Җөмләләргә тиешле тыныш билгеләрен куеп чыгыгыз.

1. *Без өйгә кайтып кергәндә кояш баеп бара иде инде* (М. Гафури).

2. *Төн буе буран котырганга юл бик начар иде* (И. Гази).

3. *Ул үзенең егетләре белән урманга килеп җиткәндә урман авызында аны шул ук Гыйльметдин каршы алды* (И. Гази).

4. *Ае юк төннең йолдызлары болытларга күмелгән* (Һ. Такташ).

5. *Аптырап Хәлимә ягына борылсам кыздан җилләр искән* (Ф. Шәфигуллин).

6. *Кайчагында аның күңеле күз яшьләре чыгарлык дәрәҗәдә аеруча бер җилкенү белән дулкынлана башлый* (Г. Бәширов).

7. *Урман каравылчысы түбәдән кар ишелгән шикелле тавыш белән дөбердәтеп көлде* (М. Галиев).

8. *Зөһрә ханым минем белән бергә китергә риза булгач күңелемне аеруча бер рух күтәренкелеге биләп алган иде* (Ә. Еники).

9. *Дөнья киңлегеннән ни файда аяк киемең тар булса?* (Мәкаль).

10. *Үзеңне әдәбият чаклы әдәбияттан халык рухының көзгесе булган әдәбияттан өстен куярга азаплану бераүне дә бизәми минемчә* (Г. Ахунов).

**2 нче бирем.** Тиешле тыныш билгеләрен куеп, баш кисәкләрнең асларына сызыгыз, җөмлә чикләрен билгеләгез.

1. *Хөрмәт итәм дусларымны*

*Гел үзгәреп торсалар да* (М. Әгъләмов).

2. *Аяк тавышы ишетелгән саен тәрәзә пәрдәсен күтәреп урамны күзәтте* (А. Гыйләҗев).

3. *Күңелең сөймәгән кешедән ярдәм сорама* (Мәкаль).

4. *Чартлап торган таш өстенә су килеп төшү белән мунча ишеге шартлап ачылып китте* (Батулла).

5. *Мин агачлар ышыгында утырган таныш өй янына килеп җиткәндә яңгыр туктаган иде инде* (М. Галиев).

6. *Танышы күрми калмасын дип аягүрә басты күңеллеләнеп ияген сыйпап куйды* (Г. Бәширов).

7. *Бүре толыбы бар кеше юлдашының туңганын белмәс* (Мәкаль)

8. *Беренче кыңгырау чылтыраса да класска керергә уйлап та караган кеше юк* (М. Мәһдиев).

**3 нче бирем.** Баш җөмләдән өтер белән аерылган синтетик иярчен җөмләләрнең урыннарын өтер куелмый торган итеп үзгәртеп языгыз.

1. *Кояш түбәнәйгән саен, эскертләр биегәя бара* (Ф. Яруллин).

2. *Ул кереп киткәч тә, звонок булды* (М. Мәһдиев).

3. *Сугыш башлану белән, Низамны фронтка алып киткәннәр* (Х. Сарьян).

4. *Аягы аксак булу сәбәпле, сугышка китми калган* (Г. Ахунов).

5. *Чүлләрдә сусаган кеше чишмәгә ташлангандай, Фәнияр китапка ташланды* (Ф. Яруллин).

6. *Дуслар ишәйсә, дошман калтырый* (Мәкаль).

**4 нче бирем.** Икешәрләп бирелгән җөмләләрдән синтетик иярчен җөмләле кушма җөмләләр төзегез. Бер очракта синтетик җөмлә баш җөмләдән өтер белән аерылсын, икенче очракта өтер белән аерылмый торган булсын.

*Үрнәк: Яз җитте. Карлар эреде. – 1) Яз җиткәч, карлар эреде. 2) Карлар яз җиткәч эреде.*

1. *Укытучы бишле куйды. Алсу шатланды.*

2. *Әни кайтсын. Балалар җиләк җыярга барырлар иде.*

3. *Урамда машина тавышы ишетелде. Картлар тиз генә чыгып бастылар.*

4. *Укучылар укыганнар. Китапларны укытучы китапханәгә тапшырды.*

**5 нче бирем.** Җөмләләргә синтаксик анализ ясагыз.

1. *Гашыйклар әллә кавыша микән*

*Ай белән Кояш кавышкан чакта?* (Р. Вәлиев).

2. *Ишек ачылган саен, трамвайга зәһәр салкын ургылып керә* (Г. Гыйльманов).

3. *Иртәләрен күлләр, сулыклар юка гына элпә белән капланса да, төшкелеккә көзнең тыйнак кояшы әлеге серле җәймәне шундук ялап та ала...* (Г. Гыйльманов).

4. *Кояш кыздырырга тотындымы – сарыкның мае парга әйләнә башлый* (М. Галәү).

5. *Шәйхәттәр бабагыз үткәннәрне бик яхшы хәтерли, гүя аның хәтере моннан күп еллар элек борып туктатылган да шуннан бирле бер тапкыр да яңадан җибәрелмәгән* (И. Гази).

6. *Беренче сыйныфта гына укыса да, Зөһрә укытучы биргән сорауларга дөрес һәм төгәл итеп җавап бирергә кирәклеген белә* (Г. Гыйльманов).

7. *Бердәнбер аерма шундадыр: ул күп, бик күп уйлана торган булып китте* (Г. Гыйльманов).

8. *Кич җиттеме, өй каршында*

*Бер яшь егет сызгыра* (Ф. Яруллин).

9. *Син белеп тор: икебезнең*

*Мәхәббәттән башка*

*Әйләнермен мин тимергә*

*Йә булмаса ташка* (Р. Миңнуллин).

10. *Иптәш сүзе инде искерсә дә,*

*Иңдәш сүзе мәңге искермәс* (Ф. Яруллин).

**6 нчы бирем.** Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз, төрләрен билгеләгез. Җөмләләргә билгеләмә бирегез. Текстка хас үзенчәлекләрне санагыз.

*Бөтен бер гомер*

*Ояга сыерчык килеп кунды. Тәпиендә - балдак. Таныш сыерчык. Алтынчы ел инде мин ясаган ояда яши ул.*

*Яз саен оясына очып килә дә аны һәряклап күзәтә, эченә керә, сайрый. Әкрен генә, ләкин рәхәтләнеп сайрый. Уенга бирелеп киткән дуңгыз баласыдай, куанычыннан хәтта чинап та җибәрә. Алтын томшыгы күккә караган, күзләре зуп-зур булып ачылган, як-якка җәелгән. Ә үзе я әтәч булып кычкыра, я мәче булып мияулый, я чәңгелдәп җибәрә. Чит җирләрдә яшәп оясын сагынган ул...*

*Аннары, ана сыерчык белән бергәләп, оя чистарталар, бала чыгаралар. Балаларын икәү үстерәләр, бергәләп, көтүлеккә очып китәләр.*

*Көзен, җылы якка китәр алдыннан, ата сыерчык оясына ялгызы гына очып килә. Сыерчыкларда китәр алдыннан ояларына кагылу гадәте бар. Бераз тын гына утырып тора ул, кояшта каурыйларын чистарта, җырлап ала. Аннары – көньякка. Еракка – чит җирләргә, офык артына китә.*

*Ләкин яз җитү белән үк, сыерчыгым тагын биредә. Оя башына утыра да, канатларын җилпеп, рәхәтләнеп сайрый. Ә тәпиендә балдак ялтырый. Алты ел инде шулай.*

*...Язын алты тапкыр "Исәнме!" дип әйттем, көзен биш мәртәбә "Сау бул!" дип озатып калдым мин аны.*

*Ләкин бервакыт сыерчыгымның картаюын сизә башладым.*

*Әле дә хәтердә: беренче язны ул бар тәне белән калтыранып җырлады! Муен каурыйлары үрә торалар иде. Май сөрткәндәй, бөтен гәүдәсе ялык-йолык килде.*

*Ә алтынчы язны... карыйм һәм үз күзләремә үзем ышанмыйм. Оя тишегендә утыра бу, борыны аска салынган. Теләр-теләмәс сайрый ул: сызгырып ала да тынып кала, сызгыра да тагын туктый. Үз тавышын үзе тыңлый кебек.*

*Сайрады-сайрады да, кыза башлагач кына, йокымсырап та китте! Башын түбән иде, утырган килеш черем итә башлады. Аның әле бервакытта да болай булганы юк иде.*

*Ә алтынчы көзне буш ояга бер генә тапкыр очып килде ул. Тын гына утырды, тәпиендәге балдакны капшап карады.*

*- Сау бул! – дидем мин аңа. Алтынчы тапкыр "Сау бул!" дидем.*

*Менә кыш та үтте. Ояга тагын бер сыерчык очып килде. Ләкин монысы минеке түгел иде инде, тәпиендә балдагы юк иде. Бәлки, күршеседер, ә бәлки, улыдыр. Үзе яшь, үзе каты тавышлы. Тиктормас бер кошчык. Майлагандай елкылдап тора җитмәсә.*

*Карт сыерчык бүтән күренмәде. Хуш, карт сыерчык! Ахыргы тапкыр хуш. Исәнме, яшь сыерчык, беренче тапкыр исәнме!* (Н. Сладков).

**13. 3. Белемнәрне тикшерү өчен сораулар.**

1. Текст нәрсә ул?
2. Нәрсә ул микротест һәм макротекст?
3. Текстның бөтенлеген кайсы яклардан чыгып билгелиләр?
4. Текстның мәгънәви бөтенлеген ничек аңлыйсыз?
5. Нәрсә ул текстның структур бөтенлеге?
6. Нәрсә ул текстның грамматик бөтенлеге?
7. Текст композициясен ничек аңлыйсыз?
8. Нәрсә ул тезем?
9. Теземнең нинди төрләре бар?
10. Нинди сөйләмгә чит сөйләм диләр?
11. Туры сөйләмнең төп үзенчәлекләре нидән гыйбарәт?
12. Туры сөйләм һәм автор сөйләме үзара нинди тәртиптә урнашалар?

13. Кыек сөйләм нинди үзенчәлекләр белән характерлана?
14. Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерүнең нинди очраклары бар?
15. Нәрсә ул уртак сөйләм?
16. Нәрсә ул пунктуация?
17. Пунктуациягә караган нинди хезмәтләр беләсез?
18. Кайсы очракта нокталы өтер куела?
19. Ике нокта куелуның нинди кагыйдәләрен беләсез?
20. Сызык кайсы очракларда куела?
21. Җәяләр куелуның нинди кагыйдәләрен беләсез?
22. Кайсы очракта куштырнаклар куела?

## 13.4. Мөстәкыйль эш өчен биремнәр

### 1 вариант

1. Һәр җөмләнең баш кисәкләрен табыгыз, компонентларның чикләрен билгеләгез, схемаларын сызып, тулы билгеләмә бирегез:

1) *Була ич шулай: җырчы җырлап туктаганнан соң да, колак төбендә җыры беравык чыңлап ишетелеп тора...* (И. Гази).

2) *Бәхет-шатлык ташып торса,*

*Дөньялар булса көләч,*

*Күңелең нечкәргән чакта,*

*Аналар белән сөйләш!* (Г. Гыйльманов).

3) *Кемдер шулай миңа ышанадыр,*

*Кемдер шулай сиңа ышанадыр –*

*Мин ышанам шуңа, ышанам!* (Ш. Җиһангирова).

4) *Янәшәдә генә Идел ага,*

*Болыт йөзә күктә агарып,*

*Бер кайгысыз кошлар агачларда*

*Уйный әле һаман шаярып* (Р. Вәлиев).

5) *Ул чәчләргә ак кар кунмаса,*

*Без бәхетле була алмас идек,*

*Без бу чаклы сагынмас та идек,*

*Шул ак чәчләрегез булмаса* (Г. Гыйльманов).

6) *Син утырткан һәрбер чәчәк, үлән*

*Белеп тора әле: син исән!* (Ш. Җиһангирова)

7) *Биек тауга кабат менмәдем мин,*

*Янәшәмдә генә булса да,*

*Еллар үткән саен сөюләрем*

*Ялкынлырак дөрли торса да...* (Ш. Җиһангирова).

2. Түбәндәге шигъри юлларга үз мөнәсәбәтегезне белдереп, гади, ике компонентлы һәм катлаулы кушма җөмләләрдән хикәя төзеп языгыз.

***Иелмәм дип уйлый идем,***

***Бөгелмәм дип уйлый идем,***

***Ләкин тормыш***

***Чишмә булып җирдән акты,***

***Саф суларын эчәр өчен,***

***Иелү генә түгел,***

***Бөгелү генә түгел,***

***Түшләремә яттым*** (Ф.Яруллин).

**2 вариант**

1. Һәр җөмләнең баш кисәкләрен табыгыз, компонентларның чикләрен билгеләгез, схемаларын сызып, тулы билгеләмә бирегез:

1) *Җиргә тагын карлар ява инде,*

*Җир төренә тагын аклыкка,*

*Җир яшерә үзенең гөнаһларын,*

*Җир күмелә сафлык, пакьлеккә* (Р. Вәлиев).

2) *Үкенмәмен җирдән китүемә,*

*Үземнән соң миннән әйбәтрәк*

*Балаларым калса,*

*Җан дусларым килеп каберемә*

*Бер уч туфрак салса...* (Ш. Җиһангирова).

3) *Таң пәрдәсен ачып кояш чыккан чакта,*

*Йөрәгеңә бәхет үрелер,*

*Шатлыкларың җем-җем энҗе чыклар булып,*

*Юлларыңа синең сибелер* (Ш. Җиһангирова).

4) *Алда таулар очраганда,*

*Янда терәк булмаганда,*

*Эшләрем дә уңмаганда,*

*Әгәр кинәт җебеп төшсәм,*

*Чылансалар күзләр яшьтән,*

*Бер тиргәгез,*

*Кичермәгез!* (Ф. Яруллин).

5) *Кояш күтәрелеп, көн шактый кыздыра башлагач кына уяндылар балалар* (К. Әмири).

6) *Бүләк иткән ак шәлемне, әнкәй,*

*Иңнәреңә бер дә япмыйсың,*

*Керләнмәсен диеп, төреп кенә,*

*Иске сандыгыңда саклыйсың* (Ш. Җиһангирова).

7) *Син керсен дип, ишек ачтым –*

*Җилләр керде* (Ф. Яруллин).

2. Түбәндәге шигъри юлларга үз мөнәсәбәтегезне белдереп, гади, ике компонентлы һәм катлаулы кушма җөмләләрдән хикәя төзеп языгыз.

***Үбә-үбә, чәчләреңнән сыйпап,***

***Иркәләми икән куенында,***

***Утларында яндыра да икән,***

***Бозларында тундыра да икән –***

***Әй усал да икән бу дөнья!*** (Ә.Атнабаев).

**13.5. Тест № 11.1.**

**Текстны укыгыз һәм биремнәрне үтәгез**

(1) *Серле тынлык белән ак яктылык кына эленеп тора иде тирә-юньдә.* (2) *Рәхимҗан шулкадәр бәхетле һәм шат иде: ул җир белән күк, болыт белән көрт аермасын онытты.*

(3) *Кинәт каядыр янәшәдә генә колагына серле аваз чалынгандай булды.* (4) *Челтерәү авазы якыная төшкәч кенә, үзенең җирдә булуын, инеш буйлап чишмәгә баруын төшенде.*

(5) *Җылы пар бөркеп, челтерәп агып яткан чишмәне күргәч, таң калды егет.* (6) *Гаҗәпләнмәслек тә түгел: бөтен дөнья – урам һәм тыкрыклар, инеш һәм су буйлары – кар астында йомылып яткан бер мәлдә чишмә күмелмичә калган.* (7) *Нурлы аланлылар үзен күптән онытккан булуга карамастан, чишмә тирән кар катламын ярып чыккан: тибеп тора.*

(8) *Җылынып киткәндәй булды егет, чөнки шаулап аккан салкын чишмә суыннан җылы пар бөркелә иде.* (9) *Егет, билдән карга батып,*

*үргә чана тартып менгәндә дә, урамнардан үткәндә дә, шул җылылык аны озата барды.*

(10) *Иртәгесен тагы су буена төште Рәхимҗан.* (11) *Ак кар өстендә күзгә күренер-күренмәс кенә рәшә йөгерә.* (12) *Никадәр матурлык монда!* (Р.Мөхәммәдиев).

1. 2 нче җөмлә:

1) гади җөмлә

2) аналитик иярчен күләм җөмләле кушма җөмлә

3) синтетик иярчен аергыч җөмләле кушма җөмлә

4) аналитик иярчен аергыч җөмләле кушма җөмлә

2. 6 нчы җөмлә:

1) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

2) бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

3) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

4) иярченле кушма җөмлә

3. 12 нче җөмлә:

1) билгеле үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә

2) бер составлы исем җөмлә

3) билгесез үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә

4) үтәүчесез бер составлы фигыль җөмлә

4. Иярченле кушма җөмләләрдән генә торган рәтне билгеләгез:

1) 2, 4

2) 2, 4, 5, 8, 9

3) 2, 4, 8, 9

4) 2, 4, 7, 8, 9

5. 6 нчы җөмләдә ***урам һәм тыкрыклар, инеш һәм су буйлары*** нинди җөмлә кисәге?

1) тиңдәш ияләр

2) тиңдәш урын хәлләре

3) тиңдәш аныклагычлар

4) тиңдәш исем хәбәрләр

6. Инверсия күренеше чагылыш тапкан җөмләләр рәтен билгеләгез:

1) 1, 10

2) 1, 8, 10, 12

3) 8, 12

4) 1, 8, 12

7. 5 нче җөмләдәге ***таң калды*** хәбәренең төрен билгеләгез:

1) гади исем хәбәр

2) тезмә исем хәбәр

3) кушма исем хәбәр

4) тезмә фигыль хәбәр

8. 7 нче җөмләдә ***тибеп тора*** нинди җөмлә кисәге?

1) кушма фигыль хәбәр

2) аныклагыч

3) өстәлмә

4) инверсияләнгән җөмлә кисәге

9. 9 нчы җөмләдә ***билдән*** нинди җөмлә кисәге?

1) урын хәле

2) кыек тәмамлык

3) туры тәмамлык

4) күләм хәле

10. *Җылы пар бөркеп, челтерәп агып яткан чишмәне күргәч, таң калды егет.* Җөмлә кисәкләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез:

1) *Егет* – гади ия, *таң калды* – тезмә фигыль хәбәр, *күргәч* – сәбәп хәле, *чишмәне* – туры тәмамлык, *агып яткан* – аергыч, *челтерәп* – рәвеш хәле, *бөркеп* – рәвеш хәле, *пар* – туры тәмамлык, *җылы* – аергыч.

2) *Егет* – гади ия, *таң калды* – тезмә исем хәбәр, *күргәч* – вакыт хәле, *чишмәне* – туры тәмамлык, *агып яткан* – кушма фигыль хәбәр, *челтерәп* – рәвеш хәле, *бөркеп* – рәвеш хәле, *пар* – туры тәмамлык, *җылы* – аергыч.

3) *Егет* – гади ия, *таң калды* – кушма фигыль хәбәр, *күргәч* – гади фигыль хәбәр, *чишмәне* – туры тәмамлык, *агып яткан* – кушма фигыль хәбәр, *челтерәп* – гади фигыль хәбәр, *бөркеп* – гади фигыль хәбәр, *пар* – кыек тәмамлык, *җылы* – аергыч.

4) *Егет* – гади ия, *таң калды* – тезмә фигыль хәбәр, *күргәч* – вакыт хәле, *чишмәне* – туры тәмамлык, *агып яткан* – аергыч, *челтерәп* – рәвеш хәле, *бөркеп* – рәвеш хәле, *пар* – туры тәмамлык, *җылы* – аергыч.

### 13.6. Тест № 11.2.

**Текстны укыгыз һәм биремнәрне үтәгез**

(1) *Ә тышта салкын яңгыр ява.*

(2) *Көзге салкын яңгыр, кемгәдер ачулангандай, тәрәзәгә бәрә, әйтерсең лә тышта калган юлчы җылы фатирга кертүеңне үтенә.* (3) *Шык, шык...* (4) *Юк, Газизләрнең тәрәзәсенә яңгыр астында калган юлчы берничек тә шакый алмый: алар биш катлы йортның өченче катында яши.*

(5) *Тәрәзә каршында йорт биеклегендә тирәкләр үсеп утыра, алар җил көченә түзә алмыйча бөгелә, агачларның ботаклары тәрәзәгә кадәр килеп җитә, коелып бетә алмаган яфраклар тәрәзәгә бәрелә.* (6) *Җанны күңелсез уйлар били башлаганчы дип, Газиз тәрәзә яныннан тизрәк китү ягын карады.*

(7) *Яңгыр шыбырдаганы җанга тия, эре тамчылар калай тәрәзә төбенә шулкадәр каты килеп төшә ки, ул гел башка сугып торган кебек шакылдый: тып та тып, тып та тып.*

(8) *Бүген ял көне булгач, Газизнең хатыны Зөлфия иртәдән бирле кухня тирәсендә бөтерелә.* (9) *Оныклар белән балалар килер дип аерата нык тырыша ул.* (10) *Газиз, тыштагы гарасатны күзәтә-күзәтә, хатынының җылы кухняга тизрәк бәлеш ашарга чакырганын көтә.*

(11) *Тамак тәмугка кертә, дисәләр дә, әлеге сүзләр хәзерге яшь буын өчен әйтелмәгән.* (12) *Мондый төксе көндә балалар бәлеш дип җылы фатирларыннан чыкмаячаклар.* (13) *Шулай да өмет дигән нәрсә бар әле* (И.Нәбиуллина).

1. 2 нче җөмлә:

1) гади җөмлә

2) теркәгечле тезмә кушма җөмлә

3) синтетик иярчен рәвеш җөмләле кушма җөмлә

4) аналитик иярчен рәвеш җөмләле кушма җөмлә

2. 5 нчы җөмлә:

1) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

2) бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

3) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

4) күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә

3. 7 нче җөмлә:

1) катнаш кушма җөмлә

2) бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

3) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

4) берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

4. Иярченле кушма җөмләләрдән генә торган рәтне билгеләгез:

1) 2, 4

2) 2, 4, 6, 8, 9, 11

3) 2, 4, 8, 9

4) 2, 4, 6, 8, 9

5. 3 нчы җөмлә ул –

1) өстәлмә

2) рәвеш хәле

3) сүз җөмлә

4) тиңдәш исем хәбәрләр

6. 9 нчы җөмлә ул –

1) синтетик иярчен сәбәп җөмләле кушма җөмлә

2) аналитик иярчен сәбәп җөмләле кушма җөмлә

3) синтетик иярчен максат җөмләле кушма җөмлә

4) синтетик иярчен тәмамлык җөмләле кушма җөмлә

7. 13 нче җөмләдәге ***бар әле*** хәбәренең төрен билгеләгез:

1) гади исем хәбәр

2) кушма фигыль хәбәр

3) кушма исем хәбәр

4) тезмә фигыль хәбәр

8. 8 нче җөмләдә ***Зөлфия*** нинди җөмлә кисәге?

1) гади ия

2) ярашмаган аныклагыч

3) исем хәбәр

4) ярашкан аныклагыч

9. 12 нчы җөмләдә ***бәлеш дип*** нинди җөмлә кисәге?

1) максат хәле

2) кыек тәмамлык

3) туры тәмамлык

4) сәбәп хәле

10. *Газиз, тыштагы гарасатны күзәтә-күзәтә, хатынының җылы кухняга тизрәк бәлеш ашарга чакырганын көтә.*

Җөмлә кисәкләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез:

1) *Газиз* – гади ия, *көтә* – гади фигыль хәбәр, *чакырганын* – туры тәмамлык, *ашарга* – максат хәле, *бәлеш* – туры тәмамлык, *тизрәк* – рәвеш хәле, *кухняга* – урын хәле, *җылы* – аергыч, *хатынының* – кыек тәмамлык, *күзәтә-күзәтә* – рәвеш хәле, *гарасатны* – туры тәмамлык, *тыштагы* – урын хәле

2) *Газиз* – гади ия, *көтә* – гади фигыль хәбәр, *чакырганын* – туры тәмамлык, *ашарга* – максат хәле, *бәлеш* – туры тәмамлык, *тизрәк* – рәвеш хәле, *кухняга* – урын хәле, *җылы* – аергыч, *хатынының* – кыек тәмамлык, *күзәтә-күзәтә* – рәвеш хәле, *гарасатны* – туры тәмамлык, *тыштагы* – аергыч

3) *Газиз* – гади ия, *көтә* – гади фигыль хәбәр, *чакырганын* – туры тәмамлык, *ашарга* – максат хәле, *бәлеш* – туры тәмамлык, *тизрәк* – рәвеш хәле, *кухняга* – урын хәле, *җылы* – аергыч, *хатынының* – аергыч, *күзәтә-күзәтә* – рәвеш хәле, *гарасатны* – туры тәмамлык, *тыштагы* – аергыч

4) *Газиз* – гади ия, *көтә* – гади фигыль хәбәр, *чакырганын* – туры тәмамлык, *ашарга* – туры тәмамлык, *бәлеш* – туры тәмамлык, *тизрәк* – рәвеш хәле, *кухняга* – урын хәле, *җылы* – аергыч, *хатынының* – кыек тәмамлык, *күзәтә-күзәтә* – рәвеш хәле, *гарасатны* – туры тәмамлык, *тыштагы* – аергыч

## 13.7. Тест

## 1 вариант

1. Җөмләнең төрен билгеләгез:

*Китә башласам, газиз әнкәем,*

*Яшь тулы күзең түбән иясең* (Ш. Җиһангирова).

1) гади җөмлә
2) ике компонентлы кушма җөмлә
3) катлаулы кушма җөмлә

2. Җөмләнең төрен билгеләгез:
*Арка сызлаганга түгел, хурлыктан әрнедек без* (А. Шамов).

1) гади җөмлә
2) ике компонентлы кушма җөмлә
3) катлаулы кушма җөмлә

3. Җөмләнең төрен билгеләгез:
*Ул хатыны кая барырга кушса – шунда бара, ни эшләргә боерса – шуны эшли* (Ш. Хөсәенов).

1) гади җөмлә
2) ике компонентлы кушма җөмлә
3) катлаулы кушма җөмлә

4. Җөмләдә компонентларның санын билгеләгез:
*Тау асларыннан ширбәттән дә тәмлерәк, күз яшеннән дә сафрак салкын сулы чишмәләр тибеп чыга; аның хуш исле печәне, билдән ашкан болыннары, колач җитмәс агачлар үскән урманнары, мәһабәт кораблар йөзеп йөри торган киң вә тирән сулы дәрьялары, сихерле көзге шикелле ялтырап яткан күлләре, бар тереклекне иркәләп, лепер-лепер яуган шифалы җылы яңгырлары, таң алдыннан әрәмәлеккә кунып, тирә-якны*

*моңга коендыра, кешенең бөтен җанын эретә торган сайрар кошлары һушыңны алачак!* (Т. Әйди).

1) 3 компонент
2) 4 компонент
3) 5 компонент
4) 7 компонент

5. Җөмләдә компонентларның санын билгеләгез:

*Коңгырт чәчләре тузгып як-якка таралган, кашлары, очарга җыенган кош канаты сыман, өскә талпынган, күзләре – чиксез моң һәм дәрт тулы күзләре – кешеләргә түгел, ә эчкә, үзенең эчке илаһи дөньясына төбәлгән кебек* (Р. Вәлиев).

1) 3 компонент
2) 4 компонент
3) 5 компонент
4) 7 компонент

6. Катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез:

*Каршы искән җил минем озын кара чәчләремне ирегә куа, алар, мин атлаган саен, бер очып китәрдәй булып, күккә күтәреләләр, бер нәүмизләнеп, хәлсезләнеп, минем куеныма, җилкәләремә утыралар* (Ф. Бәйрәмова).

1) күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә
2) күп иярченле катлаулы кушма җөмлә
3) катнаш кушма җөмлә

7. Катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез:

*Кайгыларым җир тетрәве төсле,*

*Сагышларым – гүя ак томан,*

*Чишмәләрем – чиста күз яшьләрем,*

*Ә сүзләрем буран, җил сыман* (Р. Вәлиев).

1) күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә
2) күп иярченле катлаулы кушма җөмлә
3) катнаш кушма җөмлә

8. Катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез:

*Миус үзе болай телгә алып сөйләрлек тирән һәм киң елга булмаса да, аның көнбатыш ярлары шундый текә, шундый биек, күтәрелеп карасаң, башыңдагы пилоткаң очып төшәрлек* (И. Гази).

1) тиңдәш түгел иярүле катлаулы кушма җөмлә
2) бер-бер артлы иярүле катлаулы кушма җөмлә
3) берничә төр иярүле катлаулы кушма җөмлә
4) тиңдәш иярүле катлаулы кушма җөмлә

9. Катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез:

*Зур гына урыс авылының кар басып бетергән өйләрендә һәммәсендә дә утлар сүнеп беткән булса да, авылның очындарак бер өйнең тәрәзәсендә ут яктысы ялтырый иде* (Г. Рәхим).

1) тиңдәш түгел иярүле катлаулы кушма җөмлә
2) бер-бер артлы иярүле катлаулы кушма җөмлә
3) берничә төр иярүле катлаулы кушма җөмлә
4) тиңдәш иярүле катлаулы кушма җөмлә

10. Катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез:

*Газиз карт та, Фатыйма карчык та бик яхшы аңлыйлар: бу авырту түгел, бу – суык, бу – күңелдәге бушлык, бу – югалту, бу – билгесезлек...* (Г. Гыйльманов).

1) тиңдәш түгел иярүле катлаулы кушма җөмлә
2) бер-бер артлы иярүле катлаулы кушма җөмлә
3) берничә төр иярүле катлаулы кушма җөмлә
4) тиңдәш иярүле катлаулы кушма җөмлә

11. Мисаллар арасыннан “артык” җөмләне табыгыз:

1) *Каргышлар барын онытсин,*

*Сагышлар барын оныт* (Ш. Җиһангирова).

2) *Җыр булганга татар теле исән,*

*Моң булганга татар үзе исән!* (Ш. Җиһангирова).

3) *Ил афәттә чакта, шагыйрь – корбан,*

*Ил чирләсә, шагыйрь юталли* (Р. Вәлиев).

4) *Караңгы төшкәч, җил туктады, дөньяны ниндидер шомлы тынлык басты* (Р. Зәйдулла).

11. Мисаллар арасыннан “артык” җөмләне табыгыз:

1) *Өмет бар икән, әгәр дә ул чын икән, ихлас икән, ул бервакытта да кешене алдамый* (Г. Гыйльманов).

2) *Алар түккән күз яше шулкадәр күп иде: бу яшь ташкыны, чишмә булып, җир астыннан өскә бәреп чыгар сыман иде* (Г. Гыйльманов).

3) *Урамнарны иңләп шатлык килә,*
*Дус сөенә, дошман көенә* (Р. Вәлиев).

4) *Юрадым мин: әгәр кояш чыкса,*
*Минем янга бүген киләсең* (Р. Вәлиев).

12. Компонент чикләре дөрес билгеләнгән җавапны табыгыз:

*Машиналар, атлылар йөреп такырлаган юл киң булса да, ул, саргылт туфлиләре белән кипкән үләннәрне, коелган яфракларны таптап, аяк астында шарт-шорт сынып калучы корыган агач ботакларына басып, юл читеннән бара бирә* (Р. Кәрами).

1) (1) *Машиналар, атлылар йөреп* (2) *такырлаган юл киң булса да,* (3) *ул, саргылт туфлиләре белән кипкән үләннәрне, коелган яфракларны таптап, аяк астында шарт-шорт сынып калучы корыган агач ботакларына басып, юл читеннән бара бирә.*

2) (1) *Машиналар, атлылар йөреп такырлаган* (2) *юл киң булса да,* (3) *ул, саргылт туфлиләре белән кипкән үләннәрне, коелган яфракларны таптап, аяк астында шарт-шорт сынып калучы корыган агач ботакларына басып, юл читеннән бара бирә.*

3) (1) *Машиналар,* (2) *атлылар йөреп* (3) *такырлаган юл киң булса да,* (4) *ул, саргылт туфлиләре белән кипкән үләннәрне, коелган яфракларны таптап,* (5) *аяк астында шарт-шорт сынып калучы корыган агач ботакларына басып,* (6) *юл читеннән бара бирә.*

4) (1) *Машиналар, атлылар йөреп такырлаган* (2) *юл киң булса да,* (3) *ул, саргылт туфлиләре белән кипкән үләннәрне, коелган яфракларны таптап,* (4) *аяк астында шарт-шорт сынып калучы корыган агач ботакларына басып,* (5) *юл читеннән бара бирә.*

13. Тыныш билгесенең дөрес куелган вариантын табыгыз:
*Син көләсең чөнки син беләсең*

*Дөнья фани гомер Бердәнбер* (Р. Вәлиев).

1) *Син көләсең – чөнки син беләсең,*

*Дөнья фани – гомер Бердәнбер.*

2) *Син көләсең, чөнки син беләсең,*

*Дөнья – фани, гомер – Бердәнбер.*

3) *Син көләсең, чөнки син беләсең:*

*Дөнья фани, гомер – Бердәнбер.*

4) *Син көләсең, чөнки син беләсең:*

*Дөнья – фани, гомер – Бердәнбер.*

14. Күп иярченле катлаулы кушма җөмләләрнең тәңгәллеген күрсәтегез:

1) *Язмыш таң кебек: башы бар, ахыры юк...* (Г. Гыйльманов). А) тиңдәш түгел иярүле

2) *Сынаган бар: сине сагынганда, әнкәй искә төшә нигәдер*

(Г. Гыйльманов). Б) берничә төр ияртүле

3) *Моның соңы нәрсә белән бетәчәге билгесез булса да, карар кабул ителгәч, ничектер җанга җиңелрәк булып китте* (И. Гази). В) тиңдәш ияртүле

4) *Мин булганга син куанган кебек,*

*Мин куанам хәзер син булганга...*

(Ш. Җиһангирова). Г) бер-бер артлы ияртүле

15. Тәңгәллекне күрсәтегез:

1) *Һәр кеше бәхетле булса, бар халык бәхетле була, дөнья түгәрәк була* (Р. Вәлиев). А) күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

2) *Яңгырлар башлана, салкыннар китә, җил-бураннар уйный* (С. Шәмси). Б) күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә

3) *Таңнар атса, кичләр җитсә, Чишмәләрне сагынам* (Р. Вәлиев). В) катнаш кушма җөмлә

17. Текстны укыгыз һәм биремнәрне үтәгез.

(1) *Менә шушы аяз матур көн, якында гына кызларның көлешүе, малайларның йомшак яшь тавыш белән ат куалаулары, акрын гына югарыга күтәрелә, үсә баручы кибән – боларның һәммәсе миңа бик тә ягымлы, бик тә кадерле булып күренә.* (2) *Туктап ял иткән чакларда*

*тиреңне сөртәсең дә, ирексездән рәхәтләнеп елмаясың!* (3) *Менә шушы ямьле болынга, аяз зәңгәр күккә, аның ерак читендә тыныч кына күренеп торган ап-ак болытка, якындагы тал куакларына сөенәсең...* (4) *Алар сиңа бертуганыңдай якын, кадерле булып күренә.* (5) *Алардан аерылып, алардан читтә ничек итеп яшәргә, көн күрергә мөмкин икән диеп уйлап аласың...* (6) *Һәм әнә шундый уйдан соң сиңа Ходай тарафыннан бүләк ителгән бу көннең, бу күренешнең әйтеп, аңлатып бетерелә алмастай олы бәһасе, тагын да эчкәрәк үтеп, синең хәтереңә сеңә.* (7) *Әлеге кояшлы күренеш мәңгелек яктылык булып синең күңелеңә оялый!*

(8) *Җәй көннәре бик тә озын бит инде ул...* (9) *Көне буена кояш астында йөрү, биек-биек кибәннәр утыртып кую арыта да, туйдыра да...* (10) *Әмма кичке салкын төшеп, эшләр тәмамлануга сине тирән күл суы көтә!* (11) *Кырыйларыннан башта бата-бата гына атласаң да, эченә бер кереп киткәч иллә дә тәмләп, рәхәтләнеп йөзәсең инде анда!* (12) *Зурлыгын да зур шул ул!* (13) *Аның теге очы бөтенләй күренми: тал куаклары артыннан борылып китә ул, ә инде каршы як ярына хәтле бер сиксән-йөз адымнар чамасы булыр кебек.* (14) *Әле җитмәсә ул як тоташ таллык кына!* (15) *Күлнең суы да кара-кучкыл булып тора анда: шомлы булып.* (16) *Куркыныч булып!* (17) *Ул якка йөзеп чыгучы да юк диярлек: без күлне буйлап йөзәбез яисә инде бу яктарак юанабыз* (Мансур Вәли-Барҗылы).

1. Инверсия күренеше кайсы җөмләләрдә чагылыш тапкан?

   1) 11, 12, 13, 15

   2) 8, 11, 12

   3) 8, 11, 12, 13, 15

   4) 11, 12, 13, 15, 16

2. 3 нче җөмлә ул –

   1) билгеле үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә

   2) гомум үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә

3) ике составлы, ким җөмлә

4) ике составлы, тулы җөмлә

3. 6 нчы җөмлә ул –

1) гади җөмлә

2) иярчен аергыч кушма җөмлә

3) иярчен рәвеш җөмлә

4) тезмә кушма җөмлә

4. 13 нче җөмлә ул –

1) күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә

2) тиңдәш ияртүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

3) тиңдәш түгел ияртүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

4) катнаш кушма җөмлә

5. 10 нчы җөмлә ул –

1) гади җөмлә

2) иярченле кушма җөмлә

3) бер-бер артлы ияртүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

4) берничә төр ияртүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

6. 16 нчы төзелмә:

1) рәвеш хәле

2) фигыль хәбәр

3) исем хәбәр

4) өстәлмә

7. 15 нче җөмләдә ***шомлы булып***:

1) рәвеш хәле

2) аныклагыч

3) өстәлмә

4) хәбәр

8. 17 нче җөмлә ул –

1) аналитик иярчен сәбәп җөмләле кушма җөмлә

2) бер-бер артлы ияртүле катлаулы кушма җөмлә

3) тиңдәш ияртүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

4) аныклагыч белән җәенкеләндерелгән гади җөмлә

9. 8 нче җөмләнең хәбәрен билгеләгез:

1) *озын*

2) *озын бит инде ул*

3) *ул*

4) *бит инде ул*

10. 14 нче җөмләдәге хәбәрнең төрен билгеләгез:

1) гади исем хәбәр

2) кушма исем хәбәр

3) кушма фигыль хәбәр

4) тезмә исем хәбәр

**2 вариант**

1. Җөмләнең төрен билгеләгез:

*Ул белә: кеше ризыксыз тора ала, кеше сусыз да өч көн тора ала, әмма кеше йокысыз тора алмый...* (Н. Акмал).

1) гади җөмлә
2) ике компонентлы кушма җөмлә
3) катлаулы кушма җөмлә

2. Җөмләнең төрен билгеләгез:

*Ә еракта, якты йолдызлар җемелдәшкән карасу-зәңгәр офыклар артында, таң беленеп килә иде* (Җ. Дәрзаман).

1) гади җөмлә
2) ике компонентлы кушма җөмлә
3) катлаулы кушма җөмлә

3. Җөмләнең төрен билгеләгез:

*Дөресе: кайда явызлык – шунда кан коела, сугыш уты дөрли...* (Г. Гыйльманов).

1) гади җөмлә
2) ике компонентлы кушма җөмлә
3) катлаулы кушма җөмлә

4. Җөмләдә компонентларның санын билгеләгез:

*Кул-аяк, буй-сын бик тигез килсә дә, малайның күзе зәгыйфьрәк, ул күзлек киеп йөри, фантастик китаплар укырга бик һәвәс булганлыктан, төннәр буе китапка капланып утырганга, унынчыны бетергәндә, аның күзе тагын да зәгыйфьләнә төшкән иде* (Г. Ахунов).

1) 3 компонент
2) 4 компонент
3) 5 компонент
4) 6 компонент

5. Җөмләдә компонентларның санын билгеләгез:

*Үзе тыкрыгыннан үзәк урамга борылганда гына ул кайчандыр җылы почмак биргән, дүрт малай үстереп, читкә таратып, моннан берничә ел элек кенә Салават шәһәреннән бөтенләйгә авылга кайтып төпләнгән төпчек улы тәрбиясендә яшәүче, тулы тырыс белән җиләк күтәреп кайтып килүче һәм зәңгәр кәшемир яулыгын татар әбиләренчә алга бәйләп, үзе дә зәңгәр күзле кипкән мәтрүшкәгә охшап калган Гайния карчыкка тап булды* (А. Хәлим).

1) 3 компонент
2) 4 компонент
3) 5 компонент
4) 7 компонент

6. Катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез:

*Күрше елгачыктан дымлы җил исеп-исеп куя; еракта, шәһәр бакчасында, музыка уйный; кызларның чыркылдап көлгәне ишетелеп, күңелне ярсытып тора* (И. Гази).

1) күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә
2) күп иярченле катлаулы кушма җөмлә
3) катнаш кушма җөмлә

7. Катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез:

*Рәхмәт укыйм бу дөньяга,*

*Миңа син булган өчен,*

*Керфегеңә ап-ак, йомшак*

*Энҗе кар кунган өчен...* (Г. Гыйльманов)

1) күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә
2) күп иярченле катлаулы кушма җөмлә
3) катнаш кушма җөмлә

8. Катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез:

*Әти алма, лимон, кара җимеш ише нәрсәләрне еш алып кайтса да, конфет, печенье кебек тәмле-томлылар гает шикелле зур бәйрәмнәрдә генә алып кайтылганлыктан, арзанлы камыр конфет та тансык иде безгә* (С. Әдһәмова).

1) тиңдәш түгел иярүле катлаулы кушма җөмлә
2) бер-бер артлы иярүле катлаулы кушма җөмлә
3) берничә төр иярүле катлаулы кушма җөмлә
4) тиңдәш иярүле катлаулы кушма җөмлә

9. Катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез:

*Олы юлны танклар эштән чыгарып бетерсә дә, аның белән янәшә генә җиңел машиналар салып өлгергән яңа юл ярыйсы ук җайлы: зарланырлык түгел* (Г. Шәрәфи).

1) тиңдәш түгел иярүле катлаулы кушма җөмлә
2) бер-бер артлы иярүле катлаулы кушма җөмлә
3) берничә төр иярүле катлаулы кушма җөмлә
4) тиңдәш иярүле катлаулы кушма җөмлә

10. Катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез:

*Өянке бүгенгедәй хәтерли әле: бәйрәмгә ике көн кала, төне буе гарасатлы давыллап, яшенле яңгыр яуды* (М. Галиев).

1) тиңдәш түгел иярүле катлаулы кушма җөмлә
2) бер-бер артлы иярүле катлаулы кушма җөмлә
3) берничә төр иярүле катлаулы кушма җөмлә
4) тиңдәш иярүле катлаулы кушма җөмлә

11. Мисаллар арасыннан “артык” җөмләне табыгыз:

1) *Кеше күңел кушканны эшләргә тиеш, кеше кушканны түгел* (Р. Вәлиев).

2) *Мин күрдем, төннәрне таратып,*
*Дөньяда алсу таң атканын* (Р. Вәлиев).

3) *Иртәнге таң атуны,*
*Кичен кояш батуны*

*Алышмыйм сиңа* (Г. Гыйльманов).

4) *Ай батканда, таң атканда*
*Уздым җырлап урамнардан* (Р. Вәлиев).

12. Мисаллар арасыннан “артык” җөмләне табыгыз:

1) *Аларның сыйныфында шундый гадәт бар: дәресләр беткәч, укытучы Гөлсинә апалары үзенең беренчеләрен ишек төбенә кадәр озата чыга* (Г. Гыйльманов).

2) *Иң аянычлысы: аның язмышында әле бер генә авыр йомгак та сүтелмәгән, бер генә авыр мәсьәлә дә хәл ителмәгән...* (Г. Гыйльманов).

3) *Комы беткән саен сәгатьне әйләндереп куя-куя: “Гомер бигрәк тиз үтә...” – дип күрсенә торган иде* (Л. Зөлкарнәй).

4) *Инде күптән караңгы төшкән; күктә – нур диңгезендә – түгәрәк ай йөзә; паркта электр лампалары балкый* (И. Гази).

13. Компонент чикләре дөрес билгеләнгән җавапны табыгыз:

*Аның сүзләре шундый ягымлы, шундый йомшак, җылы иде ки, врач апа сөйләшкән саен, баш авыртуы кими бара, баш эчендә янган ялкын сүрелә төшә, кулларга, аякларга, күкрәккә җылы йөгерә* (Р. Вәлиев).

1) (1) *Аның сүзләре шундый ягымлы, шундый йомшак, җылы иде ки,* (2) *врач апа сөйләшкән саен,* (3) *баш авыртуы кими бара, баш эчендә янган ялкын сүрелә төшә,* (4) *кулларга, аякларга, күкрәккә җылы йөгерә.*

2) (1) *Аның сүзләре шундый ягымлы,* (2) *шундый йомшак,* (3) *җылы иде ки,* (4) *врач апа сөйләшкән саен,* (5) *баш авыртуы кими бара,* (6) *баш эчендә янган ялкын сүрелә төшә,* (7) *кулларга, аякларга, күкрәккә җылы йөгерә.*

3) (1)*Аның сүзләре шундый ягымлы, шундый йомшак, җылы иде ки,* (2) *врач апа сөйләшкән саен,* (3) *баш авыртуы кими бара,* (4) *баш эчендә янган ялкын сүрелә төшә,* (5) *кулларга, аякларга, күкрәккә җылы йөгерә.*

4) (1) *Аның сүзләре шундый ягымлы, шундый йомшак, җылы иде ки,* (2) *врач апа сөйләшкән саен,* (3) *баш авыртуы кими бара,* (4) *баш эчендә янган ялкын* (5) *сүрелә төшә,* (6) *кулларга, аякларга, күкрәккә җылы йөгерә.*

14. Тыныш билгесенең дөрес куелган вариантын табыгыз:

*Күк аяз көннәр коры тора тик шунысы аяныч алтын вакыт заяга үтә* (М. Рафиков).

1) *Күк аяз: көннәр коры тора, тик шунысы аяныч, алтын вакыт заяга үтә!*

2) *Күк аяз, көннәр коры тора, тик шунысы аяныч: алтын вакыт заяга үтә!*

3) *Күк аяз, көннәр коры тора, тик, шунысы аяныч: алтын вакыт заяга үтә!*

4) *Күк аяз, көннәр коры тора, тик шунысы аяныч – алтын вакыт заяга үтә!*

15. Күп иярченле катлаулы кушма җөмләләрнең тәңгәллеген күрсәтегез:

1) *Кайгы килеп, җаным сызлаганда,* А) тиңдәш түгел иярүле

*Хәсрәтләрдән күңелем узынганда,*

*Керсез бала чакларыма кайтам*

(Г. Гыйльманов).

2) *Старт алырга киткән атлар күренмәс* Б) берничә төр иярүле

*булгач та, Гөлҗиһан ике ягына карт*

*каеннар тезелгән киң юлдан күзен*

*алмады* (К. Тимбикова).

3) *Зинһар өчен, кермә төшләремә:* В) тиңдәш иярүле

*Таң атуга төшләр өзелер* (Р. Вәлиев).

4) *Гомерләр үтү, тормышлар үзгәрү белән,* Г) бер-бер артлы иярүле

*ул да үзгәргән, картайган...* (Ә. Фәйзи).

16. Тәңгәллекне күрсәтегез:

1) *Ә мин, җирем, син еласаң – елыйм,* А) күп иярченле катлаулы кушма

*Син шатланган чакта – гел көләм* җөмлә

(Р. Вәлиев).

2) *Кайнар җилләр исә, ә мин түзәм,* Б) күп тезмәле катлаулы кушма

*Басса да тир бөтен җилкәмне...* җөмлә

(Р. Вәлиев).

3) *Минем кояш – бәхет, аем – шатлык,* В) катнаш кушма җөмлә

*Яңгыр булып миннән тир тама* (Р. Вәлиев).

17. Текстны укыгыз һәм биремнәрне үтәгез.

(1) *Яраткан бер гадәте бар иде бу кызның: яз җиттеме, чишмәгә килсә, тал песиләре җыеп кайта.* (2) *Чәчәк вакытында бәллүр вазалары шомырт, балан чәчәге, болын чәчәкләреннән бушап тормый.* (3) *Көзгә кергәч, кочагы белән өрәңгенең ут кебек кызыл, лимон кебек сары челтәр читле яфракларын җыя.* (4) *Бүген дә, су алудан бигрәк, шомырт чәчәкләре өчен килгән иде бит.* (5) *Ерак та барасы түгел: тау итәген тутырып, шомырт куаклары чәчәк атып утыра.* (6) *Җаның теләгән хәтле өзеп ал.* (7) *Чишмә янында да ялгыз шомырт агачы үсә.* (8) *Ул инде бик карт агач.* (9) *Чәчәкләре дә өстәге яшь ботакларында гына.* (10) *Наҗия шуларны гына өзәсе итте.* (11) *Арырак барса, тиз генә әйләнеп кайтмаслыгын белә.* (12) *Мавыгып китеп, тау башына ук менүе бар.* (13) *Мәктәп турнигында күнегүләр ясап үскән җиңел гәүдәле кызга авыр эшмени.* (14) *Агач башына да бик тиз менеп җитте ул.* (15) *Тиен шикелле ботактан ботакка сикерүе кыен булмады.*

(16) *Әнекәй-лә-рем лә!* (17) *Менә кайда икән ул матурлык дөньясы.* (18) *Левитан картиналары бер якта торсын.* (19) *Табигать үзенең бар*

*хәзинәсен бергә җыйган да, туйганчы карап сөенсен дип, бөтен матурлыгы белән кызның алдына китереп салган.* (20) *Берсен дә онытмаган, бер ишен дә калдырмаган.* (21) *Күр инде тау битендәге ул агачларны!* (22) *Бер-берсенең итәгенә тотынып менгәндәй югары үрләгәннәр* (Ләбибә Ихсанова).

1. Инверсия күренеше кайсы җөмләләрдә чагылыш тапкан?

1) 1, 14, 17, 21

2) 14, 17, 21

3) 12, 14, 16, 17, 21

4) 17, 21

2. 12 нче җөмлә ул –

1) билгеле үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә

2) билгесез үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә

3) ике составлы, ким җөмлә

4) ике составлы, тулы җөмлә

3. 19 нчы җөмлә ул –

1) гади җөмлә

2) синтетик иярчен тәмамлык җөмләле кушма җөмлә

3) синтетик иярчен рәвеш җөмләле кушма җөмлә

4) теркәгечле тезмә кушма җөмлә

4. 1 нче җөмлә ул –

1) бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

2) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

3) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

4) катнаш кушма җөмлә

5. 15 нчы җөмлә ул –

1) гади җөмлә

2) иярченле кушма җөмлә

3) бер-бер артлы ияртүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

4) берничә төр ияртүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

6. 16 нчы төзелмә:

1) эндәш сүз

2) күзаллаулы баш килешле әйләнмә

3) өстәлмә

4) кереш сүз

7. 17 нче җөмләдәге ияне билгеләгез:

1) *ул*

2) *матурлык*

3) *дөньясы*

4) *матурлык дөньясы*

8. 5 нче җөмлә ул –

1) аналитик иярчен сәбәп җөмләле кушма җөмлә

2) аналитик иярчен ия җөмләле кушма җөмлә

3) синтетик иярчен урын җөмләле кушма җөмлә

4) аналитик иярчен шарт җөмләле кушма җөмлә

9. 4 нче җөмләдә ***чәчәкләре өчен*** –

1) сәбәп хәле

2) максат хәле

3) кыек тәмамлык

4) рәвеш хәле

10. 10 нчы җөмләдәге хәбәрнең төрен билгеләгез:

1) гади фигыль хәбәр

2) тезмә фигыль хәбәр

3) кушма фигыль хәбәр

4) кушма исем хәбәр

## 14. Әдәбият исемлеге

### Төп әдәбият


1. Зәкиев М.З. Синтаксис һәм пунктуация / М.З.Зәкиев. – Казан, 1965. – 147 б.
2. Зәкиев М.З. Татар синтаксисы: Югары уку йортлары өчен дәреслек / М.З.Зәкиев. – Казан: Мәгариф, 2005. – 399 б.
3. Ибраһимов С.М. Синтаксик стилистика / С.М.Ибраһимов. – Казан, 1989. – 167 б.
4. Курбатов Х.Р. Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре / Х.Р.Курбатов. – Казан, 1956. – 174 б.
5. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле / Ф.С.Сафиуллина, М.З.Зәкиев. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б. 142-211.
6. Татар грамматикасы / М.З.Зәкиев. – III том. – М.: Инсан, Казан: Фикер, 1999. – 512 б.
7. Хангилдин В.Н. Татар теле грамматикасы / В.Н.Хангилдин. – Казан, 1959. – 335 б.


### Өстәмә әдәбият


1. Алпаров Г. Татар телендә иярчен җөмләләр бармы? // Совет әдәбияты. – 1937, № 2. – Б. 50-51.
2. Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр / Г.Алпаров. – Казан: Татгосиздат, 1945. – 328 б.
3. Амиров Г.С. Из сопоставительного синтаксиса русского и татарского языков: Приложение в современном русском языке сопоставительно с татарским / Г.С. Амиров. – Казань: Таткнигоиздат, 1961. – 208 с.

4. Асылгараев Ш.Н. Синтагматическое членение татарской речи: Автореферат дисс. ... канд. филол. наук / Ш.Н.Асылгараев. – Казань, 1968.

5. Атнагулов С., Алпаров Г. Грамматика. Икенче кисәк: Синтаксис / С. Атнагулов, Г. Алпаров. – Казан: Татар китап нәшр., 1934. – 121 б.

6. Байрамова Л.К., Сафиуллина Ф.С. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков / Л.К.Байрамова, Ф.С.Сафиуллина. – Казань, 1989.

7. Вәлиди Җ. Татар теленең грамматикасы / Җ.Вәлиди. – Казан, 1919. – 212 б.

8. Галлямов Ф.Г. Лексико-грамматические особенности повторов в современном татарском языке: Дис. ... канд. филол. наук / Ф.Г. Галлямов. – Казань, 1983. – 185 с.

9. Галләмов Ф.Г., Әдһәмова Р.Ә. Татар телендә мөрәҗәгать җөмләләр // Татар филологиясе мәсьәләләре. – Алабуга: АДПУ нәшр., 2001. – Б. 45-49.

10. Галләмов Ф.Г. Татар телендә җөмләдән тыш килгән керешмә төзелмәләр // Милли мәдәният. – 2003, № 4. – Б. 17-23.

11. Галлямов Ф.Г. Повторы в современном татарском языке / Ф.Г. Галлямов. – Казан: РИЦ «Школа», 2003. – 144 с.

12. Галләмов Ф.Г. Хәзерге татар әдәби теле: катлауландырылган җөмлә синтаксисы: Күнегүләр җыентыгы һәм анализ үрнәкләре / Ф.Г. Галләмов. – Алабуга: АДПУ нәшр., 2004. – 146 б.

13. Галләмов Ф.Г. Хәзерге татар әдәби теле: кушма җөмлә синтаксисыннан күнегүләр җыентыгы / Ф.Г. Галләмов. – Алабуга: АДПУ нәшр., 2005. – 92 б.

14. Галлямов Ф.Г. Осложненное предложение в татарском языке / Ф.Г. Галлямов. – Казань: Gumanitarya, 2005. – 264 с.

15. Гальперин И.Р. Текст как объект лингвистического исследования / И.Р.Гальперин. – М., 1981.

16. Гамәли тел сабаклары: (практические уроки языка). – III. – Казан, 1925.

17. Гарифуллин М. Татар телендә аерымланган аергычлар // Совет мәктәбе. – 1954, № 5. – Б. 70-72.

18. Гиганов И. Грамматика татарского языка / И.Гиганов. – Петербург, 1801.

19. Җәләй Л. Сурәтләү чарасы булучылыкта җөмләнең “аерымланган” кисәкләре // Сов. әдәбияты. – 1935, № 12. – Б. 87-95.

20. Закиев М.З. Проблемы структуры простого предложения татарского языка: Учебное пособие / М.З.Закиев. – Казань, 1987.

21. Закиев М.З. Синтаксический строй татарского языка / М.З.Закиев. – Казань: Изд-во КГУ, 1963. – 463 с.

22. Закиев М.З., Зиннатуллина К.З., Ибрагимов С.М. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. Сложное предложение: В 3 ч. – Казань: КГПИ, 1977. – Ч.3. – 100 с.

23. Закиев М.З., Сафиуллина Ф.С.. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. Простое предложение: В 3 ч. – Казань: КГПИ, 1977. – Ч.1. – 87 с.; Ч.2. – 94 с.

24. Зарипова И.Ф. Виды грамматической связи слов в татарском языке / И.Ф. Зарипова. – Уфа: РИО БашГУ, 2002. – 146 с.

25. Зәкиев М.З. Җөмләнең дүртенче кисәге – аныклагыч // Сов. мәктәбе. – 1962, № 9. – Б. 32-35.

26. Ибраһимов Г. Татар нәхүе / Г.Ибраһимов. – Казан: Сабах, 1911. – 86 б.

27. Ибраһимов С.М. Татар телендә аналитик төзелмәләр / С.М.Ибраһимов. – Казан: КДУ нәшр., – 1964.

28. Ибраһимов С.М. Чагыштырулы төзелмәләр һәм аларның синонимлыгы / С.М. Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. – 55 б.

29. Иванов М. Татарская грамматика / М.Иванов. – Казань, 1842. – 311 с.

30. Иманаев Ш. Татар теленең нәхү вә сарыфы / Ш.Иманаев. – Казан, 1910.

31. Казем-Бек М.А. Общая грамматика турецко-татарского языка / М.А.Казем-Бек. – Казань, 1846. – 480 с.

32. Кашапов М.Х. Татар теле синтаксисыннан лекцияләр / М.Х. Кашапов. – Казан: Gumanitarya, 2003. – 168 б.

33. Кашапов М.Х., Сәгъдиева Р.К. Татар телендә синтаксик анализ төрләре: Методик кулланма / М.Х. Кашапов, Р.К. Сәгъдиева. – Казан: ТГГИ нәшр., 2000. – 40 б.

34. Корбангалиев М., Бәдигъ Х. Ана теле нәхүе / М.Корбангалиев, Х.Бәдигъ. – Казан, 1919.

35. Коцарь Э. Вводные слова и словосочетания, вводные предложения, вставные кострукции / Э. Коцарь. – М., 1969. – 30 с.

36. Кушма җөмлә синтаксисы: теоретик мәгълүматлар, күнегүләр, контроль эшләр, тестлар. Методик кулланма. – Казан: КГУ, 2006. – 90 б.

37. Максимов Н.В. Гади җөмлә синтаксисы: 7-11 нче сыйныф укытучылары өчен кулланма / Н.В. Максимов, З.В. Шәйхразиева. – Казан: РИЦ: Школа, 2006. – 148 б.

38. Максимов Н.В. Татар теленнән кулланма (синтаксис): Өченче китап / Н.В. Максимов. – Казан: РИЦ: Школа, 2003. – 96 б.

39. Максуди Һ. Төрки нәхүе / Һ.Максуди. – Казан, 1910. – 64 б.

40. Махмудов М. Практическое руководство к изучению татарского языка /М.Махмудов. – Казань, 1857.

41. Мирзаһитов Р.Х., Шәйхиева Г.М. Хәзерге татар әдәби теле. Пунктуация / Р.Х. Мирзаһитов, Г.М. Шәйхиева. – Казан: Ихлас, 2013. – 52 б.

42. Мостафа Ә. Төрки нәхүе / Ә.Мостафа. – Казан, 1914.

43. Насыри К. Краткая татарская грамматика, изложенная в примерах / К.Насыри. – Казань, 1860. – 80 с.

44. Насыйри К. Әнмүзәҗ / К.Насыйри. – Казан: Ун-ты типографиясе, 1895. – 148 б.

45. Нәбиуллина Г.Ә. Татар халык мәкальләрендә кушма җөмлә синтаксисы / Г.Ә. Нәбиуллина. – Казан: Школа, 2003. – 208 б.

46. Нугайбәк Г. Төрлек / Г.Нугайбәк. – Казан, 1911. – 111 б.

47. Откупщикова М.И. Синтаксис связного текста / М.И.Откупщикова. – Л., 1982.

48. Сабиров К. Татар телендә тыныш билгеләре / К. Сабиров. – Казан, 1956. – 184 б.

49. Сабиров К.С. Җөмләнең аерымланган иярчен кисәкләре // Сов. мәктәбе. – 1956, № 2. – Б. 51-55.

50. Сабиров К. Татар телендә тыныш билгеләре кагыйдәләре / К. Сабиров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. – 67 б.

51. Сайкин Ш. Иярчен кисәкләрнең һәм өстәмә сүзләрнең аерымлануы турында // Сов. мәктәбе. – 1957, № 5. – Б. 28-35.

52. Сайкин Ш. Синтаксик төзелмәләрнең аерымлануы, аның кыен очраклары / Ш.Сайкин. – Казан, 1980. – 160 б.

53. Сафиуллина Ф.С. Развитие синтаксического строя татарского языка в советский период (простое предложение) / Ф.С. Сафиуллина. – Казань: КГУ, 1990. – 232 с.

54. Сафиуллина Ф.С. Синтаксис татарской разговорной речи / Ф.С.Сафиуллина. – Казань, 1978. – 254 с.

55. Сафиуллина Ф.С. Татар телендә сүз тәртибе / Ф.С.Сафиуллина. – Казан, 1974. – 154 б.

56. Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше / Ф.С.Сафиуллина. – Казан, 1993. – 265 б.

57. Сәгъди Г. Телебез нәхүе / Г.Сәгъди. – Казан, 1914.

58. Сәгъдиева Р.К. Сүзләрне бәйләүче чаралар (кушымчалар): Методик кулланма / Р.К. Сәгъдиева . – Казан: Gumanitarya (ТДГИ), 2002. – 100 б.

59. Сәгъдиева Р.К. Сүзләрне бәйләүче чаралар: Методик кулланма / Р.К. Сәгъдиева . – Казан: Gumanitarya, 2004. – 80 б.

60. Сәгъдиева Р.К., Мирзаһитов Р.Х. Татар теленнән тестлар һәм мөстәкыйль эш биремнәре. Синтаксис. / Р.К. Сәгъдиева, Р.Х. Мирзаһитов. – Казан: Ихлас, 2014. – 60 б.

61. Синтаксические конструкции: Сборник научных статей / Отв. ред. Хакимзянов Ф.С. – Казань: Изд. центр КГУКИ, 2009. – 172 с.

62. Современный татарский литературный язык: Синтаксис / М.З.Закиев, Х.Р.Курбатов. – М., 1971.

63. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков / М.З.Закиев, К.З.Зиннатуллина и др., – Казань, 1977.

64. Татар теленнән тестлар (синтаксис). Методик кулланма. – Казан: КГУ, 2005. – 46 б.

65. Хәкимҗан Ф.С., Шәкурова М.М. Хәзерге татар теле: Пунктуация / Ф.С. Хәкимҗан, М.М. Шәкурова. – Казан: Gumanitarya, 2003. – 388 б.

66. Хәмидуллин Ф.Х. Телебездә чишелергә тиешле кайбер мәсьәләләр турында (шарт җөмләләр) // Мәгариф. – 1995, № 7. – Б. 13-17.

67. Хисмәтуллин Х.Х. Җөмләнең аерымланган иярчен кисәкләре // Сов. мәктәбе. – 1939, № 2. – Б. 31-37.

68. Хисмәтуллин Х.Х. Җөмләнең иярчен кисәкләре турында // Сов. мәктәбе. – 1953, № 1. – Б. 74.

69. Шәйхразиева З.В. Суперкушма җөмләләрнең схемасын төзү: югары уку йортлары студентлары өчен методик кулланма / З.В. Шәйхразиева, Н.В. Максимов. – Казан: Школа, 2011. – 20 б.

70. Шәйхразиева З.В. Суперсинтетик кушма җөмләләрнең схемасын төзү: югары уку йортлары студентлары өчен методик кулланма / З.В. Шәйхразиева, Н.В. Максимов. – Казан: Школа, 2011. – 18 б.

## 15. Имтихан сораулары

**Хәзерге татар әдәби теле синтаксисы курсыннан имтихан өчен сораулык**

1. Синтаксис һәм логика, сөйләм һәм фикерләү арасында мөнәсәбәт. Җөмлә һәм хөкемләү. Алар арасында мөнәсәбәт.
2. Сөйләм берәмлекләре. Төп синтаксик берәмлек буларак җөмлә. Җөмләнең төп үзенчәлекләре. Хәбәрлек һәм модальлек, аларның бирелү ысуллары.
3. Синтаксис фәнендә төрле юнәлешләр.
4. Интонация һәм аның сөйләмдәге роле. Фраза басымы. Пауза. Логик басым. Тойгы басымы. Сөйләм көе.
5. Сүзләрнең синтаксик бәйләнеше. Ияртүле һәм тезүле бәйләнеш. Тезүле бәйләнешне белдерүче чаралар.
6. Ияртүле бәйләнеш. Аның төрләре: хәбәрлекле мөнәсәбәт, тәгәлләүле мөнәсәбәт, аныклаулы мөнәсәбәт. Аларны белдерә торган чаралар.
7. Сүзтезмә турында гомуми мәгълүмат. Сүзтезмәләрнең төрләре: ирекле сүзтезмә һәм фразеологик сүзтезмә; гади сүзтезмә һәм катлаулы сүзтезмә.
8. Ия. Аның төзелеш ягыннан төрләре, белдерелүе һәм төп мәгънәләре.
9. Хәбәр. Исем хәбәрләрнең төзелеш ягыннан төрләре, белдерелүе һәм төп мәгънәләре.
10. Хәбәр. Фигыль хәбәрләрнең төзелеш ягыннан төрләре, белдерелүе һәм төп мәгънәләре.

11. Аергыч һәм аның үзенчәлекләре. Төрле сүз төркемнәре белән бирелгән аергычларның аерылмышка бәйләнү юллары.

12. Аныклагыч һәм аның үзенчәлекләре. Аныклагычлар янында тыныш билгеләре.

13. Тәмамлык һәм аның үзенчәлекләре.

14. Хәлләр. Аларның мәгънә ягыннан төрләре һәм төп үзенчәлекләре.

15. Модаль кисәкләр турында төшенчә. Аларның төп үзенчәлекләре, төрләре, бирелеше. Алар янында тыныш билгеләре.

16. Җөмләнең тиңдәш кисәкләре. Гомумиләштерүче сүзләр. Алар янында тыныш билгеләре.

17. Аерымланган иярчен кисәкләр турында гомуми мәгълүмат.

18. Гади җөмләләрне төркемләү принциплары һәм төрләре.

19. Бер составлы җөмләләрнең гомуми үзенчәлекләре, төрләре.

20. Синтагма турында төшенчә. Җөмлә кисәкләренең аерым синтагма төзи ала һәм төзи алмый торган очраклары.

21. Җөмләнең актуаль кисәкләре. Актуаль кисәкләрнең урыны.

22. Сөйләмдә сүз тәртибенең роле. Төрле сөйләм стильләрендә җөмлә кисәкләренең урыны. Сүзләрнең уңай һәм кире тәртибе турында төшенчә.

23. Раслау һәм инкяр җөмләләр. Бу төр җөмләләрнең төп билгеләре.

24. Өстәлмәләр турында төшенчә. Өстәлмәләрнең кулланылышы һәм төрләре.

25. Ким җөмләләр. Аларның кимлек сәбәбенә һәм кайсы кисәкнең кулланылмавына карап төрләре.

26. Кушма җөмлә турында төшенчә. Кушма җөмләләрне төркемләү принциплары.

27. Тезмә кушма җөмлә үзенчәлекләре. Тезмә кушма җөмләләрнең үзара бәйләнешендә теркәгеч һәм интонацияләрнең роле.

28. Җөмләләр арасында ияртүле бәйләнешне белдерә торган чаралар.

29. Җөмләләр арасында мәгънәви һәм структур бәйләнеш. Җөмләләр арасында грамматик бәйләнеш һәм аның төрләре.

30. Җөмләләрне бәйли торган чара буларак интонация (санау интонациясе, каршы кую интонациясе, күтәрү интонациясе, аныклау интонациясе).

31. Иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйли торган чара буларак ияртүче теркәгечләрнең һәм теркәгеч сүзләрнең үзенчәлекләре.

32. Иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйли торган чара буларак мөнәсәбәтле сүзләрнең үзенчәлекләре.

33. Иярчен җөмләләрне бәйләнеш төренә карап төркемләү. Аналитик иярчен җөмлә үзенчәлекләре. Бу төр җөмләләрдә тыныш билгеләре.

34. Иярчен җөмләләрне бәйләнеш төренә карап төркемләү. Синтетик иярчен җөмлә үзенчәлекләре. Бу төр җөмләләрдә тыныш билгеләре.

35. Иярчен ия һәм хәбәр җөмлә үзенчәлекләре, аларның баш җөмләгә бәйләнү юллары.

36. Иярчен аергыч җөмлә үзенчәлекләре, аның баш җөмләгә бәйләнү юллары.

37. Иярчен тәмамлык җөмлә үзенчәлекләре, аның баш җөмләгә бәйләнү юллары.

38. Иярчен аныклагыч һәм кереш җөмлә үзенчәлекләре, аның баш җөмләгә бәйләнү юллары.

39. Иярчен вакыт һәм урын җөмләләр. Аларның баш җөмләгә бәйләнү юллары.

40. Иярчен рәвеш һәм күләм җөмлә үзенчәлекләре, аларның баш җөмләгә бәйләнү юллары.

41. Иярчен сәбәп һәм максат җөмләләр, аларның баш җөмләгә бәйләнү юллары.

42. Иярчен кире һәм шарт җөмлә үзенчәлекләре, аларның баш җөмләгә бәйләнү юллары.

43. Аналитик һәм синтетик кушма җөмләләрнең үзара синонимлыгы, аларны берсен икенчесенә әйләндерү юллары.

44. Катлаулы кушма җөмлә төрләре: күп тезмәле кушма җөмлә, күп иярченле кушма җөмлә һәм катнаш кушма җөмлә.

45. Күп иярченле кушма җөмлә. Аның төрләре

46. Катнаш кушма җөмлә структурасы. Катнаш кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре.

47. Тезем. Аның интонацион үзенчәлеге, өлешләре, теземдә тыныш билгеләре.

48. Уртак һәм кыек сөйләм, аларның төп үзенчәлекләре. Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү.

49. Чит сөйләм турында төшенчә. Чит сөйләм төрләре. Туры сөйләмнең төп үзенчәлекләре.

50. Текст турында төшенчә. Текстның төрләре, аның мәгънәви, коммуникатив, структур бөтенлеге. Композициясе.

## 16. Курс эше темалары

### Курс эше өчен үрнәк темалар

1. Шигърияттә җөмлә кисәкләренең урнашу үзенчәлекләре.
2. Шигърияттә тиңдәш кисәкләрнең урнашу үзенчәлекләре.
3. Җөмлә кисәкләренең аерымлануы.
4. Аналитик һәм синтетик җөмләләр синонимлыгы.
5. Тезмә кушма җөмләләрнең кулланылышы.
6. Аналитик конструкцияләрнең өйрәнелеше.
7. Синтетик конструкцияләрнең кулланылыш үзенчәлекләре.
8. Татар шигъриятендә тезем.
9. Татар әдәбиятында катлаулы конструкцияләрнең кулланылышы.
10. Татар телендә текст үзенчәлекләре.
11. Иярчен кисәк белән иярчен җөмлә синонимлыгы.
12. Татар телендә өстәлмәләрнең кулланылышы.
13. Әдәби телдә күзаллаулы (баш килешле) әйләнмәләр.
14. Публицистик стильдә җөмлә төзелеше.
15. Публицистик стильдә мәкалә атамаларының бирелеше.

## 17. Глоссарий

### Аңлатмалы сүзлек

**Аергыч** – җөмләнең предмет төшенчәсен атый торган кисәгенә ияреп, шул предметларның билгесен, санын һәм кемгә (нәрсәгә) каравын белдерә торган иярчен кисәк.

**Аергыч тезем** – санау бүлеге аергычлардан яки аергыч җөмләләрдән тора торган тезем.

**Аерылмыш** – аергыч буйсынган сүз.

**Аерымланган кисәкләр** – язуда тыныш билгеләре белән аерыла торган кисәкләр.

**Актуаль киәкләр** – сөйләм предметын һәм сөйләм яңалыгын белдерә торган сүзләр.

**Аналитик кушма җөмлә** – ияртчен җөмләсе баш җөмләгә аналитик чара ярдәмендә бәйләнгән һәм формасы белән гади җөмләгә охшаган иярченле кушма җөмлә.

**Аныклагыч** – ияртүче кисәктән соң килеп, аңа аныклык кертә торган иярчен кисәк.

**Аныклагыч тезем** – санау бүлеге аныклагычлардан яки аныклагыч җөмләләрдән тора торган тезем.

**Аныклаулы мөнәсәбәт** – ияртүче сүзнең ияртүче сүзгә өстәмә аныклык бирүе.

**Баш җөмлә** – иярченле кушма җөмләдә иярчен җөмләне ияртеп килгән җөмлә.

**Башкарылу** – ияртүче сүзнең ияртүче сүзнең нинди дә булса бер килеш формасын алуын яки кайсы да булса бер бәйлек белән килүен таләп итүе.

**Бер составлы җөмлә** – җөмләнең барлык кисәкләре дә бер генә баш кисәк янына оешып беткән җөмлә.

**Бер составлы исем җөмлә** – баш кисәге исем яки исемләшкән башка сүзләр белән бирелгән һәм әйберләрнең, билгеләрнең яки төрле күренешләрнең исемнәрен атау юлы белән аларның булу-булмауларын хәбәр итә торган җөмлә.

**Бер составлы фигыль җөмлә** – баш кисәге фигыль һәм процесс белдерә торган башка сүзләр белән бирелгән җөмлә.

**Бер-бер артлы ияртүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә** – иярчен җөмләләре баш җөмләгә бер-бер артлы ияреп килгән кушма җөмлә.

**Берничә төр ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә** – берничә төр бәйләнеш бергә кулланылган кушма җөмлә.

**Билгеле үтәүчеле җөмлә** – баш кисәктән аңлашылган процессның үтәүчесе конкрет билгеле булган бер составлы җөмлә.

**Билгесез үтәүчеле җөмлә** – баш кисәктән аңлашылган процессның үтәүчесе конкрет билгеле булмаган җөмлә.

**Боеру җөмлә** – сөйләүченең боеруын, үтенүен, чакыруын, киңәшен белдерә торган җөмлә.

**Вакыт тезем** – санау бүлеге вакыт хәлләреннән яки вакыт җөмләләрдән тора торган тезем.

**Вакыт хәле** – процессның үтәлү вакытын яки билгенең булу-булмау вакытын белдерә торган иярчен кисәк.

**Гади җөмлә** – бер генә хәбәрлектән торган җөмлә.

**Гади кушма җөмлә** – ике җөмләдән торган кушма җөмлә.

**Гади сүзтезмә** – ике генә мөстәкыйль сүздән торган сүзтезмә.

**Гади хәбәр** – бер генә сүз белән белдерелгән хәбәр.

**Гомумиләштерүче сүз** – тиңдәш кисәкләрнең барысын бергә җыеп, гомумиләштереп әйтә торган кисәк.

**Грамматик бөтенлек** – тексттагы мөстәкыйль җөмләләрнең, абзацларның грамматик чаралар белән бәйләнүе.

**Диалог** – ике яки берничә кешенең үзара сөйләшүе формасында бирелгән туры сөйләм.

**Җәенке җөмлә** – иярчен яисә модаль кисәкләр файдаланылган җөмлә.

**Җөмлә** – сөйләмнең фикерне, кичерешне һәм ихтыярны хәбәр итә һәм сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерә торган иң кыска берәмлеге.

**Җөмләнең модаль кисәкләре** – сөйләүченең чынбарлыкка, тыңлаучыга, җөмлә эчтәлегенә, төзелешенә мөнәсәбәтен белдерә торган кисәк.

**Җөмләнең модальлек белдерүе** – сөйләүченең чынбарлыкка, тыңлаучыга, сөйләмгә мөнәсәбәт белдерүе.

**Җөмләнең парадигмасы** – билгеле бер гомуми мәгънә тирәсенә тупланган синтаксик формалар системасы.

**Җөмләнең хәбәрлек белдерүе** – фикерне, кичерешне һәм ихтыярны хәбәр итүе, ягъни аларны чынбарлыктан алып чынбарлыкка төбәп әйтүе.

**Җыйнак җөмлә** – баш кисәкләрдән генә торган, иярчен кисәкләре, модаль кисәкләр булмаган җөмлә.

**Инкяр җөмлә** – нәрсәне булса да инкяр итә торган җөмлә.

**Интонация** – сөйләгәндә тавышның төрлечә хәрәкәте.

**Ирекле сүзтезмә** – кирәк булганда гына, ягъни сөйләм барышында гына ясалган һәм кисәкләре арасында реаль мәгънә мөнәсәбәте югалмаган сүзтезмә.

**Исем хәбәр** – фигыльдән кала башка сүз төркемнәре белән белдерелгән хәбәр.

**Ия** – җөмләдә баш килештәге сүз белән бирелеп, хәбәрне үзенә ияртә торган грамматик бәйсез кисәк.

**Ия тезем** – санау бүлеге ияләрдән яки ия җөмләләрдән тора торган тезем.

**Ияртүле бәйләнеш** – сүзләрнең бер-берсенә буйсынып килүе.

**Иярчен аергыч җөмлә** баш җөмләнең аергычы урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән аергычның конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен аныклагыч җөмлә** баш җөмләдән аңлашылган төшенчәне, фикерне өстәмә аныклап килә.

**Иярчен вакыт җөмлә** баш җөмләнең вакыт хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән вакыт хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен җөмлә** – иярченле кушма җөмләдә баш җөмләгә ияреп, буйсынып килгән җөмлә.

**Иярчен ия җөмлә** баш җөмләнең иясе урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән иянең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен кереш җөмлә** җөмләнең, яисә аның кисәгенең эчтәлеген кайсы яктандыр өстәмә рәвештә аныклап, комментарий биреп килә.

**Иярчен кире җөмлә** баш җөмләнең кире хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән кире хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен күләм җөмлә** баш җөмләнең күләм хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән күләм хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен максат җөмлә** баш җөмләнең максат хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән максат хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен рәвеш җөмлә** баш җөмләнең рәвеш хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән рәвеш хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен сәбәп җөмлә** баш җөмләнең сәбәп хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән сәбәп хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен тәмамлык җөмлә** баш җөмләнең тәмамлыгы урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән тәмамлыкның конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен урын җөмлә** баш җөмләнең урын хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән урын хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен хәбәр җөмлә** баш җөмләнең хәбәре урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән хәбәрнең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен шарт җөмлә** баш җөмләнең шарт хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән шарт хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен кисәк** – төгәлләүле һәм аныклаулы мөнәсәбәткә кергән сүзләрнең иярүчесе.

**Иярченле кушма җөмлә** – аерым җөмләләре ияртү юлы белән бәйләнгән җөмлә.

**Катлаулы кушма җөмлә** – икедән артык җөмләдән торган кушма җөмлә.

**Катлаулы сүзтезмә** – икедән артык мөстәкыйль сүздзән торып, гади сүзтезмәләргә таркалмый торган сүзтезмә.

**Катнаш кушма җөмлә** – аерым җөмләләрнең бер төрләре үзара ияртүле юл белән бәйләнеп, икенче төрләре тезүле юл белән бәйләнгән катлаулы кушма җөмлә.

**Кереш сүз** – сөйләүченең сөйләм эчтәлегенә, төзелешенә һәм сөйләм обстановкасына мөнәсәбәтен белдерә торган сүз.

**Ким җөмлә** – контекст, обстановка, мимика һәм жестлардан аңлашыла торган кисәге яки сүз формасы кулланылмаган җөмлә.

**Кире тезем** – санау бүлеге кире хәлләр яки кире җөмләләр белән бирелгән тезем.

**Кире хәл** – ияртүче кисәктәе аңлашылган процессның киресе булачагын белдерә торган иярчен кисәк.

**Кушма җөмлә** – берничә хәбәрлектән торган җөмлә.

**Кушма җөмләнең компонентлары** – кушма җөмлә составындагы гади җөмләләр.

**Кушма хәбәр** – грамматик мәгънәләре ярдәмлек сүзләр белән бирелгән хәбәр.

**Күләм хәле** – процессның яки билгенең күләмен, дәрәҗәсен белдерә торган иярчен кисәк.

**Күп иярченле кушма җөмлә** – икедән артык җөмлә үзара ияртү юлы белән бәйләнгән кушма җөмлә.

**Күп тезмәле кушма җөмлә** – икедән артык җөмлә үзара бары тезү юлы белән генә бәйләнгән кушма җөмлә.

**Күтәрелмә тезем** – иң элек төп бүлек, аннан соң күтәрелә бара торган интонация белән санау бүлеге әйтелә торган тезем.

**Күтәрелүче интонация** – әкренләп күтәрелә бара һәм үзенең иң югары ноктасында кинәт туктап кала торган интонация.

**Кыек сөйләм** – үзгәртелеп кулланылган чит сөйләм.

**Кыек тәмамлык** – процесс турыдан-туры кагылмый торган әйберне, затны белдергән тәмамлык.

**Логик басым** – җөмләдә мәгънәсе буенча иң әһәмиятле сүзгә төшә торган басым.

**Макротекст** – өйрәнү өчен алынган зур текст.

**Максат тезем** – санау бүлеге максат хәлләреннән яки максат җөмләләрдән тора торган тезем.

**Максат хәле** – процессның үтәлү-үтәлмәү, билгенең булу-булмау максатын белдерә торган иярчен кисәк.

**Микротекст** – өйрәнү өчен алынган күләме ягыннан кечкенә текст.

**Модальлек** – сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәте.

**Монолог** – персонажның үз-үзенә, башка берәүгә яисә халыкка мөрәҗәгать ителгән сөйләме.

**Номинативлык** – сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең атау функциясе.

**Өлешчә инкарь җөмлә** – хәбәрдән башка нинди дә булса бер кисәге белдергән төшенчә инкарь ителгән җөмлә.

**Өстәлмә** – мәгънәсенә ныграк игътибар иттерү өчен, төп җөмлә ахырына чыгарылган һәм аерым җөмлә интонациясе белән әйтелгән сүз яки сүзтезмә.

**Прагматик мөнәсәбәт** – сөйләм семантикасының тыңлаучыга мөнәсәбәте.

**Предикат** – алынган төшенчә турында әйтелгән яңалык.

**Пропозиция** – берәр эш-хәл турында хәбәр итү.

**Пунктуация** – тыныш билгеләрен кую турындагы кагыйдәләр җыелмасы.

**Раслау җөмлә** – нәрсәне дә булса раслый торган җөмлә.

**Рәвеш тезем** – санау бүлеге рәвеш хәлләреннән яки рәвеш җөмләләрдән тора торган тезем.

**Рәвеш хәле** – процессның ничек һәм ни рәвешле үтәлүен яисә нинди дә булса бер хәлнең яки билгенең билгесен, сыйфатын белдерә торган иярчен кисәк.

**Редупликация күренеше** – сүзләрне кабатлап куллану.

**Реплика** – диалог эчендә аерым кеше сүзләре.

**Референция** – сөйләм семантикасының чынбарлыкка мөнәсәбәте.

**Риторик сорау җөмлә** – җавап таләп итми торган, бары тик формасы ягыннан гына сорау җөмләләргә кертелә торган сорау җөмлә.

**Сәбәп тезем** – санау бүлеге сәбәп хәлләреннән яки сәбәп җөмләләрдән тора торган тезем.

**Сәбәп хәле** – процессның үтәлү-үтәлмәү яки билгенең булу-булмау сәбәбен белдерә торган иярчен кисәк.

**Семиотика** – нинди дә булса бер хәбәргә ия булган билгенең төзелешен һәм кулланылышын гомумән алып өйрәнә торган методологик фән.

**Синтагма** – сөйләмнең бер-берсеннән паузалар һәм башка ритмомелодик чаралар белән аерыла торган мәгънәле кисәк.

**Синтаксик фразеологизмнар** – сүзләр бәйләнешенең хәзерге нормаларына сыймый торган сүзтезмәләр һәм җөмләләр.

**Синтаксис** – телнең сөйләм төзелешен өйрәнә торган фән.

**Синтетик кушма җөмлә** – иярчен җөмләсе баш җөмләгә синтетик чара ярдәмендә бәйләнгән һәм формасы белән гади җөмләгә охшамаган иярченле кушма җөмлә.

**Сорау җөмлә** – нинди дә булса сорауны белдерә торган җөмлә.

**Сөйләм** – телнең хәрәркәттәге чагы, аралашу ысулы.

**Сөйләм адресаты** – тыңлаучы.

**Сөйләм субъекты** – сөйләүче.

**Сөйләмнең модальлеге** – сөйләмнең чынбарлыкка сөйләүче мөнәсәбәтен белдерергә сәләтле булуы.

**Сөйләмнең хәбәрлеге** – сөйләмнең яңалык хәбәр итәргә сәләтле булуы.

**Субъект** – аның турынданиндидер яңалык әйтү өчен алынган төшенчә.

**Сүз җөмлә** – җөмләнең традицион кисәкләренә туры килеп бетми һәм башка кисәкләрне ияртеп җәенкеләнә алмый торган сүзләрдән оешкан җөмлә.

**Сүзтезмә** – ике яки берничә мөстәкыйль сүзнең төгәлләүле мөнәсәбәткә керүе нәтиҗәсендә ясалган һәм төгәлрәк төшенчәне белдерә торган төзелмә.

**Тәмамлык** – җөмләнең процесс белдерә торган сүз белән бирелгән теләсә кайсы кисәгенә ияреп, процессның (яки билгенең) объектын, үтәүчене яки нинди дә булса бер хәл кичерә торган әйберне (затны) һ.б. мәгънәләрне белдерә торган иярчен кисәк.

**Тәмамлык тезем** – санау бүлеге тәмамлыклардан яки тәмамлык җөмләләрдән тора торган тезем.

**Тезем** – тиңдәш кисәкләре яки тиңдәш җөмләләре күп булу аркасында бик нык җәенкеләнгән гади яки кушма җөмлә.

**Тезмә кушма җөмлә** – аерым җөмләләре үзара тезү юлы белән бәйләнгән кушма җөмлә.

**Тезмә хәбәр** – фразеологик яки бу очракта аерым кисәкләргә таркалмый торган синтаксик сүзтезмә белән бирелгән хәбәр.

**Тезүле бәйләнеш** – сүзләрнең бер-берсенә буйсынмыйча, үзара тигез хокукта килүләре.

**Тезүле тезем** – санау бүлеге төп бүлеккә тезү юлы белән генә бәйләнгән тезем.

**Текст** – өйрәнү өчен алынган, эчтәлек һәм структур яктан оешкан тоташ сөйләм.

**Текст композициясе** – текстның билгеле бер эзлеклелектәге план белән оештырылуы.

**Тел** – аралашу коралы.

**Теркәгечле тезмә кушма җөмлә** – компонентлары теркәгечләр аша бәйләнгән кушма җөмлә.

**Теркәгечсез тезмә кушма җөмлә** – компонентлары интонация аша бәйләнгән кушма җөмлә.

**Тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә** – ике яки икедән артык иярчен җөмлә бер баш җөмләгә ияреп килеп, ул җөмләләр үзара тиңдәш булган кушма җөмлә.

**Тиңдәш кисәкләр** – нинди дә булса бер кисәккә караган һәм шул кисәккә карата бер үк мәгънә мөнәсәбәтендә торган кисәкләр.

**Тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә** – ике яки икедән артык иярчен җөмләнең баш җөмләне төрле яктан ачыклап килүе.

**Тойгы басымы** – көчле тойгы белән әйтелгән җөмләләрдә аерым сүзләргә төшә торган басым.

**Тойгылы боеру җөмлә** – формасы белән боеру җөмләгә охшаган, ләкин боеру төрле тойгыларга, эчке кичерешләргә бай булган җөмлә.

**Тойгылы җөмлә** – көчле тойгы белән әйтелә торган җөмлә.

**Тойгылы сорау җөмлә** – формасы белән сорау җөмләгә охшаган, ләкин төрле тойгыларны, кичерешләрне белдерә торган җөмлә.

**Тойгылы хикәя җөмлә** – формасы белән генә хикәя җөмләгә охшаган, ләкин нинди дә булса күренешне зур тойгы белән хәбәр итә торган җөмлә.

**Төгәлләүле мөнәсәбәт** – иярүче сүзнең ияртүче сүздән аңлашылган әйберне (төшенчәне) шуңа охшаган башка әйберләрдән (төшенчәләрдән) аерып, конкретлаштырып килүе.

**Төшмә тезем** – иң элек санау бүлеге, аннан соң төп бүлек килгән тезем.

**Төшүче интонация** – үзенең югары ноктасыннан әкренләп төшеп бара торган интонация.

**Тулы җөмлә** – мәгънә тулылыгы өчен кирәк булган барлык җөмлә кисәкләре дә файдаланылган җөмлә.

**Тулы интонация** – күтәрелү өлеше, югары ноктасы һәм төшү өлеше булган интонация.

**Туры сөйләм** – үзгәртелмичә кулланылган чит сөйләм.

**Туры тәмамлык** – процесс турыдан-туры кагыла торган әйберне, төшенчәне белдергән тәмамлык.

**Уртак сөйләм** – автор һәм персонаж (чит кеше) өчен уртак сөйләм.

**Урын тезем** – санау бүлеге урын хәлләреннән яки урын җөмләләрдән тора торган тезем.

**Урын хәле** – процессның яки билгенең булу яки юнәлү урынын белдерә торган иярчен кисәк.

**Фигыль хәбәр** – фигыль белән генә белдерелгән хәбәр.

**Фраза басымы** – бер яки мәгънә ягыннан бәйләнгән берничә сүзне (синтагманы) бер басым белән әйтү.

**Фразеологик сүзтезмә** – кисәкләре арасындагы реаль мәгънә мөнәсәбәте югалган һәм шуның нәтиҗәсендә ныгып калган сүзтезмә.

**Хәбәр** – җөмләнең ия турында хәбәр итә һәм аңа грамматик буйсына торган баш кисәк.

**Хәбәр тезем** – санау бүлеге хәбәрләрдән яки хәбәр җөмләләрдән тора торган тезем.

**Хәбәрлек** – сөйләмнең хәбәр итү үзенчәлеге.

**Хәбәрлекле мөнәсәбәт** – ияртүче сүзнең (хәбәр) ияртүче сүз (ия) белдергән төшенчә турында нинди дә булса бер яңалык хәбәр итүе.

**Хәл** – җөмләнең фигыль, сыйфат, рәвеш һәм процесс белдерә торган башка сүзләр белән бирелгән кисәгенә ияреп, процессның яки билгенең билгесен яисә процессның үтәлү рәвешен, вакытын, урынын, юнәлешен, максатын, сәбәбен, шартын, күләм-дәрәҗәсен белдерә торган иярчен кисәк.

**Хикәя җөмлә** – чынбарлыкта булган күренешләр, әйберләр турында хәбәр итә торган җөмлә.

**Хөкемләүнең предикатын белдерә торган сүз** – логик басым төшә торган сүз, ягъни тыңлаучы өчен яңа төшенчә.

**Цитата** – язма әсәрләрдән алынган туры сөйләм.

**Чит сөйләм** – тест эченә килеп кергән башка кеше сүзләре.

**Чын сорау җөмлә** – җавап таләп итә торган сорау җөмлә.

**Чынбарлык** – фәлсәфи мәгънәдә кеше аңыннан тыш реаль яши торган күренешләр.

**Шарт тезем** – санау бүлеге шарт хәлләреннән яки шарт җөмләләрдән тора торган тезем.

**Шарт хәле** – ияртүче кисәктән аңлашылган процессның үтәлү-үтәлмәвенә шарт булып килгән процессны белдерә торган иярчен кисәк.

**Эндәш сүз** – сөйләм төбәлгән затны, әйберне белдерә торган сүз.

**Эндәшле тезем** – санау бүлеге эндәш сүзләрдән генә торган тезем.

**Янәшәлек** – хәл фигыль, шарт фигыль, сыйфат фигыль кушымчалары, кайбер сыйфат һәм рәвеш ясагыч кушымчалар, тартым кушымчасы, мөнәсәбәтле сүзләр, ияртүче теркәгечләр, сүз тәртибе, интонация, янәшә тору һәм лексик мәгънә аша бәйләнеш.

**Ярашу** – иярүче сүзнең үзенең формаларын ияртүче сүз формасына карап яраштыруы.